# Дамир Гыйсметдин
# Атта да, тәртәдә дә

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007
УДК 821. 512. 145-1:3
ББК 84 (2Рос=Тат)-4:5
Г92

**Гыйсметдин Д. М.**

Атта да, тәртәдә дә...: юмористик хикәяләр, шигырьләр, җырлар, юлъязмалар, уйланулар / Дамир Гыйсметдин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 206 б. — 1000 д. — ISBN 978-5-298-01490-8

Китапка сатирик язучы, журналист Дамир Гыйсметдиннең юмористик хикәяләре, шигырьләре, җырлары, чит төбәкләрне урап кайткач язылган сәяхәтнамәләре, публицистик мәкаләләре туплап бирелде.

ISBN 978-5-298-01490-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Гыйсметдинов Д. М., 2007

## Сукыр тавык

*(Юмористик хикәяләр)*

### Ботак

Мәгълүм ки, бу фани дөньяда һәрнәрсә бер-берсенә тыгыз бәйләнгән һәм гади генә күренеш тә сәбәпсез пәйда булмый. Кем әйтмешли, тик торганнан чуан да шытмый. Шуңа күрә Мәгънәви, төп эшенә зыян килсә дә, көннәр буе әнә шул фәлсәфи бәйләнешләрне сүтеп-йомгаклап утыра иде. Башка җитәкче затлардан Мәгънәви әфәнде Харисов тирән фикерләве белән аерылып тора.

Ишектә күренгән секретарь кыз аны җитди фикерләр дөньясыннан шыксыз чынбарлыкка кайтарды.

— Мәгънәви Харисович, сезгә сантехник Сиражиев керергә тели...

— Керсен. Раз тели икән.

Чамасыз эчкәнгә Сиражиевның күз төпләре зәңгәрләнеп, бүртеп чыккан, авызыннан силос исләре аңкып тора.

Шуны күреп, җитәкче янә фәлсәфи дулкынга чалкан ятып, уйлар дәрьясына йөзеп китте.

«Ни өчен эчә бу адәм? Бер яктан, иске заман корбаны... Әтисе эчкәндер, күршеләре буш куймагандыр. Туган көннәр, бәйрәмнәр, тәпи юулар. Гомере буе шул шешәдән ләззәт тапкан алкашлар белән аралашкан бичара бит бу! Икенче яктан, яңа чорга яраклашалмаганга да чөмерәләр инде мондый мәхлуклар!»

Ул арада Сиражиев, бераз кычкырыбрак:

— Мәгънәви Харисович, сез миңа хезмәт хакын түлисезме-юкмы?! — дип сорады.

«Монысы да акча турында... Һаман бер балык башы...»

Нәчәлник тирән сулап куйды, урыныннан күтәрелде һәм, тәрәзәгә карап, тагын уйланып торды.

Сиражиев, озакка сузылган мәгънәсез паузаны өзәргә тырышып, авызын ачкан иде дә, Мәгънәви Харисович, кулы белән ишарәләп, сантехникны үзе янына дәште:

— Ә-әнә күрәсеңме, теге юкә агачын, Сиражиев?

— Йә, шуннан?

— Күрәсеңме, нинди юан ботагы сынган һәм асылынып тора?

— Әйе, тора. Ләкин мин монда причум?

Нәчәлник үпкәләрен һавадан арындырды:

— Менә бит табигать нindиләрне сындыра, Сиражиев!

— Сындыра, кәнишне! Кем бәхәсләшсен... Тик миңа хезмәт хакын...

Мәгънәви Харисович, Сиражиевның сүзен бүлеп:

— Син миңа, Сиражиев, әнә шул сынып, җиргә өзелеп төшәргә торган ботакны хәтерләтәсең. Менә нәрсә турында уйлыйм мин бу мизгелдә. Тирән мәсьәлә бу, энекәш! — диде.

Нәчәлникнең ифрат моңсуланып әйткән саллы фикерен такыр баш Сиражиев тиешенчә бәяли алмады булса кирәк.

— Шайтан алгыры, нинди ботак?! Мин акча турында, ә сез ниндидер пүчтәк ботак...

— Ә-ә, юк, Сираҗиев, болай йөрсәң, син әнә шул ботак сыман сынарсың һәм өзелеп җиргә иңәрсең. Анда инде акча да, шешә дә кирәкмәс, агай-эне...

Сираҗиев: «Әллә мин кичәгедән ычкынганмын, әллә шеф акылга җиңеләйгән», — дип уйлап, урыныннан кузгалды.

— Аңладыңмы? — дип сорады нәчәлник һәм моңсу күзләре белән сантехникка төбәлде.

Тегесе дәшми генә бүреген эләктерде һәм, эше пешмәвен тәмам аңлап, кабинеттан чыгып шылды.

Икенче хезмәткәре кергәнче, Мәгънәви Харисович, янә урыныннан кузгалып, тәрәзә аша сынган ботакка карады вә уйлануын дәвам итте. Әнә бит нәкъ шул агач астында кайбер ахмаклар затлы машиналарын куеп калдыралар һәм озак кына кибетләрдә йөриләр. Бераз җил купса, ә ул, әлбәттә, кубачак, бу ботак һичшиксез берәрсенең машина түбәсенә яхшылап манчый инде. Кем булыр ул бичара... Йә иртәннән хатыны белән чәкәләшкән, йә акчасын югалткан, йә эше уңышсыз барган берәр кәсәбәче... Бер бармаса бармый бит ул. Әлбәттә, Мәгънәви Харисович бары тик бер кылга асылынып торган кылычны хәтерләткән куркыныч ботакны җиргә иңдерә алыр иде. Җитмәсә, бу игелекле эш ул җитәкләгән йорт идарәсенең беркем искәртми башкара торган вазифасы да иде әле. Тик мәсьәлә үзлегеннән хәл ителсә, кызыграк булыр иде бит! Бик беләсе килә, кемне корбан итеп сайлар икән гакыллы табигать?.. Бу бит аның карары...

Нужалы йомышларны хәл итәргә дип кергән тагын берничә хезмәттәшен кабул итеп, аларга да ботак турында бик тирән фәлсәфәле уйлануларын ирештергәч, Мәгънәви әфәнде тыйнак кына чәйләп алды.

Көннең икенче яртысы мае белән идәнгә төшкән бутербродны хәтерләтте. Тәмле генә черем итеп утырган Мәгънәви Харисович кабинетына һич көтмәгәндә аның шефы — шәһәр хуҗасы килеп керде. Бу юлы ул, гөнаһ шомлыгы, эш тәртибен кинәт үзгәртеп, кайбер җитәкчеләрнең нинди гамәлләр белән шөгыльләнүләрен белергә теләгән икән. Кабинетка әйтерсең лә өермәле җил бәреп керде. Чистартылмаган урамнар, ватык ишекләр, киселмәгән агачлар турындагы сүзләр, күк күкрәгән сыман, диварларны тетрәндерде. Зилзилә берничә генә минут дәвам итеп юк булды. Бүлмәдә шабыр тиргә баткан Мәгънәви әфәнде үзе генә басып калды.

Бераз аңга килгәч, кабинет хуҗасы арлы-бирле атлый башлады. Аның зиһене чуалган, хәтер шүрлегенә матурлап тезеп куйган уй-фикерләре челпәрәмә килгән иде. Инде бераз тынычлангач, ул тагын тәрәзәгә күз салды. Йә Ходай! Өч ай буе сөңге кебек асылынып торган ботак өзелеп төшкән бит. «Нинди мизгелне күрми калдым!» — дип көрсенде Мәгънәви Харисович. Җитмәсә, ботак мишень итеп машинаның нindиен сайлаган бит әле! Кайсы бичараныкы булды соң ул дигән фәлсәфи сорау бу юлы тумады. Чөнки мондый кыйммәтле вә затлы машина шәһәрдә бары тик берәү генә. Ул әле генә Мәгънәви Харисовичка уттан ыштан кидерткән шефының яраткан тәгәрмәче иде.

## Көнләшү

Хатын мәкереннән күп интекте Һидият. Өйләнеп, атна-ун көн узмагандыр, Бәдриясе җәнҗал куптарды. Ак күлмәк якасына кайдандыр эләккән иннек аркасында өйдә бер атна буе зилзиләләр, штормнар котырды. Ярый ла ниндидер кәнтәй белән үбешеп-кочаклашып йөри торган донжуан булсаң... Дыңгычлап тулган троллейбуста ике тукталыш барган арада ниндидер марҗаның иннекле иреннәре белән күлмәк якасы очрашкан икән, монда мескен Һидиятнең нинди гаебе бар?! Аңлатып кара син аны көнче хатынга!

Икенче тапкыр тагын да мәгънәсезрәк хәл килеп чыкты. Һидият эшләгән фирманың директоры Фидан Шакирович аны өенә алып китеп, җырлашып утырдылар. Гармунны үзенчә өздереп, моңлы җырлаганга, Һидиятне мәҗлесләргә еш чакыралар иде. Өйләнгәч, таныш-белешләргә, дус-ишләргә бу халык талантын ишетү бәхете тәтеми башлады.

Ә инде берәр мәҗлескә хатыны белән килеп, уйный-җырлый башласа, Бәдриясе гармунчы тирәсендә бөтерелгән хатын-кызлардан көнләшеп, иренең аягына басып, аңа төрткәләп, тизрәк өйгә алып кайтып китү ягын карый иде.

Бу юлы мәҗлестәшләр арасында хатын-кызлар юк дәрәҗәсендә иде. Тик шулай да бәйрәмдарның хәләл җефете белән кызы җырга-моңга хирыс булып чыктылар.

Кирәк бит, нәкъ бергәләшеп «Аерылмагыз»ны башкарган вакытта, ишектә кыңгырау чылтырады. Бусагада ярсыган хатынын күреп, Һидият чак кына баянын кулыннан төшереп җибәрмәде.

— Менә сезнең йортыгыз яныннан узып барганда, тәрәзәдән иремнең хатын-кызлар компаниясендә җырлавын ишеттем дә кердем әле... — диде ул, бер дә оялып-нитеп тормыйча. Ә аннары, хәләленә борылды: — Әйдә, җанкай, сине өйдә көтәләр!..

Һидият үзен йомырка урлап тотылган малай-шалай кебек хис итте.

— ...Ни бит, Бәдрия... Бу бит безнең хуҗа... Директор Фидан Шакирович... Аның туган көне бит...

Тик шул чагында гына Бәдриянең кырыс йөзендә бераз елмаю күренеп алды.

— Тем более, — диде ул, мәктәп укытучысы сыман һәр сүзгә басым ясап, — җүнле ирләр җүнле җиргә хатыннары белән йөриләр...

Һидият бусаганы ничек атлап чыкканын да абайламый калды...

Еллар узган саен, хатынның көнләшүе арта барды. Болай да эштән соң еш кына өйдә утырырга мәҗбүр булган Һидият күзгә күренеп ябыга, дуслары әйтмешли, тутыга башлады. Онытылып ирекле һава сулар өчен бердәнбер урын — эш калды. Бары тик шунда килгәч кенә Һидият тормыштан юаныч таба, үзен кеше итеп хис итә иде. Ире эштән үз вакытында кайтса да, Бәдрия ара-тирә фирманың ишеге төбендә аны каршы ала, җанкисәге тирәсендә кемнәр йөргәнен җентекләп күзәтеп тора иде.

Ләкин адәм баласының кул-аягын бәйләсәң дә, күңеленә богау салу мөмкинме соң?! Хәтта көнчелектән саташа язган Бәдрия дә моңа ирешә алмады.

Март айлары, табигать кышкы йокыдан уянып, ирләр вә хатын-кызлар йөрәгендә мәхәббәт очкыннары кабынган сихри бер чорда Һидиятне командировкага җибәрделәр. Бәдриясе, ни тырышса да, бу эшкә аяк чала алмады. Ахыр чиктә китәр алдыннан, иреннән чын-чынлап допрос алды.

«Кемнәр бара?», «Кайда яшәячәксең?», «Кайчан кайтасың?» кебек сораулардан соң, ротный старшина кебек нәтиҗә ясады:

— Әгәр дә мәгәр читкә карасаң, шуны исеңдә тот: башыңны икенче якка борып куям! Бәлкем әле, сиздерми генә барып та килермен. Новосибирск минем өчен ерак ара түгел...

Һидият бу сөйләшү вакытында ярый әле өйдә ялганны фаш итә торган детектор юк дип сөенеп утырды. Югыйсә командировкага бергә эшләгән зәңгәр күзле яшь чибәркәй Сабираның да барганын белсә, Бәдриясе шундук шартлар йә поезд юлына аркылы ятар иде. Ә Һидиятнең богауланмаган күңеле инде күптән бу көнче күбәләктән туеп, әнә шул матур йөзле, мөлаем холыклы Сабирага тартыла. Һәм моны икәү: Һидият үзе вә зәңгәр күзле инженер-программист кына беләләр иде. Әйтергә кирәк, аларның аралары көннән-көн якыная, ә ташып торган хисләре язгы Зөяне хәтерләтә иде. Хәер, җае чыкса, хатын-кызлардан баш тартмаган Фидан Шакирович та Сабира кебек сөйкемле сөякне бик рәхәтләнеп кимергән булыр иде дә... Күрәсең, ул Һидиятнең программисткага булган тойгыларын аңлап, бераз читтәрәк торды.

...Серле бу дөнья. Вә рәхимсез. Яхшы ирләрне пырдымсыз хатыннар эләктереп алалар да, ә Сабира кебек әүлияларга ир табылмый — гомер буе пыскып яшәргә туры килә. Иң җайсызы — еш кына ирләрне шул карачкыларыннан кәйлә белән дә куптарып алып булмый. Әллә аларга тәвәккәллек җитми, әллә гомер агышының кинәт борылыш ясавыннан куркалар. Ничек булса була, ирләр, йомычка кебек бер ярдан икенчесенә бәргәләнеп, сөяркә белән хатын арасында эсселе-бозлы халәттә яшәүләрен дәвам итәләр. Ә ул эгоисткаларның һәркайсы ирне 24 сәгать буе култык астына кыстырып, чүәк астына бастырып яшәргә өметләнә.

Һидиятнең дә әнә шундый газаплы, маҗаралы тормышы алда кебек иде. Хатын көнчелегеннән һәм күзәтүеннән, кесә тентүләреннән, допросларыннан гарык булган ир-атның командировкада үз-үзен ничек тотуы хакында тәфсилләп язып торасы да килми. Сәяхәттәге роман бу юлы да Таһир-Зөһрә, Галиябану-Хәлил мәхәббәтеннән әллә ни аерылып тормады. Тик шулай да сөю җимешләренең иң татлыларын авыз иткәч, Һидият нишләптер көнче хатынын, баласын искә төшерә башлады. Гәрчә гыйшык-мыйшык уйнаганда гүзәл Сабирасына: «Ташлыйм мин ул явызны», — дип кат-кат вәгъдә итсә дә. Командировкада кем белән булганны сизмәсеннәр дип, Һидият, Сабираны елата-елата, ике көнгә иртәрәк кайтып китте.

Менә таныш йорт. Өйдәгеләр сагынганнардыр инде... Абау! Нәрсә бу?! Фатир ишеген ачып җибәрүгә, коридордан ярым шәрә килеш, битен каплаган бер ир атылып чыкты һәм Һидиятне башы белән читкә сөзеп, баскычтан аска очты. Шул арада йокы бүлмәсеннән: «Кем бар анда, Фиданчик?» — дигән гадәти булмаган назлы, әмма бик таныш тавыш яңгырады. Әйе, Бәдрия иде бу! Буыннары кинәт йомшарган Һидият «лып» итеп бусагага утырды. Аның гарьләнгән йөрәген гомерендә беренче тапкыр көнләшү хисе урап алды...

## Суга сикермәгез!..

Кияүгә чыктым. Дөресрәге, чыкмадым, кияүне үзем алып кайттым. Елмаймагыз, җәмәгать. Хәзер ир-егет дефицит. Элек алар юлда аунап яталар иде. Ә хәзер утыралар... төрмәләрдә, энәләрдә, диваннарда, пивнушкаларда...

Ә монда мә сиңа — бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына. Ике кулыма ике сумка күтәреп базардан кайтканда, артымнан берәү килде дә әйберләремне күтәреп алды. «Беттем! Бандит!» — дип борылып карасам, ничава гына ир-егет елмаеп тора. Өйгә хәтле озатып та куйды. Әллә ни сөйләшеп тормадык.

— Өйләнгәнме?

Башын чайкый. Юк, янәсе.

Шулай базардан берничә тапкыр бергә кайттык та — тәвәккәлләдем. Кияүгә чыгу — суга чуму, диләр, йә батып үләсең, йә йөзеп китәсең. Керттем мин моны фатирга.

Иртән тора — дәшми-нитми ашый да диванга ятып телевизор карый. Кичкә кадәр. Вупчем, мужик как мужик.

Шулай күпмедер вакыт үтте. Теге ир дигән нәмәрсә сәеррәк кеше булып чыкты бит әле. Нигәдер бу миңа аркасы белән борылып йоклый. Ярый, мәйтәм, кыен булса да монысына түзик, утыз яшькә хәтле түзгәнне. Ә менә ир дигән кешенең сиңа кич буе бер сүз әйтмәве сәер генә түгел, авыр, апаем. Өйдә ың-шың юк, әйтерсең лә мәет алып чыгып киткәннәр... Аптырагач, кухнядагы попугай белән кереп сөйләшеп утырам. Без хатын-кызларга өйгә кайтып эчеңне бушатмагач — нинди тормыш инде ул! Базарда бергә сату итә торган Шәмсия дә килеп хәйранга калып китте.

— Нәрсә, бу немой мәллә? — ди.

— Ни твой, ни мой бу, — мәйтәм.

Бер кичне эштән кайтсам — бу ир кисәге, диванга кырын ятып, әлеге дә баягы телевизор карый. Кухняда өелеп савыт-саба ята, буш шешәләр, сигарет калдыклары.

— Бу нинди бардак?! — мәйтәм.

Дәшми. Телевизор каравын дәвам итә. Шулчак җен ачуларым чыкты. Тукта әле, мәйтәм, күрсәтим әле сиңа характерымны. Уклау алдым да сыптырдым тегеңәр берне.

Телгә килде бит, апаем. Алай гына да түгел. Нәкъ шул кичтән башлап бу күзле бүкән бөтенләй үзгәрде. Теле ачылгандай булды. Быкыл-быкыл бертуктаусыз теләсә нәрсә такылдый башлады. Күрәсең, уклаудан соң моның баш миендәге нindидер шөребе ычкынып китте.

Икенче көнне Шәмсия килеп бот чапты, тел шартлатты. Биш минут буена чыктым аркылы күперләрне тыңлагач, чыдамады: «Уф, косасыларым килә башлады. Лутчы дәшми утырсын бу, Фәүзия», — дип китеп тә барды.

Ә мин озак уйлап тормыйча, кухняга кереп, әлеге дә баягы уклауны алдым да тондырдым тегеңәр тагын бер кат. Тәртип! Тагын теге шөребе урынына утырды бугай. Шул көннән бирле ләм-мим.

Бер күпме вакыт узгач, уйлыйм, моны янә бер тапкыр телгә китереп сораштырырга кирәк. Кем бу? Күгәргән роботмы, тилергән психмы, хронический импотентмы? Моны ачыкламыйча булмый бит инде!

Һәм мин ничек итеп бу тинтәкнең башына тагын бер тапкыр уклау белән менеп төшәргә икән дип сәбәп эзли башладым. Тиктомалдан телевизор карап утырган кешегә сугып та булмый бит әле ул, апаем.

Чыкты моның җае. Бер кич базардан ачуым килеп кайтты. Милиция бер дә юкка штраф салып китте. Имештер, мин ике йөз грамм абвис ясаган. Һай, белсәләр иде алар башкаларның ничек хәрәмләшкәнен! Тишек герләр, ябыштыргычлар... хәер, боларын сөйләп тормыйм, йә арагызда берәр милиционер бардыр. Кыскасы, кайтып кердем. Өйдә караңгы. Утны элдереп, зал ишеген ачып җибәрсәм — менә сиңа сюрприз! Күзле бүкән бер яшь хатын белән кочаклашып телевизор карап утыра.

Әлбәттә, бу юлы уклауны яхшылап, ике мәртәбә кулланырга туры килде.

Марҗасы шешәдән чыжлап чыккан бөке сыман балконнан выжт итте. Ярый әле фатирым беренче катта.

Хәләл җефет шундук телгә килде:

— Башны тиштең бит, тәре!

— Ә-ә, телгә килдеңме, күзле бүкән?! Мин сине җансыз робот, импотент дип йөрим тагын. Ә син әнә нинди гайрәтле икәнсең әле! Үз хатының белән булдырмагач, урамнан сөйрәп керә башладыңмы, Хайван Иваныч?

Кыскасы, ул кичтә фатирда зилзиләләр купты, бураннар, давыллар котырды. Шуннан соң мин моннан ничек котылу юлын эзли башладым. Федот, да не тот бит, апаем. Үзең уйлап кара: фатирга керттем, ашый-эчә, әле тагын марҗалар ташый. Тот капчыгыңны! Ялтырат табаныңны! Чуртымамы миңа мондый бесплатное приложение!

Бер кичне өйгә тагын Шәмсия белән бергә кайттык. Ул көнне миңа санэпидстанция штраф салып киткән иде. Имештер, халатыңның төсен белеп булмый. Дальтониклар! Алар төс аермаганга мин гаеплемени? Шулай ярсып өйгә кайтып керсәк, бусагада ук каршыбызга, аракы-чеснок исләре аңкытып, теге ир актыгы килеп басты.

— Ну, таргашлар, акчагыз бармы? — ди бу, кызыл күзләрен акайтып.

— Бар, бар, — мәйтәм. Үзем кухняга таба атлыйм. Теге яхшы тәрбияли, кинәт иманга утырта торган коралны алырга иде исәп.

Ә уклау урынында юк. Адәм актыгы аны артына яшереп торган икән. Берзаман күздән гөлт итеп бүрек хәтле утлар чәчрәмәсенме! Бер гаепсез Шәмсиягә дә төште теге таяк. Мескен «разбой» кычкыра-кычкыра чыгып чапты. Ярый әле башы эшләгән, уклаудан соңдыр инде, милиция чакырткан. Берничә минуттан бусагада әзмәвер хәтле участковый пәйда булды. Ул миңа бу мизгелдә күктән иңгән фәрештә сыман тоелды. Уклау тоткан паразитны күргәч тә, участковый, әллә гаҗәпләнеп, әллә сөенеп:

— Ә-ә-ә, менә син кая кереп посткансың икән, Хосе-Хисамов! Ә без сине бөтен Рәсәй буенча эзләтәбез тагын! — диде ул һәм уклавы кулыннан төшеп киткән хулиганның «Не забуду мать родную!», «Хосе» дип язган татуировкалы беләкләрен богаулап бикләп тә куйды.

Әлбәттә, Шәмсия белән миңа аеруча куркыныч җинаятьчене эләктерүдә ярдәм иткән өчен милиция мактау грамотасы бирде. Ләкин иң мөһиме — мин дә, Шәмсия дә бер нәрсәне тагын бер кат яхшы аңла-

дык: кияүгә чыгу — текә ярдан суга сикерү белән бер икән, җәмәгать. Кызлар, сезгә әйтәм, җанкайларым, зинһар, сикермәгез. Суга ипләп тә кереп була, озак та йөзеп була бит...

## Разборка

Бер мәҗлестә шактый гына кызып алган чал чәчле ир уртасы, күрәсең, үзенең татар икәнен искә төшереп:

— Давай «Алмагачлары»н! — дип кинәт кычкырып җибәрә.

Нигездә урысча барган бу интернациональ мәҗлестә баян төймәләрен санаучы Вадим:

— Я по-татарски не играю, — дип җавап бирә.

Ә чал чәчле абзый, әллә үтә дәрәҗәле, әллә бик үҗәт кеше булганга, залны күздән кичереп, прокурорларга хас тавыш белән:

— Ә кем уйный?! — дип сорый.

Кунаклар арасыннан бер җирән чәчле яшь егет күтәрелеп, Вадимга таба кулларын сузып:

— Давай инструмент, сбацаю! — ди.

Тик бу кичтә татарча гармун шыңгырдату насыйп булмаган икән. Баянны кулдан-кулга биргәндә, ул, гравитация кануннары нигезендәме, әллә уйнаучыларның хәмердән буыннары йомшаргангамы, шап итеп идәнгә килеп төшә. Бүлмәдәге халык беравыкка тынып кала.

— Ачыгавыз, пешмәгән! — дип кычкыра баян хуҗасы беренче мәлгә югалып калган җирән чәчле егеткә. — Ул бит концерт баяны! Беләсеңме аның күпме торганын?!

«Алмагачлары»н басмырлап сораган абзый янә сүзгә кушыла:

— Җегетләр, баян баш түгел... Соңыннан разберемся...

Алмагачы чәчәк а-ата-а...

Озакламый мәҗлес тәмамлана, бәйрәмдарлар таралыша, ә ат бәһасе торган кәнсирт гармунының язмышы хәл ителмичә кала. Баян хуҗасы, эшне озакка сузмыйча, хакыйкатьне табу йөзеннән танышлары аша бер «текә»гә мөрәҗәгать итә.

Әйтергә кирәк, крутойлар хәзер еш кына мировой судья вазифаларын башкаралар. Хакимият оешмалары бутап бетергән бюрократик кроссвордларны ансат кына чишеп куялар. Ә аларның карарын үтәми кара! Кыскасы, «текәләр» икенче көнне үк баян мәсьәләсе буенча разборка җыярга әмер бирәләр.

Җирән чәчле егет тә, асфальтта үскән Казан малае буларак, «югары» дәрәҗәдәге сөйләшүләргә үзенең «текәләрен» ияртеп килә. Шул ук мәҗлес узган клубта Казанның иң «текә» ике төркеме бер пүчтәк нәрсә буенча җыела. Җитмәсә, алар, этле-мәчеле яшәп, мондый корылтайлардан көпшәләрдән һавага булса да атмый гына таралышмыйлар икән.

Гадәттә разборкалар, бәхәсләр йә затлы джиплар, кәттиджләр, йә зур кредитлар тирәсендә барса, бу юлы көн тәртибенә бик үзенчәлекле һәм «ля» нотасы белән «до»ны аермаган крутойлар алдында ифрат четерекле мәсьәлә килеп баса.

Ике төркем дә җыелгач, бүлмәгә прокурор кебек салмак кына атлап «текәләрнең» башлыгы килеп керә. Аны күреп, мәҗлестә низагка кергән ике баянчы да сүзсез калалар. Ул әүвәлге кичтә «Алмагачлары»н җырларга ниятләнгән ак чәчле абзый булып чыга.

Иң хикмәтлесе — паркет белән очрашканнан соң да баян әле уйнарлык һәм көй чыгарырлык хәлдә була. Беренче булып моны татар баянчысы исбатлап бирә. Ул озак уйлап тормый «Алмагачлары»н суздырып җибәрә. Кушымтасын «текә» абзый:

Эх, алмагачлары, сайрый сандугачлары, —

дип җибәргәч, җыелганнар кул чаба башлый.

— Әйдә, хәзер син тартып җибәр! — дип әмер бирә башлык, Вадимга ымлап.

Вадим башкаруында «Шаланды, полные кефали» көе дә алкышлар белән кабул ителә.

Инде җирән чәчле егет һәвәсләнеп «Аерылмагыз»ны уйный башлагач, ике як «текәләре» дә баянчыга кушылып җырлап җибәрәләр. Чөнки араларында шул шлягерны яшьли ишетеп-җырлап үскәннәр дә байтак икән. Кайберәүләрнең күзләре дымланып, кайсыларының кырыс йөзләрендә гомерләрендә тәүге тапкыр сагыш-сагыну хисләре күренеп китә. Кемдер разборкалардан соң бу фани дөньядан бик иртә киткән дустын юксынып, кайсыдыр яндырылган джипларын, кәттиджләрен искә төшереп, моңланып утыралар.

Баян тавышы тынгач, чал чәчле «текә» абзый, ике ягында утырган коллегалары белән киңәшеп алып:

— Инструмент әйбәт, уйнарлык. Вак-төякләрне баянчылар үзара хәл итсеннәр, — дигән карар игълан итә.

Барысы да җиңел сулап куялар һәм гомерләрендә беренче тапкыр коралларын кесәләреннән чыгармый гына таралышалар.

Дөрес икән ул: музалар уйнаганда, туплар дәшми тора!..

## «Террорчылар»

«Чуртым-пыртым» дигән матур исемле күмәк хуҗалыкның еллык җыелышы шома гына ахырына якынлашып килә иде. Тракторчы Гайфетдин: «Аллага тапшырдык!» — дип, урыныннан кузгалды һәм, президиум өстәле янына килеп, нindидер кара пакетны хуҗалык рәисе Сафиян Хазиевичның борын төбенә куйды.

— Бу нәрсә? — дип акайды рәис, пакетка ымлап.

— Бу — бомба! — дип җавап бирде тыныч кына Гайфетдин һәм, кинәт залга борылып: — Җәмәгать, урыннарыгыздан кубасы булмагыз! Монда бернинди шаяру юк! Берсе аның минем билдә, ә икенчесе залга куелган, урамда минем кешеләр тора! — дип кычкырды. Эшнең җитди икәнен раслар өчен, ул, пинжәген ычкындырып, билендә бүлтәеп торган кара пакетны күрсәтте: — Кабатлап әйтәм: селкенмәгез, әгәр дә яшисегез килсә!

Президиумда утырганнарның бигрәк тә яшиселәре килә иде, ахрысы — алар бөтенләй коелып төштеләр. Залдагылар ышаныргамы-юкмы дип гаҗәпләнеп-куркынышып торган арада, заманында армиядә минер булып хезмәт иткәнгә Минер кушаматын йөрткән Гайфетдин трибуна артына ук менеп басты. Һәм корыч тавышы белән нотык тотты:

— Менә шулай, җәмәгать, хисап җыелышын дәвам итәбез. Тә-әк, хәзер рәис иптәш бирегә пыркарурны чакырта. Үзе белән бергә берәр журналистны да алып килсен. Видеокамера белән. Аңлашылдымы?

Сафиян, кабалана-кабалана, калтыранган бармаклары белән өстәл өстендәге телефоннан прокурорга шылтыратты, көч-хәл белән Минер Гайфинең әмерен җиткерде.

— Все! — диде Гайфетдин һәм кайдандыр пычак тартып чыгарып телефон чыбыгын кисеп ташлады. — Минем сүздән чыксагыз, бина шайтаннар оясына очачак. Бу — әмер! Аңлашылдымы?

Ун минут та үтмәде, минерның беренче әмере гамәлгә ашты. «Пых-пых» килеп залга район прокуроры тәгәрәп керде. Аның артында видеокамера күтәргән бер яшь егет пәйда булды.

Гайфетдин, бераз аңга килеп, шаулаша башлаган залга карап алды һәм, тәрәзәгә якынаеп, уң кулын күтәрде:

— Тынычланыгыз! Мин шаяртмыйм!

Шулчак урамда көчле шартлаган тавыш яңгырады, тәрәзә пыялалары зыңлап китте. Кайсыдыр куркуыннан өстәл астына чумды, кемдер идәнгә йөзтүбән капланды, кемдер елап җибәрде.

— Инде хәзер, Сафиян әфәнде, пыркарур алдында хисап тот һәм безгә фигли-миглисез генә җавап бир: нишләп безнең хуҗалык төпсез чуманда утыра, безнең акчалар кая китә, нигә халык яртышар ел зарплатасыз интегә?

Тәмам кыйбласын җуйган Сафиян Хазиевичның теле телгә йокмады:

— Гайфете... д... дин әфәнде м... менә безнең хисап...

Тракторчы рәис сузган хисап кәгазен алды һәм ертып ташлады.

— Бу ялган әкиятеңне борын тишегеңә тыгып куй! Син безгә дөресен сөйләп бир. Давай кәттидженңнән башла... Нинди акчага салдырттың аны?

Сафиян Хазиевич шабыр тиргә батты.

— Ни бит, Гайфетдин якташ, б... баҗай, әйе, баҗай акчасына инде...

Гайфетдин, карчыга кебек, залны күздән кичерде.

— Кая Самат? Ну-ка, әйт әле, булыштыңмы моңа кәттидж салырга?

Самат ни әйтергә белми озак дәшми торды. Ләкин Гайнетдиннең билендәге пакетка сузылуын күрүгә тезеп китте:

— Үзегез беләсез, җәмәгать, каян килеп миндә акча булсын... Сәмән аларда инде ул, Гайфи кордаш. Ә кәттиджен әби исеменә яздырды ул!

Шул рәвешчә югалган акчаларның язмышын ачыклый-ачыклый, җыелыш эшен дәвам итте. Тиз арада әллә ничә ат бәһасе торган джипның нинди акчага алынуы, кем исеменә язылуы да мәгълүм булды. Рәиснең секретарша Рәмзия белән хуҗалык акчасына һәр елны Кара диңгез буенда типтерүе дә, улының чит илдә белем алуы да авылдашлар алдында беренче тапкыр ачык итеп расланды. Гайфетдин басымы астында Сафиян Хазиевич үзен алма урлап эләккән карак кебек тотты.

Рәиснең хисабын прокурор да йотлыгып тыңлады. Ул әледән-әле башын чайкап, блокнотына нәрсәдер сызгалап барды. Халык, бер мәлгә бомба өстендә утыруын онытып, «Долой!», «Безгә мондый җитәкче кирәкми!» дип кычкыра башлады.

Гайфетдин тәрәзә янына килеп кулын күтәрүе булды — урамда тагын гөрселдәгән тавыш яңгырады. Тәрәзәләр зыңлап куйды. Халык шундук шып булды. Минер Гайфи хуҗалык рәисен кешеләр каршында җайсыз сораулары белән тәмам чишендерде, соңгы ун ел эчендә кылган кыңгыр гамәлләре турында бәйнә-бәйнә сөйләттерде. Халык детективны хәтерләткән бу хикәятне ах-вах килеп тыңлап утырды.

Шуннан соң Гайфетдин җиңел сулап трибуна артыннан чыкты һәм прокурорга мөрәҗәгать итте:

— Мин бирелəм, хәзер кулга алсагыз да була...

Шул ук мизгелдә залга ишек-тәрәзәләрне ватып, баштанаяк коралланган милиционерлар бәреп керде.

Куркуыннан өстәл артына чумган Сафиян Хазиевич, Гайфигә күрсәтеп:

— Сак булыгыз, коралланган ул, билендә бомбасы бар! — дип кычкырды.

Милиционерлар Минерның кулларын борып, богау салдылар, биленнән «шартлаткычын» йолкып алдылар. Халык җиңел сулап куйды.

Куллары артка каерылган Гайфетдин, канаты сынган кош сыман тыпырчына-тыпырчына, милиционерларга:

— Мин кая да качмам, егетләр, главный каракны ычкындырмагыз! — дип кычкырды.

Минер-террористның соңгы сүзе исәпкә алынмады бугай, чөнки хәзер дөньясы шундый: гадәттә Сафиян Хазиевич кебек шома кешеләр судан да, уттан да, судтан да исән-сау котылалар.

Бу юлы да хокук сакчылары террорчылыкны караклыктан күпкә куркынычрак дип бәяләделәр. «Чуртым-пыртым»ның рәисенә чуртым да булмады.

Ә менә Гайфетдин һәм аның сигналы буенча урамда ике шартлау оештырган Сәйфетдингә лаеш шулпасын байтак чөмерергә туры килде. Гәрчә шартлаткычлар йомычка тутырган ике кара пакеттан вә Яңа ел кичендә кулланыла торган Кытай петардаларыннан гыйбарәт булса да...

## Сукыр тавык

*(Бер мәхәббәт тарихы)*

Туй машиналарына диңгез тубыктан дигәндәй, җилдертәләр генә шәһәр урамнары буйлап. Күз иярми торган тизлек белән. Әйтерсең лә йөзләгән чакрымга бер җан иясе очрамаган сафарида ярышучы раллимастерлар. Тизрәк өстәл артына кунаклап чөмерергә ашыгалар, сукыр җаннар!

Инде күптән буйдак язмышын сайлаган Минһадый мондый кортежларны күргән саен әнә шулай сүгенеп кала иде. Куштаннар! Җитмәсә, өйләнеп өлгермиләр, аерылыша башлыйлар! Бу юлы Минһадый әллә бераз уйланып калды, әллә саксызлык күрсәтте, ә бәлкем, руль артында утыручысы ачыгавыз булгандыр — машина астына эләкте. Аның күз аллары караңгыланып китте... Аңына килеп күзләрен ачканда, Минһадый тирәсенә кешеләр җыелган иде.

Кемдер, җиңел сулап:

— Аллага шөкер, исән! — диде.

Кайсысыдыр Минһадыйның кулын-аягын капшап карады.

— Исән бит!.. Сезгә больномы? — Зәңгәр күзле бер матур туташ аның чәчләрен сыйпады. — Аягыгызга баса аласызмы?

Якында гына бер яшь гаишник күренде. Матур хатын аны ярдәмгә чакырып, алар икәүләп Минһадыйны аякка бастырырга тырыштылар. Ләкин бәлагә юлыгучы уң аягының авыртуына чыдый алмый «һай!» дип янә асфальтка утырды.

— Все, егетләр, мин калам... — диде матур хатын туй кортежыннан чыкканнарга. — Аны больниска илтергә кирәк...

Бераз тарткалашып-үгетләшеп торгач, туй кунаклары, машина ишекләрен шалт-шолт ябып, китеп тә бардылар...

Ә бәйрәмчә киенгән зәңгәр күзле туташ һәм милиционер Минһадыйны хастаханәгә озата киттеләр. Мондый ягымлы хатын-кызны тайпылмас буйдак гомерендә беренче тапкыр күрде. Хәер, баштарак үзләре имгәткән кешегә зур игътибар күрсәтәләр инде ул... Ә аннары — син күр дә мин күр... Беләбез без хатын-кызларны... Минһадый тирәсендә бөтерелгән нәфис карлыгачның исеме Рәмзия булып чыкты.

Инде кич тә җитте. Гаишник саубуллашып китеп барды. Шәфкать туташы берничә кат өенә кайтып китәргә тәкъдим итсә дә, Рәмзия хастаханәдә калды. Төн буе Минһадыйны саклап, карап чыкты.

Үзе турында тәфсилләп сөйләде. Кияүгә китмәгән, шәһәр кызы. Балалар табибәсе. Әтисе машина алып биргән, рульдә бер генә атна. Фатиры бар...

Ә Минһадый артык шапырынмады. Хәер, мактанырлык нәрсәсе дә юк иде бит аның. Институт тәмамлап унбиш ел буе бер урында түнгәк кебек утыра. Төзелештәге прораб. Получкадан авансак очын очка ялгап көн күрә. Тулай торакта бүлмәсе бар. Һәм тагын бер байлыгы — кырыкка җиткән яше бар. Шулхәтле яшәп чын-чынлап җылы кочак, татлы ирен тәмен тоймаган ир сыныгы. Бер-ике тапкыр хатын-кыз тарафыннан нык алданып төп башына утыргач, Минһадый аларга ут сүндерүче пожарга караган кебек карый башлады.

Соңгысы Нәҗия булды. Бергә эшләп дуслашып йөрделәр. Эш өйләнүгә борыла башлагач, Нәҗия чыгымчы ат кебек тәртәгә типте... Имеш, фатирың юк, машинаң да булырга охшамаган... Китте. Менә шул көннән бикләде дә инде Минһадый йөрәген. Все! Әнә бар Азат дусты, Самат якташы. Җиткән. Вакытны да кызык уздыралар. Йә балыкка ычкыналар, йә аугa. Кайчак авылга кайтып китәләр. Язмаган тек язмаган...

Шулай да табигать дигән нәрсәкәй үҗәтләнеп үзенекен исбатлый, ахрысы. Рәмзиянең атна буе үз баласын караган кебек янышнан китмичә утыруы Минһадыйның хатын-кызларга булган бозлы карашын бераз эретә башлады. Күрәсең, барысы да бер себерке белән куылмаган болар. Кырык елга бер җүнлесе дә очрап куярга мөмкин...

Күп тә үтмәде, Минһадый аякка басты. Һәм бу, әлбәттә, аның йөрәгенә кереп оялаган Рәмзия ярдәме белән булды. Кыскасы, аның бозланып каткан күңеленә беренче тапкыр яз килде. Һәм аны бердәнбер карлыгач китерде...

Син мәхәббәттән качасың, аны юк, ул пүчтәк дип кул селкеп, йөрәк клапаннарына йозак эләсең, сөюне тормышның башка гүзәллекләренә алыштырырга тырышасың. Ә ул, үч иткәндәй, киресен эшли. Бер билгесез көч синең дөньяңның астын өскә китерә башлый. Алай да аңламыйсың икән — машина астына ташлый. Теләсәң ничек очраштыра. Нәтиҗәдә кулларыңны күтәрәсең. Рәхәт җиңелүдер ул! Кемнеңдер сине иртәнге җылы җил кебек назлавы, тирән мәгънәле сүзләр, күңелне җилкендереп алган серле карашлар, өмет иңдерә торган елмаюлар. Дөнья матур, дөнья киң икән ул!

Инде тәмам мәхәббәтнең барлыгына ышанган, иңнәренә көчле канатлар үсеп чыккан Минһадый буйдаклыктан ваз кичәргә ниятләнеп йөргән чакта, кинәт...

Горизонтта Наҗия пәйда булды. Ул, башкага чыгып, лаеш шулпасын байтак чөмергән икән. Һәм дөньяны аңлаган. Бер кичне башын иеп Минһадый хозурына килеп гафу үтенде, үзенең нинди михнәтләр күрүен тәфсилләп сөйләде. Кульяулык чылатты. Тел төбе шул иде: әйдә, дустым, искене онытып, яңадан башлыйк.

Минһадый мондый борылышка бөтенләй әзер түгел иде. Шуңа да ул яшереп-нитеп тормады:

— Ә мин бит башканы яратам, Наҗия... Соң инде...

Наҗия Минһадыйның муенына килеп асылынды.

— Юк, юк, мин сине беркемгә дә бирмим!

Шулчак Наҗия яшьле күзләре белән телевизор өстендә торган зур төсле рәсемне күреп алды. Ул кинәт үзгәреп китте.

— Ничек?! Рәмзия! Шулмы җанкисәгең?!

Минһадый Наҗияне кәнәфигә утыртты.

— Әйе, әйе, Рәмзия. Без тиздән өйләнешәчәкбез. Ул бик яхшы кеше...

Наҗия кинәт шаркылдап көлеп җибәрде:

— Кем, Рәмзияме? Син беләсеңме соң аның ничәнче ире булачагыңны?

— Беләм. Беренчесе!

— Һай, кеше көлдермә, Минһадый. Мин белгәне генә өчәү иде...

Минһадыйның өстенә бер мичкә кайнар су аудардылар диярсең!

— Ул әле... ни дә бит... табибә...

Наҗия әңгәмәдәшенең сүзен шундук бүлдерде:

— Нинди табибә?! Шлюха! Без бер тулай торакта тордык. Штукатур ич ул! Аның йөрмәгән егете калмады. Әйтсәм әйтим: фахишәлектән акча эшләп баеган чикерткә бит ул!..

Минһадыйның өстенә инде бер мичкә бозлы су койгандай булды.

— Җитте! — дия алды ул, актык көчен җыеп. — Җитте! Алайса, берегез дә кирәкми!..

Минһадый, пыш-пыш тәмәке тартып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренде. Шул вакыт тәрәзә каршына машина килеп туктады. «Рәмзия!» дип уйлады Минһадый һәм тиз генә тәмәкесен сүндерде. Ул арада ишектә кыңгырау шылтырады.

Бүлмәгә әйтерсең лә якты кояш балкып керде, тирә-юньгә шомырт исе таралды.

— Хәлләрегез ничек, Минһадый абый? Шөкер Аллага, савыккансыз икән! — Рәмзия җавап көтеп тормый дәвам итте: — Мин сезгә Радик белән икебездән туебызга чакыру китердем. Килегез инде, яме? Сезнең аркада танышкан идек бит. Әнә теге чакта. Гаишник ул... Йә, ярый, көтәбез...

Ишектәге кояш тәгәрәп чыгып та китте. Бүлмә караңгыланып калды. Рәмзияне бары тик шомырт исләре генә хәтерләтә иде.

«Сукыр тавык икән мин!» Әнә шундый фикер Минһадыйның телгәләнгән күңелен чәнчеп узды.

## Влач бар ул!

Кыяфәте, үз-үзен тотышына караганда, әллә сукбай, әллә берничә көн рәттән денатурат чөмергән, башына эт талагандай кепка чәпәп куйган абзый автовокзал янында шундый ук арбадан төшеп калган, сәләмә шинель кигән берәү белән гәп сата.

— Тә-әк, атаңның ботинкасы, колхозлар инде юк, дисең... Ә присидәтелләр кая китте?

— Кая китсен! Колхоздагы сатарлык нәрсәне сатып, шәһәрләргә китеп, кәттиджләр салдырдылар.

— Да-а, — дип гаҗәпләнде кепкалы абзый, авызыннан аңкып торган искә үзе дә чыдый алмыйча, кайдандыр бер төпчек табып, шуны көйрәтеп җибәрде.

— Силсәвит тә юкмы?

— Кайдан килеп?

— Соң, нинди дә булса влач бармы соң, бабаңның сучинкасы?!

— Ә-әнә агач башындагы каргадан сора! Кемдә акча, влач шунда хәзер, белдеңме, әбиеңнең тапочкасы.
— Райкум-парткумнар да юкмыни инде хәзер, идрит-садрит?
— Күптән инде, идрит-кудрит!
— Сикритарлар кай тарафта?
— Алары да җылы урыннарда.
— Да-а... Ә соң сез, халык, ничек яшисез мондый тормышта, шайтанның чабатасы?
— Менә шулай яшибез инде. Кемдер яши, кемдер пыскый... Ә-әнә күрәсеңме чүплекне? — Шинельле сукбай тимер әрҗәгә төртеп күрсәтте. — Беренче әтәчләр белән шунда килсәң, нәрсә дә булса табарсың. Ботинкасын да, кәвешен дә, галушын да, күгәргән ипиен дә...
— Эт тормышы икән алайса!
— Ә син соң үзең кайдан? Бер дә Әмрикәдән кайткан кешегә охшап тормыйсың әле, кодаңның сандалие!
Махмырдан башын кая куярга белмәгән абзый ияге белән ТЭЦ трубалары күренеп торган горизонтка ымлады.
— Тегеннән...
— Нәрсә, качигар штули?
— Тинтәк син! — диде кепкалы сукбай, янә бер төпчекне көйрәтеп җибәреп. — Төрмәдән! Унбиш елымны тутырып чыктым...
— Шулаймыни? — дип гаҗәпләнде шинель кигән сукбай.
— Мондагы тормышны бөтенләй аңламыйм — үзгәргән дөнья, нык үзгәргән!.. Тегендә хет көненә өч тапкыр ашаталар, киендерәләр иде. Чөнки анда влач бар... Ишо какуй!
Ирекле тормышта үзен судан тартып чыгарган кәрәкә кебек хис иткән абзый, төрмәдәге җәннәтне исенә төшереп, тирән сулап куйды һәм як-ягына карангалап алды.
— Йә, ярый, әйдә киттек!
— Кая киттек?
— Киттек, киттек, болай яшәп булмый.
Төрмәче әңгәмәдәшенең җиңеннән әләктереп, аны ашамлыклар сата торган ларекка таба сөйрәде. Ни сәбәптәндер сәүдә ноктасы ябык булып чыкты. Ләкин төрмә михнәтләрен кичереп чыныккан кеше өчен мондый вак-төяк һич тә киртә булалмады. Ул аяк астында яткан ике учка сыярлык ташны күтәреп алды да утлары балкып торган ларекның тәрәзәсенә томырды.
— Нишлисең?! — дип кычкырды шинельле абзый. — Һәм, куркуыннан кая качарга белми, уңга-сулга бәргәләнде. — Бетерәләр бит безне хәзер!..
— Җебемә! — дип ысылдады рецедивист. — Хәзер хет бер туйганчы ашарбыз!
Ларекка яртылаш тыгылып, төрмәче агай киштәдән бутылкалар-консервларны — кулына нәрсә эләгә, шуларны җиргә сыпырып төшерде.
Ул арада сиреналар улый башлады. Озак та үтми, җинаять кылынган җиргә милиция машинасы килеп туктады.
— Йөгерик! — дип кычкырды шинельле сукбай. Михнәтле булса да, ул ирекле тормыштан колак кагарга һич кенә дә теләми иде. Ләкин төрмәче аны нык тоткан.
— Тик тор! Без хәзер бер җептә, брат. Күмәк җинаять.
Берничә минуттан ике сукбай да милиция машинасында утыралар иде.
— Ә син, влач юк, дисең! Бар ул, брат, бар! — диде беренче сукбай, ниндидер бер канәгатьлек хисе белән. Һәм кузовта утырган милиционерларга ымлап өстәп куйды: — Ә инде влач безне ач-ялангач калдырмас!

## Интервью

Яңа ел алдыннан һәр каләм иясе тирләп-пешеп саллы әңгәмәдәш эзли башлый. Чөнки бәләкәй генә гәҗит тә Яңа ел санында укучыны аяктан бәреп егарлык мәкалә бастырырга тырыша. Ел буена без абруйлы, дәрәҗәле, атаклы, исемле, кызыклы әфәнделәр вә ханымнарны ишетеп, күреп торабыз. Ә менә гап-гади берәр кешенең чыгыш ясавы истә калмаган. Иске елның соңгы көнендә шундый бер инсан белән әңгәмә корасы, аның фикерләрен халыкка бик җиткерәсе килгән иде. Хәер, озак эзлисе дә, ерак барасы да булмады. Андый кеше — Сәрвәр абый, күршемдә генә яши. Һөнәре дә гап-гади — урам себерүче, ягъни дворник. Яңа ел кичендә аның ишеген шакыдым.
— Әйдә, күрше, түрдән уз! Утырып садись! — диде хуҗа абзый. — Бик сирәк керәсең!
Мин бер-ике сүз белән йомышымны аңлаттым.
Сәрвәр абый, хәйләкәр елмаеп:

— Интервью алырга кердең алайса. Ә гонорарың кайда? — дип сорады.

Анысы минем пакет төбендә иде. Тел чиштергечне өстәлгә бастыруым булды, Сәрвәр абый ялт итеп ипи белән колбаса һәм ике чәркә тартып чыгарды.

— Интервью ул, агайне, серьезный нәрсә, — дип сөйләнә-сөйләнә себерке хуҗасы рюмкаларны тутырды.

— Әйдә, күрше, Яңа ел белән!

— Башлап искесен озатыйк инде, — дип төзәттем мин чәркәдәшне.

— Да-а, алай да була. Тә-әк. Узган елда нәрсәләр булды, дисеңме? Күп нәрсәләр булды, агайне. Яз давай!

Мин, Сәрвәр абыйның фикерләрен кәгазьгә төшерергә әзерләнеп, кулыма блокнот һәм каләм алдым.

— Яз! Бүген зарплата бирделәр! Влачка рәхмәт!

— Менә бит! Яхшы эш!

Сәрвәр абый икенче рюмкага үрелде.

— А какжи! Өч ай акчасыз утырып кара әле! Берьюлы тоттыргач, кадерлерәк була икән ул зарплата дигәннәре! Тә-әк... Дальше яз. Бүген Хәмидә апаң мине ташлап китте. Абыйсы янына, авылга. Записка язып калдырган... Монысы да зур вакыйга... Күтәрәбезме?

Өченче рюмка һәм бутерброд урынына төшеп утыргач, мин әңгәмәдәшне серьезныйрак темаларга борырга булдым.

— Сәрвәр абзый, көнкүреш, хезмәт хакы — болары таныш, болары аңлашыла. Монысы белән күбебез интегә... Ә менә, әйтик, син сайлауларга йөрисеңме?

— Ни в какоем случае! — диде күрше, катгый тавыш белән. — Сайлаулар безнең өчен зур расход, сущи җәза ул! Беләсеңме алардан соң күпме чүп-чар, кәгазь җыештырырга туры килә! Җитмәсә, сайласаң-сайламасаң да, кемне кирәк, шуны уздыралар...

— Әмма сайлауларсыз да ярамый бит, Сәрвәр абзый! Демократия!

— Ник булмасын? Менә мин үз эшемдә махир, ул эштә дә мастерлар күп хәзер. Сайлаулар, беләсеңме, кемгә кирәк ул? Егет белән кызга. Гаилә корыр өчен. Анда инде, брат, махинацияләр үтми...

Сәрвәр абзый кандалаларны өйдән качыра торган ниндидер әчкелтем усал тәмәке көйрәтеп җибәрде. Сүз җитәкчеләргә күчте. Иске елда күрше аларны тагын да хөрмәт итә башлаган икән.

— Ни өчен? — дип җанландым мин, андый хөрмәтнең нәрсәгә нигезләнүен аңларга тырышып.

— Чөнки алар хәзер минем участокта яшәмиләр. Яңа кәттидж, элитный йортларга күчеп беттеләр. Ун ел буена мин окоптагы солдат кебек боевой тревогада яшәдем, понимаешь...

— Ярый, — мәйтәм, — Сәрвәр абзый, ә менә реформалар, бәяләр турында фикерең ничегрәк?

Күршем тагын шешәгә үрелде.

— Тут, брат, без бутылки не разбирусь... Бәһаләр үсә. Алабута кебек. Элек влач әдәплерәк иде. Бәяләрне биш елга бер тапкыр биш прасинтка күтәрәләр иде и все! Хәзер елына ике-өч тапкыр. Бигрәк тә фатир өчен түләүләр! Билдән түбән тибәләр инде, валлаһи! Шалт — утыз прасинт, шалт — илле прасинт! Сувис аларда — ноль прасинт!

Әңгәмәдәшем сөялле бармаклары белән өстәлдә барабан какты.

Мин дә инде шушы авырткан җирне кашымасам... Сәрвәр абыйның шайтан таягы кебек гөрләп үскән бәяләр турындагы озын вә тозлы-борычлы монологын сезгә тулысынча җиткерергә уңайсызланам, җәмәгать. Хәер, кайсыгызның, кадерле ватандашлар, иске елда, кибетләргә кереп, яңа бәяләрне, почта әрҗәсеннән чыккан утка, суга, газга, телефонга түләү кәгазьләрен күреп, андый монологларны сөйләгәнегез йә ишеткәнегез булмады?!

Сәяси фиркаләр хакында Сәрвәр абзый бик кыска гына:

— Мин — анархист. Теләсәм, урамны буйга себерәм, теләсәм, аркылыга, — дип, симпатиясен нык дәлилләде.

— Карале, латин имлясы турында ни уйлый икән гади халык вәкиле?

Шул хактагы сорауга Сәрвәр абзый гел бишлегә укыган мәктәп баласы кебек чатнаттырып җавап бирде:

— Күптән күчәргә кирәк иде... Ун ел элек! Мәскәүләрдән рөхсәт сорап йөрсәң, шулай була инде ул... Без, мәсәлән, Төркиядә яшәүче киявебез белән латинча язышабыз. Чөнки минем бар укыганым — 5 класс та коридор — латин имлясында булды...

— Ярый, абзый, синең уй-фикерләреңне аңладым. Әйдә инде хәзер Яңа ел хакында бер-ике сүз әйтеп җиффәр әле!

— Башлап яшәп карыйк әле, аннары...

Кем белә, безнең кызыклы әңгәмәбез беренче әтәчләргә кадәр дәвам иткән булыр иде... Әгәр дә мәгәр ишек ачылып, бүлмәгә Хәмидә апа һәм аның белән бергә авылча киенгән бер ак сакаллы карт килеп кермәсәләр. Сәрвәр абзый аларны күрүгә бөтенләй айнып китте, үрә катты.

— Менә сиңа Кыш бабай һәм Кар кызы! — диде ул сүзен-сүзгә ялгый алмый. — Өнемме бу, төшемме... Син бит «авылга киттем» дип записка язып калдыргансың!

— Ә син, опилка баш, аны күзеңне ачып укымагансың! Мин бит «авылдан абыйны каршылырга киттем» дип язган идем, хәчтерүш!

Мин әкрен генә ишеккә таба елыштым. Сәрвәр абый арттан кычкырып калды:

— Гонорарың өчен рәхмәт, энем! Тагын кер. Интервью алырга...

## Ярый әле...

Миләүшә — болай да пешкән кура җиләге — иртән буянып-ясанып, кыска итәкле модный күлмәген киеп, эшенә китте. Һавада яз, кошлар сайрый, кояш иркәләп-балкып тора. Нигә җәяү тәпиләмәскә?!

Мондый алиһәнең шәһәр урамында күренүе, йомшак итеп әйтсәк, үз юлы белән уянып кына килүче гадәти шәһәр тормышына кинәт җанлану кертте.

Урам себерүче абзый тал чыбыгы кебек нечкә билле чибәркәй артыннан себеркесенә таянып озак карап торды. Аннары, үзе дә сизмәстән, әрҗәгә төяргә әзерләнгән чүп-чарны тротуарның икенче ягына таба шудыра башлады.

Күрше йортның подъезд ишеген беркетеп маташучы егет тә Миләүшәне күреп илтифатын җуйды булса кирәк. Балта остасының кинәт кычкырып җибәрүе вә кадак урынына баш бармагына чүкеч белән сугуы әнә шул хакта сөйли иде. Бик сүгенәсе килсә дә, шундый чибәр кыз узып барганда, егет, авыртуын сиздермәскә тырышып, телен тешләде һәм үзе ишетелерлек кенә итеп ыңгырашып куйды.

Тыкрыкка җитәрәк, Миләүшәнең төз аякларына карап мөкиббән киткән тәрәзә буяучы ир уртасы да, дөньясын онытып, пыялаларны зәңгәр төскә буйый башлады.

Кыска итәкле гүзәлкәйнең тыкрыктан үтүен күзәтеп, юл кагыйдәләрен оныткан ике иномарка шоферы рульне ташламый гына бер-берсе белән «кочаклашып үбештеләр». Нәтиҗәдә тыкрыкта «пробка» хасил булды. Иномарка хуҗалары — яңа урыс белән яңа татар билләреннән мобильникларын тартып чыгарып, кай тарафларгадыр шылтырата башладылар.

Ярый әле Миләүшә якында гына эшли иде. Югыйсә урамдагы шәһәр техникасы белән идарә итүче ир-егетләр, мондый гүзәллекне күреп, башларын җуеп, тагын әллә нинди техноген казалар ясап ташларлар иде.

Ярый әле Миләүшәнең искиткеч гүзәл кыяфәте, балериналарча хәрәкәт итүе бергә эшләгән хезмәттәшләренә алай тәэсир итмәде. Чөнки ул эшләгән хатын-кызлар чәчтарашында андый алиһәләр атлаган саен очрап тора иде...

## Язып кара!

Фельетончы Сәгыйть авырып киткәч, гәҗитнең баш редакторы очерклар махиры Газизҗанны чакыртты.

— Агайне, заманалар кырыс, халык авыр яши хәзер. Давай, брат, кызыклы-мәзәкле усалрак нәрсәкәйләрне язып кара әле...

Гадәттә тонналар, литрлар, үтәлгән йөкләмәләр турында язганга, Газизҗан бераз аптырашта калды. Яхшы кешеләр, матур күрсәткечләр турында язу — бер нәрсә... Ә фельетон, тәнкыйть... Тырышсаң, эшләмәслек эш түгелдер, әлбәттә. Аласың мәзәк, кем әйтмешли, саласың кәстрүлгә, су кушасың, болгатасың, кайнатасың, тозын-борычын өстисең дә — менә сиңа фельетон!

Шулаен шулай да, икенче ягы бар шул каһәрнең: шырдый-бырдый, усал нәрсә язып бирәүнең ачуын китерсәң, үпкәләтсәң?

Озак уйланды Газизҗан. Тәнкыйть бит ул сиңа сыра да, ширбәт тә түгел. Хәзер берәү дә сүз күтәрми. Бигрәк тә нәчәлство. Дары кебек кабынып китәләр. Җитмәсә, шәһәре дә кечкенә. Агай-эне ак мыек, бер-беребезне яклыек дигәндәй, юньле урыннарга район башлыгы Хәсән Галиевичның туган-тумачалары кереп оялаган. Ә Газизҗанның фатир аласы, телефон куйдырасы бар...

Озак баш ватты ул. Фельетон өчен темалар чәчелеп ята. Мәсәлән, юллар начар. Әйтерсең лә бомбага тотканнар үзләрен, танклар белән үтүкләгәннәр. Язасы иде шулар хакында. Халык та рәхмәтле булыр иде. Фельетонның бәреп ега торган беренче җөмләсе дә әзер: «Рәсәйдә ике бәла бар — юллар һәм тиләләр». Шул тармак өчен җаваплы идарә фәкать түрәләрнең кәттиджләренә асфальт салдыру белән мәшгуль. Тәәк, ә идарә башлыгы кем? Әйе, Гали... Галиевич... Главаның абыйсы. Язып кара син ул хакта! Кулыңа кәҗә билеты тоттырып, 24 сәгать эчендә районнан сөрәчәкләр!..

Тагын уйланды Газизҗан. Кәнишне, фатирлар төзү һәм бирү идарәсендә дә сазлык. Андагы хәлләр турында фельетон гына түгел, сатирик вә криминалистик роман язарлык. Редакциягә жалобалар да килеп тора. Нинди шәп нәрсә сырлап булыр иде. Билләһи газыйм, халык гәҗитне типографиясе белән бергә йолкып алып китәр иде дә рәхмәт әйтә-әйтә укыр иде. Елдан-ел аска тәгәрәгән тираж да бер мизгелдә күтәрелеп китәр иде. Язып кара, Газизҗан! Тәвәккәллә! Шундук фатир алыр идең. Идарә башлыгы Кәрим Галие-

вич икенче көнне үк кәҗүнни думнан тимер рәшәткәлесен кояшлы яктан бирдерер иде. Бернинди чиратсыз!

Озак уйланды Газизҗан. Бәлкем, җир бүлү турында язаргадыр... Анда да безобразие бит! Алып-сатып, үзләштереп бетерделәр җирне. Урман-күл буйларын, кәүсәр суларын дус-ишләргә тараткан җир комитеты башлыгы Харис... Галиевичны өтәләргә иде... Өтәләрсең, бар... Главаның энекәше шул...

Янә уйланды Газизҗан. Берсүзсез иномаркалар турында да шәп фельетон язып булыр иде. Һәр түрәнең астында джип бит! Шуларны фотога төшерәсең, «Мерседес»ларының асларына бәһасен язасың, янәшәсенә түрәләрнең рәсми хезмәт хакын сырлап куясың. Шуңа кыска гына бер-ике чеметә торган җөмлә өстисең дә вәссәлам! Укы, халык, фельетон! Прокуратура, эш кузгат!.. Хәсән... Галиевичтан башлап... Чү! Әллә нәрсәләр керә башка...

Озак уйланды Газизҗан. Темалар күп, кәсафәтле фактлар буа буарлык, ә булачак фельетон геройларына якын барырлык түгел... Болай да, тегеләй дә, аксак кәҗәгә атланып та. Күңелдәге «кирәк» һәм «ярамый», ниһаять, көрәшеп ардылар.

Көн кичкә авышканда, Газизҗанның талчыккан йөзе кинәт яктырып киткәндәй булды. Ул кулына каләм алды, тиз-тиз нәрсәдер сырлап, шуны редакторга алып керде.

Гәҗит башлыгы тәмәкесен көйрәткән килеш кем беләндер телефон аша сөйләшә иде. Ниһаять, сүзен очлап, ул Газизҗанга төбәлде.

— Нәрсә, яздыңмы?

— Яздым, Галимҗан Галиевич, — диде журналист һәм язганын тиз генә шефның өстәленә салды.

— Бу нәрсә? — дип гаҗәпләнде редактор, кәгазьне боргалап.

Газизҗан күзен челт-челт йомгалады:

— Ни ул... Гариза ул, Галимҗан Галиевич. Икенче ел бит инде отпускысыз эшлим. Бик арыдым. Җибәрегез инде, пожалыста!..

## Май кап!

Демократия килде килүен, ләкин нәчәлство беркая да китмәде. Карьера биеклекләрен штурмлаучылар да кимеми. Бары тик демократия дип кәнәфи дәгъвалаучылар ниятләрен әллә кая тирән яшерә башладылар.

Ә менә инженер Галимәрдән замана җилләренә иярмәде. Үзенең вазифасын тыныч кына үти бирде, үз кәккүге кычкырганны көтте.

Беркөнне иртүк аны бүлек мөдире Хәсәнша Халикович чакыртты. Галимәрдән, шефның бүлмәсенә кереп, тыйнак кына урындык читенә утырды.

— Менә син, Галимәрдән, бик тырыш кеше. Сүз тыңлаучан. Кыскасы, сине үстерергә вакыт, —диде нәчәлник, елмаеп.

Галимәрдән дәшмәде. Янәсе, үзегез беләсез.

— Бик зур сер итеп кенә әйтәм, тиздән бездә үзгәрешләр башланачак... — Хәсәнша Халикович бармагын өскә күтәрде. — Аңладыңмы?

Галимәрдән аңгыра сарык сыман баш селекте.

— Тагын бер кат искәртәм: бу хакта беркемгә дә ычкындыра күрмә, май кап!

Күптән мүкләнеп беткән конторада нинди үзгәрешләр булыр икән? Шулай да иртәнге сөйләшү инженерның өч төнлек йокысын урлады. Инде бераз тынычланып килгәндә генә, Галимәрдәнне директор урынбасары Сәгыйть Магазович чакыртты.

— Син, энекәш, бик тырыш, сүздән чыкмыйсың. Күп сөйләмисең... Кыскасы, сине күтәрергә вакыт. Тиздән... Тик, тсс, авызыңа май кап!

Галимәрдән үзен нәрсә көткәнен аңламаса да, янә баш селекте.

Бу монолог хисле инженерның тагын биш көнлек йокысын качырды. Инде адәм рәвешенә кереп килгәндә генә, аны директорга чакырттылар:

— Тә-әк, Галимәрдән энекәш, син бездә ничә ел әле?

— Унбиш, Марсель Хәйдәрович.

— Ни гомер гади инженер булып йөрисең, әйеме? Еламаган бала син, понимаешь! Үзең сорамыйсың, ә без уйламыйбыз. Йә, ярый, бар, түлке кешегә сөйләп йөрмә, май кап!..

Бу визиттан соң Галимәрдән тагын бер атна җүнләп йоклый алмады.

Көн артыннан көн уза торды. Үзгәрешләрнең зурысы да, кечкенәсе дә күренмәде. Кинәт Галимәрдән эшли торган конторага бер-бер артлы тикшерүчеләр килә башлады.

Бер атна узмады, бүлек эшләрен сүлпән алып барган өчен, Хәсәнша Халиковичны урыныннан «выжлаттылар». Галимәрдәннең йөрәге жу итте: «Башланды!» Ләкин бүлек мөдире урынына бер яшь шалканны китереп утырттылар. Әле иренennән ана сөте дә кипмәгәндер. Кычкырып елаган бала булгандыр инде...

Чираттагы тикшерүдән соң Сәгыйть Магазовичны кәнәфиеннән очырдылар. Галимәрдәннең йөрәге тагын жу итте. «Миңа урынның җылырагы тия, ахрысы...» Ләкин тимәде. Китерделәр дә куйдылар башканы... Бөтенләй уйламаган кешене. Монысы да, күрәсең, каты елый торган булгандыр.

Конторада ревизияләр дәвам итте. Бу юлы директорның үзе өстендә күк күкрәде, яшен яшьнәде. Галимәрдән тагын дулкынланып үзгәрешләр көтте. Йокысыз төннәрнең саны арта барды.

Ниһаять, тикшерүләр тәмамланып бер-ике атна узгач, контораны банкрот дип игълан иттеләр. Әлбәттә, бетерү комиссиясе төзелде. Аның рәисе билгеләнде. Әйе, бу юлы бәхет ниһаять, Галимәрдәнгә елмайды...

## Кабак

*(Чынга бик якын хикәя)*

Кыям абый, әллә бик яшьли җирдән аерылып калага килеп урнашканга, әллә холкы белән крәстиянгә якын булганга, дачасына мөкиббән кеше иде. Һай, сез аның пөхтә, матур бакчасын күрсәгез! Тирә-юньдәге бакчачылар да йорт яки мунча салыр йә куак-мазар утыртыр алдыннан һичшиксез Кыям абый белән киңәшләшәләр. Ни өчен дигәндә, аның белмәгәне юк. Утыз ел бергә гомер иткән Сәвиясе дә крәстиянлек чире йоккан хатын булып чыкты. Икесе дә җигелеп, иртәдән кичкә хәтле җирдә казынганга, бакчалары да, йортлары да сокландыргыч бер җәннәт почмагын хәтерләтә. Ә нинди күркәм күршеләр туры килде аларга?!

Кыям абыйның кордашы Хәмидулла абый да шул ук крәстиянлек хастасын йоктырганнардан. Аның хәләл җефете Сания апа да бакчачылар нәселеннән. Күршеләрне шушы җир кисәкләре дуслаштырды. Табыннары да, шатлык-кайгылары да һәрвакыт уртак. Хәтта бакча тәрәзәләрен кышка кадаклап кайткач та, аралары өзелми — шәһәрнең төрле почмакларында яшәсәләр дә, бер-берсен туган көннәрдән, туйлардан һәм башка шундый күңелле мәҗлесләрдән калдырмыйлар.

Быелгы бакча чоры гадәттәгечә матур гына башланып, тыныч кына дәвам итте. Ләкин ике бакча арасын бүлеп үскән чиктәш карлыганнар өлгереп, кыяр-помидорлар өч литрлы банкаларга тутырыла башлаган дәвердә көтелмәгән бер хәл килеп чыкты.

Мәгълүм ки, кабак дигән бер сәер үсемлек гадәттә утырткан урынында түгел, бераз читкәрәк китеп өлгерә.

Кыямның кабагы гел дә уңа һәм һәр елны күрше Хәмидулланың биләмәсенә шуышып кереп, шунда түгәрәкләнә. Быел да ул Хәмидулланың бакчасында адәм күтәрә алмаслык дәү булып җитешкән иде.

Гаҗәеп хәл, Хәмидулланың түтәлләрендә һәрнәрсә Кыямныкы кебек шаккатыргыч булып үссә дә, шул ук шартларда кабак нишләптер уңмый иде.

Ә Хәмидулла аның бәлешен үлеп ярата. Киптерелгән орлыкларын черт-черт чистартып ашап утырулары да еракта калган балачагын хәтерләтә бит. Җитмәсә, ирләргә файдасы да тия, диләр. «Үсми генә бит, каһәр! Ә аныкы бүлтәйгән!» — Хәмидулла үз территориясенә рөхсәтсез кереп оялаган кабак яныннан узганда һәрвакыт нindидер нәфрәтләнү кичерә иде.

Көннәрдән бер көнне Кыям, күршесенең бакчасына кереп, кабакны үз ягына тәгәрәтә башлады. Бу хәлне карап торган Хәмидулла, әллә мондый яшелчәне үстерә алмавына гарьләнеп, әллә күршесенең бер сүз кушмавына ачуланып, үзе дә сизмәстән «Саран тәре!» дип ысылдады. Кирәк бит, кабакны инде үз ягына тәгәрәтеп чыгарган Кыям абый моны ишетеп, карт кычыткан баскандай кычкырып җибәрде:

— Кем?! Минме?

— Мин түгел инде! — дип җавап бирде Хәмидулла һәм, верандасының ишеген шап иттереп ябып, эчкә кереп китте.

Кабак хуҗасы, ярсуын көчкә тыеп, күршесе артыннан верандага очып менде, ябык ишекне дөбердәтте:

— Ач ишегеңне, күземә карап кабатла!

— Ачмыйм да, кабатламыйм да! Син, Кыям, куша гына беләсең, ә бүлешергә сине ни атаң, ни арифметика укытучысы өйрәтмәгән!..

Запастагы прапорщик Кыям Фазлыев: «Аһ, син шулаймы әле, кабахәт!» — дип, үзе дә сизмәстән кулындагы таягы белән веранда тәрәзәсенә төртте. Пыяла бөтен дөньяны яңгыратып коелып төште.

— Мин моны болай гына калдырмыйм! — дип кычкырды Хәмидулла, ватык тәрәзәдән балта уйнатып. — Под суд пойдешь, Хайван Иваныч!

— Пошел ты, Собака Петрович! — дип төкеренде отставной прапорщик һәм, җилкапканы тибеп ачып, үз бакчасына кереп китте.

Күршеләрнең чит телгә күчеп сөйләшә башлаулары пүчтәктән кабынып киткән низагның дәвамлы булачагына ишарәли иде. Кыямның сүгенә-сүгенә электричкага китеп баруын тәрәзәдән күргәч, Хәмидулла ашыкмый гына ишекләрен бикләде һәм ярты кирпеч алып, аны граната кебек селтәп, күршесенең веранда тәрәзәсенә томырды. Атаканың уңышлы тәмамлануыннан ниндидер бер тәм табып, тынычланып, Хәмидулла да, салмак кына баскалап, станциягә таба юл алды.

Озак та үтми, ике бакча арасында имән такталардан ясалган калын, биек дивар үсеп чыкты. Киләчәктә араларның тагын да катлауланачагын күздә тотып булса кирәк, Хәмидулла койма өстеннән чәнечкеле тимерчыбык тарттырды. Ә Кыям исә, салкын сугышның көчәя баруын сизенеп, ул чыбыкларны баганадагы электр утына тоташтырып куйды.

Күршеләр арасында дуслык никадәр нык булган булса, дошманлык та шул ук дәрәҗәдә көчле иде. Эшләр тиз арада мировойга, аннан район мәхкәмәсенә барып җитте. Газета, җәмәгать оешмалары да читтә калмады. Шунысы кызык: шикаять язучы һәр ике як та низагның нәрсәдән башлануын күрсәтмәгәнлектән, инстанцияләр хат авторларына, аларның олы яшьтә булуларын истә тотып, бер-берегезне гафу итәргә, дуслашырга кирәк дигән стандарт җаваплар юллау белән канәгатьләнделәр. Кем белә, тора-бара бу хәлләр Аурупа мәхкәмәләренә, Берләшкән Милләтләр Оешмасына да барып җиткән булыр иде, әгәр дә...

Мәсьәләне дөньяның иң югары «инстанциясе» үзе тамырдан хәл итеп куймаган булса...

Яңгырлы август кичендә ике арада төзелгән иң биек корылма-диварга кинәт яшен сукты. Әллә электр тогы уздырылган чәнечкеле чыбыклар бер-берсенә якын торганга, әллә имән такталары бик коры булганга, ут бик тиз генә койманы ялмап алып, йортларга сикерде. Ул көнне каладаниндидер зур бәйрәм узганга, бакчачылар, шул исәптән этле-мәчеле яшәгән Кыям белән Хәмидулла да, дачаларына килмәгәннәр иде. Икенче көнне хәвефле хәбәрне участковыйдан ишетеп, ике гаилә дә, ут йота-йота, бакчаларына йөгерделәр. Пыскып яткан кисәү башларын, хәрабәләрне, тапталган бакчаларын күреп, дөньяда нинди генә сынаулар үтмәгән ике ир дә күз яшьләрен тыя алмадылар.

Ул арада участковыйның вазгыятькә бик туры килеп бетмәгән оптимистик тавышы яңгырады:

— Карагыз әле, җәмәгать, гаҗәп бит бу! Ничек шундый мәхшәрдән исән калган икән бу кабак?! — диде ул, тирес чүмәләсендә аунап яткан зур кабакка төртеп күрсәтеп, һәм бөтенләй дә урынсыз сорау ташлады: — Кайсыгызныкы ул, иптәшләр?

## Дурдом

Җәмәгать, алдыйлар безне! ЖКУдагылары да, банктагылары да, сәясәтчеләре дә, гәзитчеләре дә, кибетчеләре дә, сөяркәләр дә һәм хәтта хатыннар да. Шул алдауларны безгә сеңдерүче, башыбызны әйләндерүче — мин сезгә әйтим, телевизор!

Аның нәрсә икәнен исеменең беренче өлеше үк татарча кычкырып тора! Әйе, тилевизор!

Көне-төне «Пантин-прови»лар, «Дирол»лар, прокладкалар күрсәтеп, инде ничәмә ел халыкны интектерәләр бит!

Әнә бер яшь чибәркәй сагыз чәйнәргә үгетли. Ак тешләре мәрҗәннәрдәй тезелеп киткән. Ник шунда берәр сынык тешле әби-сәбине чыгарсыннар. Шиш! Унсигез яшьтә безнең дә тешләр киләшчә кебек иде, малайкаем!

Менә тагын бер шоколад тәнле, озын сыйраклысы җыерчыкларны бетерә торган кремны мактап утыра. Имештер, көн дә куллансагыз, минем кебек шома тәнле булырсыз. Монда да бите ат картасын хәтерләткән әби-карчыкларны күрсәтмиләр. Шиш! Ә яшь чакта кызларның җыерчыгы булса да, кем әйтмешли, битләрендә түгел, итәкләрендә генә була!

Кичләрен арып кайтасың, ашарга утырасың — тагын шул ук зәңгәр ящик! Нормальный, галстук таккан ирләр бәхәсләшәләр. Янәсе, Рәсәйдә вертикальне ныгытырга кирәк... Хм... Бу хакта хатын-кызлар сүз куертсалар, бер хәл... Аңлар да идең... Аларны ул тема һаман борчый... Урыс әйтмешли, у кого что болит...

Ә ирләр?! Сигез сәгать ат урынына эшләп кайткан ир вертикаль турында түгел, җәмәгать, беренче чиратта горизонталь турында кайгырта ул! Ягъни, тамак ялгап, диванга барып егылу турында уйлый...

Телевизордан күрсәткән адашкан мәхәббәтләр, саташкан сөюләр, ычкынган гыйшыклар, экияти чит ил тормышы хатын-кызларыбызны күрәләтә боза башлады, җәмәгать! Шул шедеврларны карагач, авыл хатын-кызы абзарга чыгып, пычрак фермага барып, ничек сыер саусын ул?! Үзен королева кебек хис иткән хатын ничек алты квадрат метрлы тараканлы кухняга кереп, тозлаган кәбестәдән исерек ире өчен аш пешерсен?! Иң кимендә ул төнлә горизонтальный гырлап яткан иренең кинәт уянып, мәхәббәттән котырган Хуан Карлоска йә Луис Альбертога әверелүен тели...

Еш кына зәңгәр экраннардан гыйшык-мыйшык, шәрә тәннәрне күрсәтәләр. Кайчак андый кинолар - «Тыныч йокы, нәниләр!» тапшыруы белән бергә дә туры килгәли. Оят, валлаһи! Ярый ла мин, бер күзне йомып, ояла-ояла булса да карармын ди. Ә бит еш кына яныма нәкъ шул интирисный маминтта биш яшьлек онык та килеп утыра. Андый чакта мин аңа болай дим:

— Бар, улым, йокларга ят инде. Әнә телевизордагы апайларың да йокларга әзерләнәләр...

Әлегә тыңлый да, тора-бара нишләргә булыр инде?

Тормыш дәрәҗәсе аска тәгәрәгән чорда телевизор әйтерсең лә икенче бер дөньяда яши: анда гел бәйрәм, җыр, гел юмор-сатира, уен-көлке.

Хәер, монысы да тикмәгә түгел... Дөньяда атна саен бәя күтәреп торган хөкүмәт тагын бардырмы-юктырмы, белмим, ләкин шуңа түзеп торган халыкны беләм: ул без! Мәсәлән, торак реформалары барышында йөз тапкыр бәяргән фатирларга кергәндә, үзеңне хәзер йә 5 йолдызлы отельгә, йә Эрмитажга кергән кебек хис итәсең, билләһи газыйм! Кәнишне, сәгать саен бәяләрне күтәреп, халкының кәефен төшереп торган хөкүмәтнең гамәлләрен телевизор, мактамаса да, оныттырырга бик тырыша. Ләкин мөмкинме бу?! Моның өчен кибетләргә кермәскә, транспортта йөрмәскә, гәҗит укымаска, өйдә бикләнеп, шул телевизорны гына карап ятарга кала.

Күршем Гафур берничә ай эш табалмый шулай дөньядан отключаться итеп, өйдә утырып карады каравын. Нәтиҗәсе трагикомически килеп чыкты.

Бер кичне эштән кайтсам — 01, 02, 03, 04 машиналары дүртесе дә безнең подъезд төбендә торалар. Участковый, пистолетын тотып, арлы-бирле йөгереп йөри. Булган, мәйтәм, хәлләр...

Соң теге Әмрикә кинолары, андагы атыш-сугыш, шартлатулар, пожарлар үзенекен эшләгән инде, җәмәгать! Әүвәл Гафур абзагыз кухняда петарда шартлата, аннары залга йөгереп керә, эшләп торган телевизорны монстр дип кабул итеп, ике көпшәле 20 ле калибрлы мылтыгыннан ящикка гөрселдәтә. Ут капкан монстрны өйдә калдырып булмый бит инде — тиле геройга әверелгән Гафур аны бишенче каттан аска томыра... Анда кемнеңдер иномаркасы торган булган. Кыскасы, Әмрикә киноларыннан бер дә ким түгел... Все, алып киттеләр күршене. Кайткалы юк әле. Дурдомда, диләр... Димәк, ашыкмаса да була. Безнең бүгенге тормыш шул ук дурдом бит инде ул, җәмәгать! Шту анда утырасың, шту монда.

Менә шул психлар йортында өч сантый сөйләшеп утыралар икән.

— Мине җиргә Хак Тәгалә җибәрде. «Бераз тәртип урнаштырып кайт әле!» — диде.

— Юкны сөйлисең, ул бу эшне миңа кушты! Шуңа мин монда! — дип каршы төшә икенчесе.

Өченче сантый бу икәүне тыңлап утырган да:

— Хак Тәгалә буларак, сезгә шуны әйтәм: мин мондый йомыш белән Җиргә беркемне дә җибәрмәдем!.. — дигән.

Ирексездән уйлап куясың, әллә чыннан да бездә тәртип урнаштырыр өчен Ходай йә бер җүнле кандидатура табалмый, йә аны безнең тарафларга командировать итәргә теләми...

## Букет

Шулай бервакыт эштән соң Гаделҗан өйгә бик саллы гына букет күтәреп кайтты. Атналар буе иреннән җылы сүз ишетмәгән, елмаю күрмәгән, бүләккә бер кисәк исле сабын түгел, кер сабыны да кыстырып кайтмаган кешенең мондый гамәле Санияне нык гаҗәпләндерде һәм аптырашта калдырды. Үз җае белән алпы-салпы тәгәрәгән тормышта мондый көтелмәгән хәл шактый киеренкелек тудырды.

Ни уйларга да белмәде аптыраган хатын. Мондый букетны Гаделҗан шәһәрнең берәр бакчасыннан урып кайтты микән әллә? Алай дисәң, үзе салмаган да. Шулай да бер нәрсә аңа көн кебек ачык иде. Гаделҗан мондый чәчәкләрне, чукынса да, акча түләп базардан хатынына алып кайтып бирмәс иде. Шту син!

Шундый нәтиҗәгә килгән хәләл җефетенең авызыннан сәер сөаль яңгырады:

— Нәрсә-ә бу?!

Гаделҗанга мондый сорау бик мәгънәсез кебек тоелды.

— Нәрсә «нәрсә», күрмисеңмени, күзең чыкмагандыр бит!

Сания мондый дорфалыктан бераз югалып калса да:

— Үз күземә үзем ышанмыйм, апаем, кемгә бу чәчәкләр?!

— Әбиеңнең батинкасы! — дип шартлады, ниһаять, Гаделҗан һәм шытырдавыклы кәгазьгә төргән букетны коридор идәненә томырды.

— Менә рәхмәт!.. — Сания үкси башлады. — Килеп керүеңә миңа түгел дип уйлаган идем шул аны. Берәр җанкисәгеңә алгансыңдыр әле. Ә ул свиданиегә килмәгән... Әнә җеннәрең ничек кузгалды!

Гаделҗан, коридорда ярты минутлап таптанып торгач:

— Ашарга бармы? Әллә миңа ашханәгә барып ашаргамы? Их, җегетләр, кайчан да булса юньле хатыннар кебек елмаеп каршы алырлар микән мине үз өемдә? — диде.

— Бар, әнә шул кәнтәйләрең янына, букетыңны да алып кит! — дип кырт кисте дулаган хатын һәм чәчәкләрне коридорга томырды.

Гаделҗан букетны идәннән күтәреп тормыйча ишеккә юнәлде.

Нәкъ шул урында тукталып, ир-хатын мөнәсәбәтләре хакында бер кәлимә әйтеп китәсе килә. Бу очракта атта да бар, тәртәдә дә дигән мәкаль мач килер иде. Гаделҗан мондый тарихи адымны ясарга керешкән икән, алып кайткан букетын биргәндә, елмаеп:

— Әнисе, матурым, минем кебек авыр кеше белән күп еллар бергә торуың уңаеннан кайнар котлыйм, — дип әйтсә, бәлкем, бу чәчәк тапшыру церемониясе бөтенләй башкача төс алган булыр иде.

Әйтергә кирәк, Саниянең чәчәк бәйләмен кызыл чүпрәкне күргән үгез кебек кабул итүе дә бөтенләй урынсыз иде. Нәкъ менә шундый шырдый-бырдыйдан килеп чыккан низаглар тормыш корабын гаилә дигән океанда әледән-әле штормнарга ташлый, еш кына су астындагы рифларга бәреп челпәрәмә китерә. Һәм бу катастрофа ир белән хатынның пүчтәк кенә бер мәсьәләдә аңлашмауларыннан килеп чыга...

Ә безнең вулкан кебек кайнап торган геройларга килгәндә, аларның эшләре бер дә җайлы бетәргә охшамаган иде.

Шулай да, мунча ташы да беравыктан суына дигәндәй, ярты сәгатьләп вакыт узгач, Гаделҗан, әзрәк тынычланып, өйгә кайтып керде. Ул, үз гаебен сизгәндәй:

— Кара әле, Сания, безнең бит бүген... — дип авызын ача башлаган иде, шул чакта балконда нәрсәдер шатыр-шотыр килде. Мондый манзараны детектив киноларда гына күргәнгә, Гаделҗан беренче мәлгә югалып калды. Югалырсың да, пажалый, чөнки балконда бер кулына чәчәк бәйләме, икенчесенә күлмәк-чалбар тоткан ярым шәрә ир уртасы кеше басып тора иде.

— ...Г-г-гафу ит-т-тегез, зинһар!..

Гаделҗан озак уйлап тормады, балконында кинәт пәйда булган ир затын буып алды:

— Кем син, кайдан?!

Агарынган адәм:

— М-м-мин бирегә югары каттан т-т-төштем...

Бу хәлләрне күреп коты алынган Сания нәрсә эшләргә белмичә залда басып тора иде.

Ярсыган Гаделҗан, хатынына күрсәтеп:

— Син бу хатын белән танышмы?!

— Юк-юк, Алла сакласын! — дип акланды чакырылмаган кунак.

Вазгыятьне йөгәнләгән Гаделҗан сорау алуын дәвам итте:

— Син монда кем янына килдең? Кайсы фатирга?!

— Мин сезнең өстәге С-с-сонечкага... кунакка килгән идем...

— Ә-ә, менә эләктегез! — дип күкрәде Гаделҗан. — Минем дә хатынны Соня дип йөртәләр. Бәреп үтерәм хәзер икегезне дә!

— Юк-юк, мин сезнең хатыныгызны беренче күрәм, билләһи газыйм! София Александровнаның ире кинәт командировкадан кайтып төште, зинһар, харап итмәгез, чыгарып җибәрегез инде мине!

Гаделҗан бу мескеннең хәленә керергә теләмәде:

— Каян килдең, шуннан кит! — дип, теге чакырылмаган кунакны балконнан төртеп төшерде.

Ярый әле чит хатыннарны яратучы альпинистка озак очарга туры килмәде. Гаделҗанның фатиры икенче катта гына иде. Балкон идәнендә төшеп калган затлы букет сөяркәләрнең гыйшыклары андый-мондый гына булмавына ишарәли иде.

Мондый психологик тетрәнүдән соң ир белән хатын нәрсә эшләргә белми торганда, кинәт ишектә кыңгырау чылтырады.

— Тагын кем инде бу?! Тилеләр йорты, билләһи газыйм! Ну мин сезгә күрмәгәнегезне күрсәтәм хәзер! — дип, Гаделҗан коридорга ыргылды. Ләкин бу юлы андый кискен чараларның кирәге булмады. Ишектә, елмаеп, Гаделҗанның яшьлек дусты Гаделша басып тора иде.

— Каян килеп төштең син, зимагур?! — дип, өй хуҗасы кунакны кочаклап алды.

— Чү, имгәтәсең бит! Валлаһи, үгез кебек тазаргансың, йә әле, әүвәл хатын-кызларга хөрмәт күрсәтик.

Шул сүзләрдән соң Гаделша бер бәйләм роза чәчәкләрен рәвешенә китереп Саниягә бүләк итте.

— Хәтерлисезмедер, юкмыдыр — нәкъ егерме ел элек мин сезнең туйда шаһит булып утырган идем. Ихлас күңелдән бәйрәмегез белән котлыйм!

— Ну, брат, булдырасың... Без инде авылчарак, гади генә, ләкин шулай ук ихластан... — дип, Гаделҗан чәчәк бәйләмен мунча себеркесе кебегрәк тотып хатынына сузды.

## Уртача

Безнең илдә бар бер гаҗәп үлчәм —
Һәрнәрсәне санау уртача.
Ил буенча мисал: һәр кешегә
Туры килә икән бер дача.

Хастаханәләрдә хәлләр ярый,
Начар түгел, алсак уртача...
Сырхауларның утыз алты ярым
Температурасы һәркайчан.

Кешеләр дә яши ару гына,
Әгәр исәпләсәң уртача.
Кода алган ике меңгә, мәгәр
Унбиш меңен кушса кодача.

Гомерне дә уртача саныйлар,
Сиксән бишкә кушып кырыкны.
Кем соң сорый анда киткәннәрдән:
«Яшәдеңме шушы срокны?»

Уртачалар җайлы түрәләргә
Бутар өчен агын-карасын.
Акыллылар әгәр ышанмаса,
Түшәмнәргә карап санасын.

## Исем китә берәүгә

Безнең йортның нәкъ кырыннан
Машина юлы уза.
Дөмбердәүгә чыдар хәл юк,
Тузаны да нык туза.

Ишегалдында төзелеш —
Көн дә субай сугалар...
Күршедә музыкант яши,
Һәр кич улый трубалар.

Төнге клуб каршыбызда,
Анда да шайтан туе.
Дөмбер-дөмбер музыканы
Тыңлыйбыз төннәр буе.

Йортыбызда яшәүчеләр
Исәрләнеп йөриләр,
Ыржаялар бер-беренә,
Әйтерсең лә бүреләр.

Исем китә тик берәүгә —
Һәрчак елмаеп уза.
Исәнләшә башын иеп,
Кулын беренче суза.

Мәйтәм, нидән бәхетле бу,
Әллә бер дурак микән?
Сере чишелде соңрак —
Ул адәм чукрак икән!

## Ни җитмәгән?

*(Шәхес һәм нәфес)*

Әрсез шәхес Васыйл — тыгылды бар җиргә,
Урласын урлады, батып шабыр тиргә...
Кәттидже дә булды, «Мерседес»-джип та бар.
Юк, нәрсәдер җитми — дөньясы һаман тар.

Кулда влач, акча, хөрмәт-дәрәҗәләр,
Хур кызлары кебек ишле сөяркәләр...
Тик нәфескә һаман нидер җитми сыман,
Мәгәр гакылны капласа куе томан.

Шөкер итми кыланганның тормыш җебе
Өзеләдер, челпәрәмә килгәч затлы джибе...
Шулай ачыклана, мәрхүм ни теләгән —
Аңа бары ике аршын җир җитмәгән!..

## Демократия

*(Почти булган хәл)*

Ил өстендә шаулый демократик давыл,
Шундый хәлдә ничек сайлый икән авыл?
Әйтте башлык: «Ничек булса, шулай булсын —
Сайлаулар үз агымына гына узсын!..»
Менә Гайфи агай кайтып килә җырлап,
Буфетлар мул — җибәргәннәр моны сыйлап.
«Мин влачка тавыш бирдем — эшләсеннәр,
Первыйлыктан аска гына төшмәсеннәр!»
Хәсән абый демократларны яклаган,
Ләкин серен барсыннан да саклаган.
Башкаларга әйткән: «Шөкер бит Аллага,
Эшләр шәп бара!» — дип, рәисне мактаган.
Әнә тракторчы Сәйфи кайтып бара,
Усаллыгы күзләрендә — йөзе кара...
Үпкәсе рәискә: фуражларны кысты,
Шуңа тракторчы һәммәсен дә сызды.
Пенсиядәгеләр тавыш бирде өйдә,
Тәүге тапкыр үзләре теләгән көйгә...
Үткәннәрне өзелеп сагынганга күңел,
Зюгановны сайладылар алар бүген.
Шулай итеп ирекле сайлаулар узды,
Санадылар — нәтиҗәдән күзләр тонды:
«Тормыштан канәгать» авыл влачны сызган,
Шуңа беренчегә коммунистлар узган.
«Дөрес санамагансыз бит, ачәрвахлар!
Себер китә сезнең белән газиз башлар! —
Сүкте рәис избиркомны, тетте барсын: —
Төзәтегез — санау дөрес якка барсын!..»
Санадылар... Кая кирәк өстәделәр,
Канәгать булсыннар диеп өстәгеләр.
Нәтиҗәләр шунда гына дөрес чыкты:
Югарыга «Җиңдек!» дигән рапорт очты...

## Әби-бабай тәрбиясе

Оныклары уянса елмаеп,
Болытлы көн китә яктырып.
«Әйдә, кызым, күтәрел тизрәк,
Ычкындырмыйк кулдан яктыны».

Кайчагында шыңшып та уяна —
Аңламассың бала-чаганы...
Күтәрәләр — башка чарасы юк —
Дәү этисе тарткан чананы.

Җигелә дә хәзер бахбай кебек,
Алып китә кызны бакчага,
Онык диеп чаба әби-бабай —
Кием дә җәл түгел, акча да.

Әти-әниләре кайларда соң?
Алары да исән — эшлиләр,
Атнага бер килеп иркәлиләр —
Үзләренчә, аерым яшиләр.

Үсеп буйга җиткәч оныклар да
Рәхмәт әйтеп искә алырлар...
Әби-бабай җилкәсенә тагын
Балаларын китереп салырлар.

## Җыя халык долларны

«Халыкта акча бар...» — диеп
Күтәрәләр бәяне!
Хәзер әби-сәбиләр дә
Белә инфелясияне.

Сумнар белән авыз пешкәч,
Доллар җыя барчасы...
Чөнки бернидән курыкмый
Әмрикә акчасы.

Бай кешеләр гәпләшәләр:
«Яшел» күпмегә үскән?»
«Нефть бәяләре ничек?»
«Агач» күпмегә төшкән?..»

Уҗым хакында сүз бармый,
«Агач» та утын түгел...
Сүз акча турында бара —
Һәркем финансист бүген.

«Халыкта акча бар», — диләр,
Тик әйтмиләр — кайсысы?
Элек рубль җыя идек,
Хәзер доллар кайгысы.

Булмас бу илдә баеп та,
Бәяләргә дә түзеп.
Доллар җыям да ычкынам
Әмрикәгә үзем!..

## Сагыну

Авылын сагына Хатыйп,
Анда калган Раузасын.
Алимент җибәрмәсә дә,
Җибәреп тора хатын.

Кибет мөдире Малик та
Онытмый туган ягын —
Кышын бер телеграм суга,
Бер шылтырата язын...

Әти-әнисен сагынып,
Көн дә эчә Маһидур.
Тулай торакны селкетә,
Дер-дер килә каридур.

Туган йортны сагынуы
Чиктән ашкан Илдарның —
Атна саен кайтып килә
Урап авыл юлларын.

Бер дә урамас иде дә,
Бәрәңгесе бетмәсә,
Итне дә шуннан кайтара,
Каймагын да, җитмәсә.

Авыл үзе дә онытмый
Ерактагы улларын...
Ихлас күңелдән сагына
Адашкан балаларын.

## Үпкәләмә Ходайга

Мөдир Хәсән һәрбер эшне
Бисмилла белән башлый,
Башлавын дөрес башлый да,
Тик иртәгәсен ташлый.

Еш кына үз вазифасын
Ул Ходайга тапшыра,
Нәтиҗәсе булыр, шәт, дип,
Кул кушырып утыра.

Ходайның кодрәтендә дип,
Йөз чөерми ришвәттән,
Салып куя кесәсенә
Дога белән беррәттән.

Җайлы гына барган чакта,
Тормыш йөзтүбән китте:
Бер капчык шикаять җыеп,
Тикшерү килеп җитте.

Дөрес юлга кайтыр диеп,
Алла озак көткәндер...
Ахыр чиктә кул селтәгән,
Түземлеге беткәндер...

Зур срок алса да Хәсән,
Гыйбрәт алмас үткәннән...
Утыра көннәрен чутлап,
Һәм Ходайга үпкәләп...

## Ришвәткә мәдхия

Озак йөрде фатир алалмыйча Хәйдәр...
Чиратларда торды алтмыш яшькә кадәр.
Йортлар төзелсә дә, елмаймады бәхет —
Әллә кайдан урап узды шул бәдбәхет!

Әйтте бажа: «Кирәкле кешене беләм...
Әзерлә акчаңны — сөйләшергә керәм...»
Фәкать шулай хәл ителде мәсьәлә, вәт!
Ни әйтсәң дә, көчле нәрсә икән ришвәт!

Машиналы итте ришвәт кешеләрне,
Җылы урынга күтәрде ул дус-ишләрне,
Институт ишекләрен шар ачтырды,
Кирәк чакта армиядән дә качырды.

Инде килде замананың башкасы,
Юк дефицит! Булсын бары акчасы.
Шатландык, ясин чыгабыз дип ришвәткә —
Ә ул килгән икән мәңгегә китмәскә!

Ришвәт шайтан таягыдай чәчәк ата,
Аркылыга-буйга, уңга-сулга арта,
Усал карарларны уза урап кына —
Чөнки көрәш бара тик шул бумажкада...

Дөньясыннан гарык булып китте Хәйдәр —
Табигый хәл: берәү килер, берәү китәр...
Юк җирләргә урыннары — зират тулы...
Бу юлы да ришвәт сузды ярдәм кулын...

## Иске сандык

Иске сандык — серле сандык, ахры,
Бабай ача аны карарга.
Һәрбер нәрсә аңа яхшы таныш,
Хатирәләр сеңгән аларга.

— Менә болар керенкалар иде,
Бик аз гына йөреп алдылар.
Влач алышынды тиз арада,
Буш акчалар кулда калдылар.

Ә боларын Сталин вакытында
Капчык-капчык ташып йөрдек лә,
Хрущев дигән пеләш алтмыш бердә
Алыштырып куйды бер төндә.

Ә бу — торгынлыкның акчалары,
Алары да калды халыкта.
Павлов дигән берәү аркасында
Әнә күпме ята сандыкта.

Патша, вәзир, алар килә-китә,
Халык кала — аңа яшәргә.
Кыса-кыса җыйган акчаларны
Алыштыра кинәт каһәрләр!

Сандыктагы алдау тарихыннан
Бабакайның килә елыйсы,
Шуны күреп, онык әйтеп куйды:
«Евро кирәк иде җыйныйсы...»

## Гали, Вәли һәм бәяләр...

Бәяләргә югарыдан
Килә әмер: үсмәскә!
Югыйсә халык мөмкин бит
Бу хәлләргә түзмәскә.

Зур түрәләр һәр тарафтан
Вәгъдә бирә, ант итеп,
Ә бәяләр — гел тыңлаусыз
Сикерәләр ялт итеп.

Гали түрә — газ хуҗасы...
Вәли — электрныкы.
Чистарталар бергәләшеп
Кесәсен халыкныкын.

Вәли Галигә кычкыра:
«Тәүге ташны син бәрдең!
Мин убыткада утырам —
Ник бәяңне күтәрдең?!»

Галинең дә тамак көчле,
Ул да дәлилен таба,
Аргумент тапмаса, шундук
Трубаны тотып яба.

Аңлап булмый бу кәмитне —
Кем гаепле? Кем хаклы?
Ә хөкүмәт ул арада
Күтәреп куя хакны.

Очын очка ялгап булмый,
Юк яшәү уңайлыгы!
Ә бит газ да, электр да
Халыкның үз байлыгы!..

## Ярты*

*(Шаян җыр)*

Авылларда киң таралган —
Исеме аның «Ярты».
Ансыз яши алмый бүген
Ни яше дә ни карты.

Печәнен дә әзерләтә,
Онын кайтарта тартып.
Утынын кистереп куя —
Эшне тиз тота ярты.

Ифрат зур ярдәме тия
Әби һәм бабайларга.
Яхшысын да, яманын да
Ярты чыга майларга.

Күпме көрәшсә дә влач,
Җиңалмады яртыны.
Инде хәзер хөрмәт итә
Ихтыяҗын халкының.

Ярты-йорты дип көлмәгез,
Әйләнеп бара бергә.
Имән кебек егетләрне
Күтәреп сылый җиргә.

Ярдәме аның бер көнлек,
Зыянын кем санаган.
Соңгы юлга шуның үзен
Озатыйк безнең арадан.

## Атта да, тәртәдә дә...

Тракторда эшли Гата,
Шуңа ул көнен күрә.
Кемгәдер печән кайтара,
Бакчасын сөреп бирә.

Фермада сыерлар сава
Һәм болай уйлый Сөмбел:
«Өйгә буш чиләк күтәреп
Кайту дөрес эш түгел».

Йорт алдында бүрәнәләр —
Озыны бар, кыскасы...
Әлбәттә, биредә яши
Шамил — урман хуҗасы.

Иң зур кәттидж — аны белә
Олысы вә кечесе:
Иркен сулап яши анда
Хуҗалык җитәкчесе.

Буш кул белән йөрми халык,
Һәркем табадыр җаен.
Төпсез чуманнан чыгалмый
Мескен авыл ел саен.

Атта да бар, тәртәдә дә...
Бирмиләр хезмәт хакын!
Шуңа ташый һәрнәрсәне
Өенә авыл халкы.

## Бикле урман

Шәһәр читендә ничектер
Сакланып калган урман.
Ул могҗизаны күрәм дә
Һәр көн сокланып узам.

Бу ваемсыз заманада
Ничек исән син, урман?!
Нинди фәрештәләр сине
Саклый адәм кулыннан?

Балта-пычкы күрмәсен дип,
Гел кылып торам догам,
Яшәтә якты дөньяда
Шифалы вә саф һаваң!

Тик берзаман шул урманны
Әйләндереп алдылар.
Биек койма артларында
Кәттиджләрен салдылар.

«Пүчтәк» каен-усакларны
Кисеп аттылар төптән.
Затлы нарат-имәннәргә
Тимәделәр гомумән.

Менә шулай табигатьне
Саклау юлын таптылар.
Гади кеше йөрмәсен дип,
Урманны да яптылар.

Җирнең, суның, саф һаваның
Кадерләрен беләләр...

Хәзер яшеллек шифасын
Татый бары түрәләр.

## Яңа ел попсасы*

*(Шаян җыр)*

Тагын бер ел очты-китте
Мәшәкатьләре белән.
Сизми калдык, тыз-быз килеп,
Эш сәгатьләре белән.

Кушымта:

Узган гомерләрне җәлләп,
Син көзгегә карама!
Юкса, картаябыз диеп,
Тоз саласың ярама.

Сызып ташла календарьдан
Гомереңнең бер елын.
Урамда салкын салкынын,
Җылы җанкай куены.

Кушымта.

Өметләр бик зурдан иде,
Бокаллар чыңлаганда...
Кремльдән яңгыраган
Котлаулар тыңлаганда.

Кушымта.

Вәгъдәләр үтәлмәде дип,
Иске елны сүкмәгез,
Шәраблар бик кыйммәт хәзер...
Зинһар, түгә күрмәгез!..

Кушымта.

Рекламда тормыш гүзәл дип,
Дөмбәсләмә «ящикны».
Без аларны ишетсәк тә,
Алар безне ишетми...

Кушымта.

Дөнья барыбер үзгәрми —
Без генә үзгәрәбез...
Гомер ике килми диеп,
Бокаллар күтәрәбез!

Кушымта.

## Иҗат газабы

Тәнкыйть язалмый аптырый
Фельетончы Гыйсметдин.
Темаларны барлый да ул:
«Язар нәрсә юк бит, — ди. —

Чират иде кибетләрдә,
Шырпы иде дефицит...
Хәзер җаның нәрсә тели —
Ал, агайне, рәхим ит!

Транспортны сүгәр идең —
Әйтеп булмый авыр сүз.
Бер-бер артлы такси йөри,
Чиратларны күрми күз.

Фатирсыз интекте халык...
Хәзер ул да җитәрлек,
Элит йортлар сафка баса...
Матурлар, искитәрлек!

Кием-салым кибет тулы,
Ни генә юк базарда!
Кинәт үзгәрде замана,
Тема бетте язарга.

Хәзинәдә барсы да бар:
Колбаса да, балык та...
Тик бер генә нәрсә җитми:
Акча юктыр халыкта».

Кыскасы, Гыйсметдин хәзер
Фельетонны ташлады.
Дөнья матур, дөнья киң, дип,
Җырлар яза башлады.

## Яшен

Күкләр күкри, тәрәзәләр зыңлый,
Йолт-йолт итә яшен утлары...
Бөтен җиһан дыңгыр-дыңгыр килә —
Адәмнәрнең алына котлары.

Һәркем шулчак мескенлеген аңлый,
Сизә табигатьнең кодрәтен,
Кайсы тизрәк бисмилласын укый,
Искә ала динен, милләтен.

...Шатырдатып кинәт яшен сукты,
Утлы сөңге бәрде имәнгә!
«Ахырзаман килә, ахрысы!» — дип,
Әби китеп ауды идәнгә.

Бабай тиз-тиз белгәннәрен укый,
Оныклар да юрган астында.
Җан иясе тын алмыйча тора —
Бар да тигез яшен каршында.

Беравыктан дөнья тынычлана,
Кояш чыга кинәт ялтырап.
Шулчак, беләм, кеше онытадыр
Ничек утырганын калтырап.

Акыл ияләре баш ваталар,

Аңлый алмый серле дөньяны.
Ә табигать безгә бармак яный —
Үз урныңны, дустым, бел, яме!

## Кызлар көлә...*

*(Җыр)*

Урам буйлап бара кызлар көлеп,
Болытлы көн китә яктырып,
Шул көлүләр ыспай егетләрнең
Йөрәкләрен ала яндырып.

Кушымта:

Кызлар көлә кышкы буранда да,
Кызлар көлә яңгыр яуганда,
Кызлар көлә бармак күрсәтсәң дә,
Кызлар көлә кызлар булганга.

Сөенәләр кызлар, белмим тик сәбәбен,
Нинди бәхет күктән төшкәндер...
Бәлкем, сөйгән ярлар, тәвәккәлләп,
Тәүге серен кичә чишкәндер.

Кушымта.

Кызлар күзләп барам — кәефләр шәп,
Сирәк була мондый тойгылар...
Көлә кызлар, димәк, бар да яхшы,
Еламасын алар кайгыдан.

Кушымта.

## Китәр идем дә бит...

*(Җыр)*

Китәсең бит, кораб, калам карап,
Кайтырсыңмы икән яңадан?
Мин дә китәр идем синең белән
Бәхет эзләргә дип ягадан.

Кушымта:

Теләкләр бар, тик аяклар тартмый...
Туган ярдан ничек аерылыйм?!
Үз җиремдә михнәтләр күрсәм дә,
Читкә барып олтан булалмыйм.

Китәр идем бу тынгысыз илдән,
Авырлыктан тәмам гарыкмын...
Бер кош кебек җилкәненә кунып,
Мосафиры булып корабның.

Кушымта.

Китәр идем дә бит — өзеп кара
Кендек җебен — корыч канатны!
Әйтерсең лә кемдер туган җиргә
Бәйләп куйган минем корабны.

Кушымта.

## Киленнәр*

*(Җыр)*

Җитез машиналар чаба, юл бирегез,
Килен алып кайта бүген егетегез.
Икесе дә матур, дөнья кебек тигез,
Чәчәк атар, димәк, әле сезнең нигез.

Кушымта:

Киленнәрнең була төрлеләре,
Эштә җитезләре, өлгерләре.
Чибәрләре, нечкә биллеләре,
Игелекле, тәмле теллеләре.

Киленнәрнең җилкәсендә тормыш йөге,
Тәүлек буе йөгерсә дә, балкыр йөзе.
Киленнең язмышы — барына да түзү
Вә ишетмәү каенананың каты сүзен.

Кушымта.

Онытылмый килен булып төшкән көннәр,
Ялкын кебек янып беткән сихри төннәр...
Килер бер көн, килен үзе — каенана,
Өйнең түре, йомшак урын инде аңа!

Кушымта.

## Сөю хакына*

*(Җыр)*

*А...га*

Ничек табыштык без — аңлый алмыйм,
Фәрештәләр ярдәм иткәндер...
Моңа хәтле гөрләвекле язлар
Бездән башка ничек үткәндер?!

Арабызда шактый вакыт ята,
Тик күңелем синең яшьтәшең...
Башкаларга күз салмасын диеп
Йөрим әле көеп-көнләшеп...

Күңелдәге мәхәббәт сазының
Ишетелми иде тавышы...
Син кагылдың аңа, алсу гөлем,
Әллә белеп, әллә ялгышып.

Әй, Җир шары, бераз әкрен әйлән,
Язгы кояш, син дә ашыкма!

Вакытларны тезгенлисе килә
Ошбу сөюләрем хакына...

## Үкенү*

*(Җыр)*

Киттем — кайталмадым, юлым ерак...
Урман-таулар безнең арада.
Уянамын ак өметләр белән,
Ә кичләрен алар тарала.

Кушымта:

Бу дөньяның ике игезәге —
Аерылу белән сагыну.
Озатып йөри безне гомер буе,
Ул газаптан юктыр арыну.

Гомеремнең соңгы бер көзендә
Кайттым туган якка ашкынып...
Без яшьлектә салган күперләрне
Алып киткән вакыт ташкыны.

Кушымта.

Нигез корган, гармуннар өзелгән,
Читтә бигрәк озак йөрелгән...
Гомер йомгак кебек тәгәрәгән,
Сиздермичә генә сүтелгән.

Кушымта.

Бернәрсә дә тиктомалдан түгел,
Дөнья барысын да тигезли...
Туган туфрак үч аладыр бездән,
Ташлап киткән өчен нигезне.

Кушымта.

## Яңа бистә*

*(Җыр)*

Яңа бистә дисәләр дә — борынгы син,
Ничә гасыр шаулап узган урындыр син...
Балачагым калды, җилкапкага эленеп,
Тик тапмадым, кабат кайтсам да әйләнеп.

Кушымта:

Яңа бистә — һаман әле истә,
Инде күптән аннан китсәм дә...
Гомер юлым, тәүге адымнарым
Башланды шул Яңа бистәдән.

Ата-бабалардан калган һөнәрләрне
Саклаган остазлар гүя җәүһәрләрне.
Тимерчеләр төтенлиләр иде һәр көн,
Түбәтәй-бүрекне тегә иде һәркем.

Кушымта.

Янәшәңдә Идел ага торды тулып,
Яңа бистә яшәде бер йодрык булып.
Ятлар камап алган шомлы, чит мохиттә —
Җырлап тордың үз җырыңны, Яңа бистә!

Кушымта.

## Бер җырлыйсы килә

Эх, җырлыйсы килә яңгыратып,
Бар дөньяны таңга калдырып.
Моңсызларның бәгырьләрен телеп,
Гамьсезләрне утта яндырып.

Бер җырлыйсы килә сезнең өчен,
Искә алып үткән гомерне...
Калган хәтер, яшьлек җүләрлеге
Җилкендерер әллә кемеңне!..

Бер җырлыйсы килә эч бушатып,
Тоеп мәхәббәтнең җылысын...
Күңелдәге төерләрне чишеп
Җырлыйсымы... Әллә җылыйсы...

## Ничек түзим икән?!

Син инде юк... Кирәкми эзләргә,
Буранлы кышларда, яңгырлы көзләрдә...
Син йөргән сукмаклар кинәттән өзелгән —
Бакчамның бизәге — иң гүзәл гөл шиңгән...

Күрешмәбез инде беркайда, беркайчан —
Ул шомлы уйлардан шашынам да качам,
Сагыштан әйтерсең табигать бөрешкән...
Күз яшьләре булып үләнгә чык төшкән.

Очрашмабыз, бәгърем, күрешмәбез бүтән,
Елмаеп каршыма килмәссең син иртән...
Кара кош кычкыра, ничек түзим икән?!
Дөньядан бик иртә киттең шул син, иркәм...

## Сөю хатлары

*(Җыр)*

Ят карашлардан яшереп
Язылган бер сүз җитә...
Ике йөрәк дулкынында
Хәбәрне хисләр йөртә.

Кушымта:

Сөю хатлары саргаймый,
Каурый белән язсаң да.
Сөю хатлары югалмый,
Суларга агызсаң да.

Сандыклардагы хатлардан
Килә канәфер исе.
Еллар узгач та сүрелми
Чын мәхәббәтнең хисе.

Кушымта.

Ак кәгазьгә кайчак төшә
Сүзләрнең иң мөһиме.
Мин сиңа шундый хат яздым,
Синнән җавап көтимме?!

Кушымта.

## Ә мин калам Казанда...

*(Җыр)*

Чал тарихның шаһитлары —
Казансу да, Идел дә...
Дулкыннары какмый ярга,
Кага минем күңелгә.

Кушымта:

Халкымның изге шәһәре —
Барсы моннан башлана...
Бишеге бит син татарның,
Казан — гүзәл башкалам!

Булган шанлы тарихында
Агы да, карасы да...
Вакыт та дәва табалмый
Милләтнең ярасына...

Кушымта.

Казаннарга күңел тарта —
Ничек кайтмаска мөмкин?!
Монда туа моңлы җырым —
Дөнья матур, дөнья киң!..

Кушымта.

Онытыла кайгыларым,
Искә төшми казам да...
Син китсәң китәрсең инде,
Ә мин калам Казанда...

Кушымта.

## Мәхәббәт юк диеп уйлама

*...гә*

Әйтерсең лә яшьлек кире кайтты,
Дөнья күкрәп кинәт үзгәрде.
Хыялымда йөргән, төшләремә кергән
Очраттым мин зәңгәр күзләрне.

Беләм, син дә язмыш җилләренә

Ялгыз гына каршы торгансың...
Яманына чыдап, яхшысына
Шөкрана гына кылгансың.

...Ак агачлы йортың түбәсендә
Бер телем ай торды эленеп.
Йолдыз атылганда, йөзләреңдә
Ниндидер хис китте күренеп.

Онтылмас төн, гыйшык шәрабыннан
Мөмкин идеме соң айнырга?!
Ах, мизгелләр, сөю мизгелләре,
Ничек сезгә кире кайтырга?!

Гомрем буе гыйшык — әкият диеп
Көлемсерәп йөрдем бу хакта...
Инде хәзер бар дөньяга әйтәм:
«Сөю юк дип уйлау зур хата!»

Бүрәнәле йортың... Нарат исе
Аңкып тора һәрбер агачтан.
Җылысы да сүрелмәгән икән,
Ике йөрәк бергә янгачтан...

## Сөюебез әле алдадыр

Яз белән җәй — мәхәббәт айлары,
Ә көз моңсу фасыл — аера.
Гөлләр шиңә, торналар да китә,
Җилкәннәрне җилләр каера.

Бизәкләрен җуя табигать тә,
Кыш алдыннан кала бөрешеп...
Урамнарны яңгыр айкый-чайкый,
Яшьләр йөрми анда көлешеп.

Көннәр төтенләгән учак сыман
Газаплана дөрли алмыйча...
Вакыт уңга-сулга бәргәләнә,
Үз-үзенә урын тапмыйча.

Ә безләргә тик көтәргә кала
Гөрләвекләр аккан язларны.
Карлыгачлар алып килер әле
Тәкъдирләребездә язганны.

Шыксыз көзләр, салкын кышлар узар,
Янәшәңдә, бәгърем, калырмын...
Сөю утын, ышан, сүндермәмен —
Кирәк булса, үзем янырмын...

## Кайсыгызның күңеле нечкәргән?..*

*(Җыр)*

Башым салам, юкәгә сөяләм,
Моңга сусап җаннар тилмерә...
Әкрен генә «Карурман»ны сузам,
Шул җыр миңа кинәт көч бирә.

Кушымта:

Байтак йөрдем фани дөнья буйлап,
Тоялмадым тәмен тормышның.
Сагынып кайттым изге чишмәләрне,
Салкыннарын бездәге кышның...

Бишек җыры, әнкәй моңы белән
Сеңгән җанга изге мәхәббәт.
Аның белән яшәүләре — җәннәт,
Ансыз яшәүләре — кыямәт.

Кушымта.

Бар язганым ята ак кәгазьдә...
Кайсыгызның күңеле нечкәргән?
Бармы арагызда елатырлык көйче —
Кайсыгызга Ходай моң биргән?

Кушымта.

## Күңелең сынмасын*

*(Җыр)*

Тәрәзәңә бер көн бәрде карлы яңгыр...
Кемдер әйтте: «Түз син, язмышың шулайдыр...»
Китте ул ашыгып, китте ул хушлашмый,
Кемгәдер үпкәләп, дөньяны аңламый.

Авыр көннәреңдә тешеңне кыс, көрәш,
Бирешмә, елама, түз инде, сеңелкәш.
Син ялгызың түгел, сынмасын күңелең,
Балаларың өчен яшә, яшә, бәгырем.

Караңгы төннәрдә ялгызың булганда,
Каргама дөньяны, күңелең тулганда.
Төннән соң көн туа, ач тәрәзәләрне,
Кояш үзе алыр кара пәрдәләрне.

## Гомер уза*

*(Җыр)*

Гомер уза искән җилләр кебек,
Йөрәкләрдә кала ярасы.
Кемнәр әйтер, кемнәр санап бирер
Тагын күпме калды барасы.

Сөенәм мин, һәрчак иртәләрен
Шөкрана кылам тормышка.
Ә кичләрен, янә утлар сүнгәч,
Чумасың шул кайгы-сагышка.

Яшәү — үлем. Бары тик бер сукмак.
Нигә башка сукмак юк икән?
«Адаштым», — дип кире кайтыр идем,
Яшьлегемә кайсы юл илтә?!

Гомер уза аккан сулар кебек,
Йөрәкләрдә кала үкенеч.
Әҗәлләрдән дару булмас инде,
Ходай яшәр өчен бирсен көч.

## Урман чәчәкләре

Ак бүлмә, ак түшәм, ак дивар...
Бер үк төс чагыла йөзләрдә.
Тик өметләр генә ак түгел,
Яшәү уты сүнгән күзләрдә.

Яз иде... Берәүнең якыны
Урманнан чәчәкләр китерде.
Ак төсләр кинәттән үзгәрде —
Әйтерсең бүлмәгә яз керде!..

Язмыни?! Бирегә яшәүнең
Җиһаннардан инде ал таңы!
Ни гаҗәп, шул көчләр күтәрде
Ятактан өметсез хастаны.

Тәрәзә төбендә өч чәчәк,
Төренгәндер анда киләчәк...
Бәллүр савытларга куйсаң да,
Тик барыбер алар шиңәчәк.

Урманның шифасы саекмас,
Чәчкәсе-гөлләре шиңсә дә...
Кешенең исеме югалмас,
Бу дөньядан үзе китсә дә...

## Идел ярларында без икәү...

Идел буе... Акчарлаклар оча,
Дулкын кага комлы ярларга.
Гүя һавадагы торналардай,
Җәйләр китә әллә кайларга.

Бигрәк кыска булды быел алар,
Тоеп өлгермәдек рәхәтен...
Ә шулай да бу җәйләргә минем
Килә бары рәхмәт әйтәсем.

Очраштырды, кавыштырмаса да...
Истә бергә булган мизгелләр.
Утырабыз Идел ярларында,
Узганнарны сагына күңелләр...

Иделләргә агып китмәс микән
Без кичергән сихри тойгылар?..
Вакыт тегермәнен әйләндерә —
Иделдә шул башка кайгылар.

Дулкыннары, шыбыр-шыбыр килеп,
Гүя моңлы көйне уйныйлар.
Сез китәрсез, без калабыз, диеп
Уйлыйлардыр алар, уйлыйлар...

## Оныта адәм баласы

Баш өстендә утлар ялт-йолт итте,
Телсез калдым, бетте хәлләрем...
Фәрештәләр гүя ташлап китте,
Сүнде җилдә өмет шәмнәрем.

Караңгыда кинәт ай калыкты,
Нурлар керде ачык тәрәздән,
Ерактан бер якын тавыш килде,
Әллә кайдан, биек гөмбәздән.

Сырхау бәреп еккач, сынауларны
Без бит бергә, бәгърем, кичердек...
Упкын кебек тоелган гүр аша
Яшәү утравына сикердек.

Кешеләрне сынар өчен, ахры,
Кинәт килә икән хасталар...
Ахирәттә генә түгел, бу дөньяда
Бәяләнә бугай хаталар.

Тик аякка баскач, он(ы)та адәм
Ант иткәнен, тәүбә кылганын,
Аяз көндә яшен суккан кебек,
Бер мизгелдә һуштан язганын.

«Исәнлекне сакла!» — дигән күк әмерен
Кирәк иде ташка чокырга.
Бәбиләрдән әбиләргә хәтле
Шул язуны һәр көн укырга.

## Диңгез

Әдрән диңгез! Тибрәләсең күз алдымда,
Сәйдәш моңын ишеттереп колагыма...
Тезләнәм дә чуерташлы ярларыңа,
Сәҗдә кылам... И рәхәт тә җаннарыма.

Уртак дөнья... Бер үк кояш астында без,
Мин — бер гади адәм, ә син — мәшһүр диңгез!
Дулкыннарың тилереп колачлыймын,
Әйтерсең лә иске дусны кочаклыймын.

Еракларда калды безнең туган җирләр,
Диңгезләрне сагынып яши торган ирләр...
Тозлы суларыңның шифаларын сизәм,
Килмәгәннәр өчен кабат-кабат йөзәм.

Иртән сәфәр... Соңгы тапкыр килдем сиңа,
Дулкыннарың шыбыр-шыбыр елый сыман.
Син — мәңгелек! Бу дөньяның кунагы без...
Ә шулай да тәңкә салдым сиңа, диңгез.

## Тагын кайттым*

*(Җыр)*

Тагын кайттым... нигә кайттым соң мин?
Кемнәр көтә монда, ниләр бар?
Яшьлек сукмакларын үлән баскан,
Дуслар киткән, көтми сөйгән яр.

Кайда соң сез, зифа ак каеннар,
Без утырткан нәни юкәләр?!
Чишмәләре кипкән тугайлардан
Сандугачлар киткән үпкәләп.

Вакыт йөге узган урамнардан,
Көмеш баскан әнкәй чәчләрен.
Авылым да карт аналар кебек
Җуйган, ахры, үзенең көчләрен.

Тагын кайттым... ничек кайтмаска соң,
Тарта тамыр, тарта туганнар...
Тау битендә яткан каберләрдән
Дәшә кебек дөнья куйганнар.

Тагын кайттым... Сагынып кайттым әле.
Йөрәкләрдә сагыш, давыл бар...
Ярый әле кайтып сыеныр өчен
Җир йөзендә туган авыл бар.

## Чабата

Бүген аның урыны чормаларда,
Музейларда кайчак күренә.
Әби-бабам хатирәсе булып
Саклана ул һаман күңелемдә.

Аны киеп урман тарттырганнар,
Җир сөргәннәр, иген иккәннәр.
Тула оеклы кызлар аулак өйдә
Нәфис кулъяулыклар чиккәннәр.

Күн итекле болгар бабам аны
Күршесендә генә күргәндер.
«Оныкларым моны кимәсләр!» — дип,
Әле горурланып йөргәндер.

Язмыш борылышы, ләгънәт заман,
Ачлык, ялангачлык чорлары...
Болгар варисы да, антын бозып,
Аны балтырына чорнады...

Татар түрә булса, аның белән
Бизи, диләр, үзенең түрләрен.
Күп йөрсәм дә, олы бүлмәләрдә
Чабатаны бер дә күрмәдем.

Ата-бабай истәлеге булып
Сеңеп калган яшьли күңелемә.
Тарихымны балам белсен диеп,
Мин чабата эләм түремә...
Ә бит читек якын үземә.

## Дәфтәр

Күк йөзендә кояш кына янса,
Яңгыр яумый, карлар төшмәсә...
Йолдыз атылмаса, таң атмаса,
Тып-тын булса... Җилләр исмәсә...
Берәүгә дә әмер килмәсә,
Шашыр иде адәм, китмәсә.
Гомер дәфтәренә кемдер язган, —
Онытмыйча язган һәммәсен.
Кайнар — суык, яңгыр — кояш анда,
Сөю — нәфрәт, көн — төн тезмәсе.
Яшьлек — картлык анда, биләү — кәфен —
Бу дөньядан китү сәгате.
Ярый әле бирелмәгән безгә
Шул дәфтәрне уку сәләте.

## Соңгы яфрак*

Көз җиткәнен күрәм яфраклардан...
Елый-елый җиргә иңәләр.
Моңсу рапсодия... Саргылт әҗәл.
Тереклекне шулай җиңәләр.
Җил очыра, аера яфракларны,
Ташлый суга, илтә учакка.
Кеше язмышлары, тормыш көзе
Чагылып китә миңа шул чакта.
...Өй каршында ялгыз каен тора —
Бер яфрагы калган үзенең.
Җилләр исә, яңгыр-карлар ява,
Ләкин төшми яфрак өзелеп.
Кайдан килә шундый яшәү көче,
Бәйләнеше туган туфракка?!
Кыш буена күз алдымда тора —
Мин сокланам соңгы яфракка.

## Күл*

*(Җыр)*

Күлнең серен сөйли камышлары,
Көне буе сайрый таллары,
Эссе чакта тәнгә сихәт бирә
Төнбоеклы салкын сулары.

Акчарлаклар уйный күл өстендә,
Назланалар җилдә дулкыннар.
Су буенда янган учаклардан
Күтәрелә соңгы очкыннар.

Уйчан да ул, җилле, давыллы да, —
Җилкәннәрне дә ул каера.
Кочагына алып кемнәрнедер
Кайчак мәңгелеккә аера.

## Багышлау

*Танылган журналист Фәрит Иделлегә*

«Азатлык»тан азат булалмассың —

Кендекләрең бәйле түгелме...
Алманнарның китсәң дә иленә,
Җаның калыр монда, Иделле.

Син калырсың татар күңелендә
Акчарлагы кебек Иделнең.
Чын дусларың сине сагынырлар,
Син дә юксынырсың, Иделле...

Бергә чакта үткен сүз, җыр белән
Гомер узмаган да шикелле...
Иделкәйнең суларына баксаң,
Узган икән, дустым Иделле.

Сүзләр китәр, исемнәр дә агар,
Яшәү бит ул фәкать мизгелле...
Гасырларда Идел ага торса,
Татар яшәр, дустым Иделле!

## Юл чатында...

Урам буйлап бара иде...
Чү! Кинәт нәрсә булды?!
Бер ир-егет көпә-көндез
Юл чатында егылды.

Очып китте баш киеме,
Нәрсәседер коелды.
Илтифат итми берәү дә,
Ә бит... кеше егылды.

Йөзләгән адәм узгандыр
Бәла яткан урамнан.
Могҗиза — берәү туктады:
«Нәрсә булды, күз алмам?»

Бу изге җан кайдан килгән,
Белмим, кем булгандыр ул.
Бәлкем, кайчандыр үзе дә
Шулай егылгандыр ул.

## Кеше китә...

*Энекәшем Әнвәр рухына*

Үзгәргәнсең, Бола, өшәнгәнсең, Тимәш,
Язгы кардай эреп бара халкың, димәк.
Мәңгелектә инде энекәшләр, әни —
Искә төшкән саен йөрәкләрем әрни.

Моңлы бала идең, Әнвәр, җырлы идең...
Дәва эзләп күп чак урманнарда йөрдең.
Әрнегәндер күңлең, сизенгәндер җаның
Бары тик санаулы көннәрең калганын.

Кабереңә чәчәк тотып килгән чакта,
Моңлы каен җырлап тора синең хакта:
«Чәчкәләрнең кирәге бар, — дия сыман, —
Килмәсәгез, кайгылардан мин дә сынам».

Бола суы нишләп шулай моңсу ага,
Дулкыннары гүя яраларга кага...
Кеше китә — тик җырлары гына кала...
Исәннәрне сәфәр көтә, дәшә кала.
Хуш, авылым! Текә ярда әткәй кала,
Бөтен сагыш әйтерсең лә аңа кала.

## Ялгыз әткәй*

Төн уртасы... Авыл изрәп йоклый,
Тик бер тәрәзәдә ут яна.
Таңга хәтле әткәй газаплана,
Ялгызлыктан бәгъре сызлана.

Сигез бала үсеп таралышкан...
Дөнья куйган әнкәй иртәрәк...
Шулай килеп чыга — ахирәткә
Изге җаннар иртә китәләр.

Ялгызлык вә тынлык — ике афәт,
Гүр сагышы бардыр аларда...
Ярый әле төнлә буран кубып,
Симфония уйный калайда.

Күз алдыннан йөгереп еллар уза,
Ишетелә тальян моңнары...
Чү! Ишектә тавыш ишетелде —
Кайтып төште көткән уллары.

Кызларың да кайтыр, туган йортка
Юктыр әле юлны оныткан...
Тирә-юньгә яшәү нуры сибеп,
Тыз-быз килеп чабар оныклар...

Әллә кая кереп поса шулчак
Җан ярасы — шомлы ялгызлык.
Күз алдында әткәй рух яңарта,
Хет бер төнгә җиңә явызны...

Күрешүләр — мизгел, уза-китә,
Аерылу кыса — һава юк!
Ансына да чыдар идең дә бит,
Ялгызлыктан гына дәва юк...

## Әгәр мине шулай яратсаң...

Уянам да йоклый алмый ятам...
Уйлар баса кайчак төннәрен...
Нигә яшим бу фани дөньяда,
Кирәкмәсәм әгәр кемгәдер?!

Мал җыюдан һәрчак өстен булдым,
Мин фәлсәфә ташын эзләдем...
Биеклеккә менеп, дөнья көтүләрем
Кирәк иде кебек кемгәдер.

Авырлыклар килсә, чигенмәдем,
Дошманнарга серем бирмәдем.
Өмет учакларын сүндермәвем
Кирәк иде кебек кемгәдер.

Хыянәтләр, яла ягулардан,

Һөҗүмнәрдән куркып үлмәдем.
Сизә идем — шулай яшәүләрем
Кирәк иде кебек кемгәдер.

Еллар үткәч кенә аңладым бит:
Бөтен хикмәт синдә ләбаса!..
Бу дөньяда озак яшәр идем,
Син дә мине шулай яратсаң...

## Юлъязмалар

### Татар — Африкада да татар

Поездда да йокланмый. Җитмәсә, салкынча. Инде чикләр үтелгән, документларга тиешле мөһерләр сугылган, Ригага да ике-өч сәгатьлек юл калып бара. Вагоныбыз хуҗабикәсе Ирина да йокламый. Ул зур табактагы мүк җиләген чүпләп, чистартып утыра. Поездда барганда проводниклар белән сөйләшү журналист кешегә шактый кызыклы мәгълүмат тупларга мөмкинлек бирә.

Марҗа булса да, Ирина үзе туып үскән Латвия иле, латышлар турында бер кәлимә дә начар сүз әйтмәде. «Эшләгән кешегә кайда да бер...» Ә мүк җиләге Русиядә күпкә очсызрак икән. Ирина аны җае чыкканда сатып ала да, Ригага кайткач, базарда сәүдә итүче танышына бирә. Кыскасы, үзенә күрә бизнес. Әңгәмәбез кинәт өзелде — тамбур ишекләре шыгырдавын ишетеп, Ирина табакны алдан әзерләп куйган газета белән җәһәт кенә каплап куйды. «Бригадир!» — дип пышылдады ул һәм форма кигән озын буйлы ир кешегә каршы чыкты.

Шефы проводницага каты бәрелмәсен өчен мин, югалып калмыйча:

— Вагонда бик суык, бераз җылытып булмыймы? — дип, поезд нәчәлнигенә урысча мөрәҗәгать иттем.

Ул кырт кисте:

— Бездә сездәге кебек нефть скважиналары юк!

Акцентыннан аңлашылды: бригадир латыш икән. Димәк, дөрес булып чыга: 1917 елда революцияне саклап калырга булышкан атаклы кызыл латышлар варислары бүген урысча сөйләшүчеләр белән үзләрен дорфа тоталар. Хәер, бу ике халык арасындагы салкынлыкның сәбәпләре күз алдында. Латвиядә урыс телендә нәшер ителә торган басмалар, җае чыккан саен, төп халыкны, хөкүмәтне «тәпәләп» торалар. «Хокукларыбыз кысыла!» — дип, дөньяга кычкыралар. Үзен һаман да «старший брат» дип хис иткән милләт җирле халыкның телен өйрәнергә теләми. Латышларның урысларны өнәмәве, күрәсең, тарихи вакыйгаларга да бәйле. Мәгълүм ки, Латвия җөмһүрияте 1918 елда игълан ителә. Шуннан соңгы чорны латыш тарихчылары болай исәпли: 1940—1991 еллар — совет оккупациясе чоры, 1991—2003 еллар — Европага кайту. Оккупация чоры, бәйсезлекне югалту тарихта калса да, күпләрнең хәтерендә үпкә, йөрәкләрендә яра әле дә яши. Әле совет чорында бер гаепсезгә Себергә сөрелгәннәрнең кайберләре исән, аларның варислары да урысларга тәлинкә тотарга теләми. Нәрсә хөрмәтенә? Латышлар бәйсез дәүләтләрен, тарихи гаделлекне торгызу белән нык шөгыльләнәләр. Латвия җиренә гаскәр тутырып, төрле гигантлар торгызыр өчен Русия төбәкләреннән бихисап эшчеләр китереп, СССР хөкүмәте латышлар санын урыслар белән тигезләгән иде. Бүген дә әле алар барлык халыкның 58,5 процентын гына тәшкил итәләр, ә урыслар — 29 процентны. «Ригада татарча сөйләшсәгез, җайлырак булыр» — монысын безгә Латвиядә сәяхәт итеп кайтучылар әйткәннәр иде инде.

Ригада, нигездә, татарча сөйләшеп йөрдек. Ни әйтсәң дә, без, Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре, биредә яшәүче милләттәшләребез белән очрашырга, аларның проблемалары турында сөйләшергә килдек бит. Алай гына да түгел, үзебез белән бер төркем танылган татар артистларын алып бардык: Резидә Шәрәфиева, Айдар Габтдинов, Равил Харисов, Гүзәл Мостафина. Балтия илләрендә, Беларусь, Германия, Финляндиядә яшәүче татар җәмгыятьләре җитәкчеләренең җыелышы алдыннан сәнгатькәрләребез Риганың музыкаль академиясе бинасында татарча матур концерт куйдылар. Баштарак залда утыручыларның татарчасы чамалы дип уйлаган булсак та, ялгыштык. Концертка килгән, нигездә, урта һәм олы яшьтәге милләттәшләребез җырларны гына түгел, юмористик шигырьләр сөйләүче мин фәкыйрегезне дә, соңрак сәхнәгә күтәрелеп тирән мәгънәле шигырьләр укыган шагыйрь Разил Вәлиевне дә алкышлап каршы алдылар, дикъкать белән тыңлап утырдылар.

Шулай да дүрт меңгә якын милләттәшебез яшәгән Латвиядә ана телебез югала бара. Яшьрәкләр белән урысча сөйләшеп аңлашырга туры килә. Хәер, арада искәрмәләр дә очрап куя. Рига вокзалында безне чәчәкләр һәм чәкчәкләр белән каршы алган яшьләр арасында үзе чәчәктәй гүзәл Лена Газизова, мәсәлән, та-

тар телен аңлый, аз булса да сөйләшә һәм, иң мөһиме, милләтебезгә, аның мәдәниятенә тартыла торган туташ булып чыкты.

Польша, Литва, Беларусь, Эстониядән килгән, инде ана телләрен югалткан җәмгыять вәкилләре Конгрессның башкарма комитеты уздырган күчмә утырышта нотыкларын нигездә урысча сөйләделәр. Барысы да аңласын өчен. Ә бу чарада куелган мәсьәләләрнең биредә яшәүче милләттәшләребез өчен актуаль икәнлеге яхшы аңлашылды. Балтия илләре бүген инде чит мәмләкәтләр рәтенә керә, анда виза белән барасы. Күчмә утырышта биредәге татарларның яңа вазгыятькә яраклашуы, рәсми хакимият даирәләре белән уртак тел табып эшләве, милли җәмгыятьләр арасында бердәмлекне ныгыту турында зур сөйләшү булды, кайбер катлаулы мәсьәләләрне чишү буенча акыллы тәкъдимнәр яңгырады. Финляндия татарлары исеменнән чыгыш ясаган «Исламия» җәмгыяте рәисе Окан әфәнде Дахер, мәсәлән, Суоми илендә гасырлар буена тупланган үзара тату яшәү һәм бергәләп милләтне саклап калу тәҗрибәсе белән уртаклашты. Соңрак Финляндиядә яшәгән милләттәшләребезнең тәҗрибәсен өйрәнү зарурлыгы Башкарма комитетның карарына да кертелде.

Латвиядә яшәүче милләттәшләребезнең үзара килешеп эшләве бигрәк тә мөһим мәсьәлә булып тора. «Идел» җәмгыятенең ике оешмага бүленүе, низагның матбугат битләренә чыгуы инде күпләргә мәгълүм. Хәер, бу юлы ике як та, әллә әдәп саклап, әллә киләчәктә берләшер өчен юл табу йөзеннән, бер-берсенә мичкә тәгәрәтмәделәр.

Инде әйткәнебезчә, күчмә утырышта катнашучы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Закиров та, Латвиянең рәсми хакимият вәкилләре дә, Балтия илләрендәге татар җәмгыятьләренең лидерлары да үз хөкүмәтләре белән аңлашып, ярдәмләшеп эшләүләре турында канәгатьләнеп сөйләделәр.

Ригада ошбу мәшәкатьле чараны оештыручы, Латвия татар-башкорт мәдәни җәмгыяте рәисе Зөфәр Зәйнуллин беренчеләрдән булып латыш теленнән имтихан тоткан, гражданлык алган. Бу гамәле белән ул үзенең бизнесын да, җәмәгать эшләрен алып баруны да бермә-бер җиңеләйткән. Башка милләттәшләребез дә, яшенә, шөгыленә карамастан, җирле халыкны хөрмәт итеп, аның телен өйрәнү курсларына язылганнар. Шуңа да татарлар биредә үзләрен ятим бала кебек хис итмиләр, гәрчә туган якларын, тарихи ватаннарын сагынып яшәсәләр дә.

Сүз уңаеннан әйтеп үтим, Балтия илләрендә яшәүче милләттәшләребезнең бирегә килеп урнашулары төрлечә булган. Шуңа карап, җирле халыкның да татарларга мөнәсәбәте һәр илдә дә бертөрле түгел.

Литвага безнең борынгы бабаларыбызны бөек кенәз Витаутас 600 ел элек үзе чакырып китергән. Алар Литваның бәйсезлеген саклап калуга зур өлеш керткәннәр. Грюнвальд бәрелешендә татар җайдакларының батырлыгы аркасында гына Витаутас тарихи җиңү яулый. Бөек кенәз татар яугирләренә рәхмәт йөзеннән аларга яхшы җирләр, дворян титуллары бирә. Ә инде Латвиягә, Эстониягә, әйткәнемчә, татарлар 40 нчы еллардан соң килеп урнашалар. Кемдер гаскәри булып, кайсылары социализм гигантларын күтәрер өчен.

Балтия илләре белән аралар географик яктан үзгәрмәсә дә, визалар, таможнялар кертелгәч, күрешүләр бермә-бер сирәгәйгән. Шуңа да милләттәшләребез Казаннан килгән делегация әгъзаларын бик сагынып, хөрмәтләп, зур кунакчыллык күрсәтеп каршы алдылар.

Ригада бер генә тәүлек булсак та, коеп яңгыр явып торса да, күрешүне оештыручылар бу гаҗәеп шәһәрнең иң истәлекле урыннарын тыштан булса да күрсәтә алдылар. Кояшлы көннәрдә Даугава суларында күпсанлы манаралар, чиркәү шәүләләре сызылып ята, диләр. Биредә һәр адымда Европа шәһәрләрендә төрле чорда барлыкка килгән төзелеш һәм архитектура чалымнарын күрәсең. Атаклы Штирлицның агенты профессор Плейшнерның соңгы шпионлык гамәле дә Рига урамында төшерелә. Совет чорында режиссерлар чит ил пейзажларын эзләп ерак йөрмәгәннәр. Бирегә килеп төшергәннәр. Латвия башкаласының атаклы Домский соборы, аның эчендәге гүзәл галереялар, 200 ел элек куелган һәм дөньяда иң зурлардан саналган орган, күпсанлы музейлар турында тәфсилләп яза алмыйм, ни кызганыч, без аларны күрергә өлгермәдек.

...Чуерташлы Рига урамнарында биредә яшәүче төп халыкка аңлашылмаган татар телендә рәхәтләнеп сөйләшеп йөрүебез безне шыксыз, яңгырлы көнне җылытты сыман тоелды миңа. Бер ярты сәгать элек кенә «Неллия» мәдәният үзәгендә узган җыелышта Ригада яшәүче шагыйрь Дамир Рафиков укыган шигырь искә төште.

Мы верим, что казанский брат
С прибалтоземляками в паре.
Наш сохранит родной уклад.
Татар — и в Африке татарин!

Очрашуда башка шигырьләр дә яңгырады, ләкин Дамир Рафиков язган сүзләр күңелгә оптимистик ядкарь булып уелып калды.

Ә инде вокзалга безне озатырга төшкән милләттәшләребез арасында гүзәл татар кызы Лenaның кинәт перронда күренүе болытлы көндә кояш балкып чыгуы белән бер иде. Җитмәсә, ул, минем янга килеп, үзе-

нең рәсемен бүләк итте. Фоторәсемнең арткы ягында «Безне онытмагыз!» дип, мәгънәле ике генә сүз язылган иде.

Ничек онытасың?..

*Казан—Мәскәү—Рига—Мәскәү—Казан*
*октябрь, 2004*

## Бардым, җаныем, Донбасска…

### *Шахтер кызы*

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Донбасска...

«Шахта» көендәге сагыш, аерылу газабы, моң, туган җирләрне ташлап күз күрмәгән якка китүчеләрнең хисләрен шулхәтле төгәл ачып сала ки, әйтерсең лә ул һәрбер мосафирга кагыла.

Мин дә, Донецк аэропортына төшкәнче, күңелемнән әнә шул җырны көйләп бардым.

Шахтер егет күмер чаба,
Кемнәр ала исәбен?
Гомерем булып таш басмаса,
Ташламам, җанкисәгем...

«Шахта» көен ишеткән саен, пенсионер Зәйнәб апаның да күзләренә яшьләр килә. Бу җыр аның бәгырьләрен генә телеп калмый, ул аны, канатларына утыртып, үсмер чакларына алып китә. Әткәй-әнкәй, бабакайларның туган җирләрен сагынып хасталанган чакларын исенә төшерә ул. Гәрчә Зәйнәб апа үзе шушы Нахаловка дигән татар бистәсендә туып, 70 ел күмер тузанын сулап яшәгән кеше булса да.

Ләкин казлар киткән һәм кайткан саен, шахтер кызы Зәйнәб аларны кулын каш өстенә куеп озатып кала, каршы ала. Ерак Мордовия, Торбеево якларына да очалардыр казлар. Зәйнәб апага әти-әнисе туган җирләрне күрергә насыйп булмаган. Һәм булмас та, ахрысы. Туган-тумачалар, балалар, оныклар биредә — ике канат астында...

Бабаларының әллә бәхет эзләп, әллә бөек социализм төзелешләренә фәрман белән Донбасс якларына кайдан килеп урнашуларын Нахаловкада кемдер белә, кемдер инде белмидер дә. Чөнки биредә берничә буын алмашкан. Кешеләр шушы ташлы-күмерле җирдә төпләнгәннәр, тамыр җибәргәннәр, өлешләренә тигән алтыннарын-көмешләрен тапканнар.

Донецкида мине каршы алып озатып йөргән Рәшит Брагинның да балачагы, яшьлеге шушы бистәдә узган.

### *Чикләр*

Украина бүген безгә якын булса да, чит ил. Донецк өлкәсе аның бер саллы өлеше, көч-куәте, сәнәгате, байлыгы, 4 миллионга якын халкы белән илнең горурлыгы булып тора. Заманалар хәзер шундый: Мәскәүдә Внуково аэродромында ук дәүләт чиген, таможняны узасың. Очкычта да, аэропортта да аралашу нигездә урысча. Донецк урамнарында да реклама урыс телендә. Шулай да ара-тирә украинчалары да очрап куя. Оешма-ширкәт исемнәре ике телдә. Телевидение, матбугат күбесенчә урысча сөйли, яза. Татарлар да ешрак бераз бозып булса да бөек Толстой телендә аралашалар. Дөресен әйтим: монысы безгә тормышны күпкә җиңеләйтә.

Бу баруымда миңа дәүләт чикләрен һавада гына түгел, җир өстеннән дә узарга туры килде. Ял көне, Рәшит әфәндeнең машинасына утырып, Донецкидан Ростов өлкәсенең Таганрог шәһәренә бер көнлек сәяхәт кылырга чыктык. Юлда барганда шахтерлар күпләп яшәгән әле дә күмер чыгарыла торган атаклы Макеевканы уздык. Биредә дә, башка шәһәр һәм бистәләр кырыенда да ясалма каф таулары — терриконнар атлаган саен очрый. Аларның өстендә акациядән гайре бернәрсә үсми икән. Җир астыннан чыккан бу массаны авыл хуҗалыгында да кулланып булмый — радиацияле икән ул. Җил искән саен кышын тирә-юньдә яткан карны, ә җәен агач-яфракларны, чәчкәләрне кара төскә буяп торучы малярлар — әнә шул күмер комы таулары. «Бездә ак күлмәк — биш минутка», — дип шаярталар шахтерлар.

Успенка дигән чиктәш постка бик тиз килеп җитсәк тә, Украина ягында тезелеп киткән машина чиратын күреп, гаҗәпкә калдык. Баксаң, тормыш анда да бер, монда да бер, нигә хохоллар Рәсәйгә чират торып керә соң? Хәер, монда милләт тә, Рәсәй дә ни причум икән. Таганрог Азов диңгезе ярларында урнашкан. Анда балык базарлары мул, бәһаләре дә очсыз. Җитмәсә, ял көне кайберәүләр һава алмаштырып, җилләнеп тә кайталар.

«Ә бит әле кайчандыр гына таганроглылар Донецк базарларына, кибетләренә еш киләләр иде, — дип искә ала Рәшитнең дусты эшкуар Николай. — Чөнки ул вакытта чикләр юк иде, ә шахтерларга аерым игътибар бар иде...» Кыскасы, күмер чокучыларны хөкүмәт иң кыен чорда да арзан азык-төлектән өзмәгән.

Дөрестер ул. Хатынымның әтисе сугышка хәтле үк Макеевка якларында ФЗӨдә (төзүчелеккә) укырга барган, шунда бераз эшләп тә алган. Бабай 60 ел узгач та онытмый: ашау яхшы, кибетләр арзан ашамлыклар белән тулы иде, ди. Килеп бер-ике ай узмаган, стипендия акчасына ул туган авылына хәтта ике посылка шикәр җибәргән. Бәлкем, безнең татар бу якларга җырлый-җылый адәм рәтле тормыш итеп булмасмы дип тә килгәндер...

Чик сакчылары, таможня хезмәткәрләре миңа, Россия гражданинына, әллә ни сораулар биреп тормадылар, ә менә Рәшиткә тирләп-пешеп иммигрант кәгазен тутырырга туры килде. Монысы яңа кагыйдә буенча икән. Ә алар мондый постларда ай саен үзгәреп тора. Әйтергә кирәк, халык бу чик бюрократиясен тозлап-борычлап сүгә, һаман да күнегә алмый. Бер илдә яшәдек, понимаешь, атлаган саен койма-киртә, граница куеп чыктылар. Кемгә кирәк иде... Икенче яктан карасаң, Украина — мөстәкыйль дәүләт! Ассимиляция шаукымына эләгеп урыслаша барган украиннар хәзер мәскәүчә яшәргә теләмиләр.

## *Донбасс — татар ягы*

Донецк заманында СССРның иң яшел матур шәһәрләренең берсе дип санала иде. Чагыштырмача яшь кала. Аның беренче нигез ташы 134 ел элек салынган. Тәүге исеме — Юзовка, соңрак ул икенче исемгә ия булган — Сталино. Мәгълүм ки, шәһәр 1941—1943 елларда немец оккупациясен кичерә. 1961 елдан ул Донецк исемен йөртә. Шәһәр — күмер һәм металл башкаласы. Аның бу ягына аерым тукталып торасым килми. Тик әйтми булмый: шәһәр тирәсендә 20 гә якын шахта бүген дә күмер чыгара. Элеккеге СССР илләрендәге икътисади парадокс Донецк шахталарын да читләтеп узмаган. Донбасста чыгарылган күмер бәһасе бүген Польшадан китерелгән күмердән кыйбаткарак төшә. Андый парадокс бездә дә очрап тора. Хәтерлисезме, мал сатам, бәһасе заводныкыннан арзанрак...

Хәер, сәяхәтемнең максатыннан бераз читкә тайпылдым бугай.

Донецк татарлары бик кунакчыл булып чыктылар. Казаннан килгән кунак белән очрашу да шәһәрнең матур бер җирендә урнашкан татар кафесы «Гөлфидан»да узды. Аны берничә ел элек ирле-хатынлы Вәлиевләр ачкан икән. Бирегә өлкә татар җәмгыятенең иң танылган шәхесләре чакырылган иде. Чәйле-мәйле табын артында дустанә сөйләшү булды. Ул кичтә кафеда татар, украин, рус җырлары, туган телдә сөйләшү өзелеп тормады.

Яхшылап танышу өчен мин табындашларымны, һәркайсына үз вакытын билгеләп, иртәгәсен шул ук кафега чакырдым. Вәгъдәләшкәнчә, милләттәшләр килә торды, мин магнитофон төймәләренә баса тордым...

60 яшьлек Әхмәт ага Чанышевны, кылган гамәлләре, җәмгыятьтә тоткан урынын исәпкә алсаң, чын аксакал дип атап була. 40 ел буена ике меңгә якын кеше эшли торган автотранспорт ширкәтен җитәкли, халык депутаты да, Украинаның атказанган транспорт хезмәткәре дә, СССРның Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнгән шәхес тә ул.

Әхмәт абый, андагы татарлар кебек урысча-мишәрчә сөйләп, бер фикерне кабат-кабат сеңдерде: Татарстан, татарлар белән элемтәләрне ныгытырга, ешрак күрешергә, аралашырга кирәк.

Юрист Рамил Әмиров — заманында Гдлян төркеме белән серле үзбәк йомгагын сүткән прокурорларның берсе. Хәзер адвокат. «Командировкаларда йөргәндә, татар кешесен очратсам, аннан да зур шатлык булмый иде», — дип искә төшерә Рамил. Эстониядә ниндидер җинаять эшен тикшергәндә бер татар кешесенең фамилиясенә тап булгач, аны повестка белән берничә тапкыр үзенә чакырткан. Бәхеткә каршы, аның җинаятькә катнашы булмаган, ул шаһит буларак кына барган. Инде ничә ел вакыт узса да, Эстониядә яшәүче татар шаһит Хәмит Шәйдуллин белән юрист Рамил Әмиров хәзергә хәтле аралашып-күрешеп яшиләр икән.

Медицина фәннәре докторы, профессор Рифат Грачевның да тамырлары Мордовиядән, үзе 1943 елда Донбасста туган. Заманча җиһазландырылган клиникасы бар, өлкәнең мөселман фиркасе рәисе. «Без фундаменталистлар түгел. Соңгы вакытта мөселманнарга карата негатив караш зур... Нишлисең, безгә беркайчан да җиңел булмады», — дип фикерли профессор. Нәсел-нәсәбәсе — табиблар: биредә яшәүче Рушан Айзатуллов һәм Семен Такташев та танылган профессорлар. Бер ягы белән Кырым татарларыннан булган Алим Ширинский искиткеч ир-егет икән: менә дигән баянчы, өлкә Советы депутаты, «Южтрансстрой» дигән фирманың генераль директоры. Милли хәрәкәтләргә ярдәмчел бер кеше. «Яңа буын җитәкчеләр — акыллы егетләр, алар белән эшләп була», — дип саный Алим әфәнде.

Рәүф Әбдикеев Куйбышев районының хәрби комиссар урынбасары, тумышы белән Пенза ягыннан, бабалары — шахтерлар. Рәүфнең энекәше Руслан Каһирәдә университетта укый. Быел җәйгә укуын тәмамлап, Украина ислам университетында мөгаллим һәм биредәге ике манаралы зур мәчеттә имам булып эшләячәк.

Әлбәттә, берничә көндә Донецк өлкәсендә яшәгән булдыклы милләттәшләребезнең һәркайсы белән сөйләшеп тә, танышып та өлгермәдек. Мәсәлән, аралашканда еш кына Украинаның Югары Рада депутатлары Татьяна Бахтеева, Равил

Сафиуллин исемнәре яңгырады. Равил әфәнде Украинаның профессиональ футбол лигасының президенты да икән әле. Хәер, Донецкидагы футбол турында без әле соңрак сөйләрбез.

Танышу кичәсендә иң аз сүз тоткан ике кеше турында аерым әйтмичә булдыра алмыйм. Алар — Украина мөселманнар шурасы рәисе, Донецк шәһәр Советы депутаты Рәшит Брагин һәм аның уң кулы — Донецк өлкәсе татарларының мәдәният үзәге җитәкчесе Фәридә Хафизова.

### *Ринат, Рәшит һәм Фәридә*

Милиция хезмәткәре Рәшит Брагинның язмышы 1995 елда кискен борылыш ясый. Донецкида яшәгән милләттәшләребез тормышында ул көзге көн онытылмаслык кара эз калдыра.

15 октябрь кичендә Рәшитнең туганы Әхәт Брагин һәм аның дус-ишләрен, тән сакчыларын стадионнан чыгып барганда шартлаталар. 8 кеше шундук һәлак була, берничәсе яралана.

Әхәт Брагин — «Шахтер» футбол клубының президенты — яңа икътисади шартларда эшләрен җайга сала, үз тирәсенә талантлы яшьләрне җыя, дини һәм милли оешмаларга зур ярдәм итә башлый. Мәгълүм ки, 90 нчы еллар Рәсәйдә дә, Украинада да милек бүлү, конкурентларны астыртын рәвештә юк итү кебек канлы гамәлләр белән тарихка кереп калды.

Җинаятьтән соң 8 елга якын гомер узып китсә дә, аны оештыручыларның кайберләре кулга алынса да, мәхкәмә эше әле дә дәвам итә. Кайберәүләр, бу коточкыч вәхшилек артында Украинаның элеккеге премьер-министры Павел Лазаренко торган, диләр. (Ул хәзер, ришвәтчелектә гаепләнеп, Америка төрмәләренең берсендә утыра.)

Әхәтнең игелекле эшләрен аның туганнары, дуслары, ярдәмчеләре үз кулларына алалар: Ринат Әхмәтов, Рәшит Брагин һәм башкалар. Рәшитне милиция хезмәтендә зур карьера көткән булса да, ул, Әхәт һәлак булгач, дин һәм милләт эшләрен тулаем үз өстенә ала. Ринат исә бизнес, эшкуарлык белән шөгыльләнә башлый. Әхәтнең истәлегенә Донецк шәһәренең матур бер җирендә ике манаралы зур мәчет күтәрелә. Аны мөэмин-мөселманнар, буш вакытларында төзелешкә йөреп, хәйрия җыеп, иганәчеләр табып, үзләре төзиләр. Манараларның берсен Ринат үз акчасына салдыра, ә мәчеткә Әхәт исемен бирәләр. Биредә бүген мәчет кенә түгел, ислам университеты да, татар милли җәмгыяте дә урын тапканнар.

Рәшит күп вакытын, эшләп тапкан хәләл малын дини оешмаларга, ярдәмгә мохтаҗ милләттәшләребезгә, татар җәмгыятенә биреп бара. Аның кебекләр күптән череп баеган булыр иде дә, тик Рәшит Әхәт туганының исән чакта «Динебезгә, милләтебезгә ярдәм ит!» дип әйткән сүзләрен онытмый, алардан чыкмый.

Ә инде байлык дигәннән, Ринат Әхмәтовка Донецкида гына түгел, Украинада да тиңнәр юк диярлек. 36 яшьлек, бик аз сүзле мөлаем татар егете — «Шахтер» спортклубының президенты, Ауропада танылган эшкуар. Мин Украинада сәяхәт кылып йөргән көннәрдә «Комсомольская правда» шул ил өчен махсус чыгарылышында миллиардер Ринат Әхмәтовның арзан бәягә зур ширкәтләрнең акцияләрен сатып алуын тәнкыйтьләп чыкты. Ә бит бөтен дөньяда акция сату-алу кыңгыр гамәл түгел, эшкуарлыкның төп бер юнәлеше. Сүз бит урлау, талау турында бармый. Заказ биреп яздырган мәкалә кара пиар конкурентларның йоклап ятмавы хакында сөйли.

Ринат Әхмәтовның игелекле, ярдәмчел бизнесмен икәне турында Киевта очрашканда Кырым татар халкының мәшһүр лидеры Мостафа Җәмилев миңа болай диде:

— Ярый әле Ринат ярдәм итеп тора. Югыйсә мин «Алтынчы процесс» дигән китабымны да нәшер италмас идем, Украина парламентына да сайлана алмас идем...

Бәлкем, хәтерләре әйбәт кешеләр онытмаганнардыр, Казан—Донецк арасында узган ел ахырында хезмәттәшлек итү турында килешү имзаланды. Казанлылар Донецкидагы ислам университетына һәм татар җәмгыятенә компьютерлар бүләк иттеләр. Шуннан соң Ринат Әхмәтов, үзенең очкычына утырып, Казанга килде. Президент Минтимер Шәймиев белән очрашты. Ике арада эшкуарлык җепләре дә ныгый башлар. Китәр алдыннан, кунак ашы — кара каршы диптер инде, Ринат әфәнде Казандагы Россия ислам университетына «Газель» микроавтобусы бүләк итеп калдырган.

Быел Казан шәһәре Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты ярдәме белән Донецкида сабан туе уздырырга ниятләнә, «Шахтер» һәм «Рубин» футбол клублары арасындагы хезмәттәшлек тә башланып китте дияргә була.

Сүз уңаеннан «Шахтер» командасының Украина чемпионатында атаклы «Динамо»ны (Киев), «Днепр»ны (Днепропетровск) артта калдырып беренче урында баруын әйтеп үтәргә кирәктер. Ринат Әхмәтовның «без быел кубокны да, чемпион исемен дә алачакбыз» дигән сүзләре бер дә мактануга гына охшамаган.

Ә инде Фәридә Хафизовадан башка Донецк өлкәсендәге татар тормышын күз алдына да китереп булмый. Алар Рәшит белән бергә кайчандыр татар учагын кабызып җибәргәннәр. «Мәшәкатьле булса да, үзебез исән чакта без аны сүндермәячәкбез», — диләр Украинадагы милләттәшләребез.

Өлкә татар мәдәни үзәге оешканга 5 ел тулды. Биредә яшәүче милләттәшләребезне барлау, якшәмбе мәктәпләрен эшләтеп килү, бию ансамбленең региональ бәйгеләрдә лауреат булуы, Донецк өлкә телевиде-

ниесе тарафыннан татарлар турында ике документаль фильм төшерүе — болар барысы да Фәридәнең зур тырышлыгы аркасында ирешелгән нәтиҗәләр. Ә менә «Өлкәдә күпме татар яши?» дигән гади бер сорауга сезгә бирелә төгәл җавап бирүче булмас. Кемдер «80 мең» дияр, кемдер «100 мең» дип тә әйтер. Чөнки чит илләрдә төп милләттән булмаган халыкларны чама белән генә саныйлар. Татар җәмгыятенең баш авырттыргыч проблемалары да җитәрлек. Милли класслар тагын да күбрәк кирәк, татарча гәҗитме, журналмы чыгарырга теләк зур — әлегә мөмкинлекләр әз. Берничә ел татар балалар ансамбле эшләп килгән килүен. Ә менә җитәкчесе стажировкасын тәмамлап Казанга кайтып киткәч, репетицияләр тукталган.

Сер итеп кенә әйтәм: тиздән Фәридә ханым беренче тапкыр Казанга киләчәк. Үтә кызыксынучан журналистлар, аның белән күрешеп, үзләре сөйләшә алалар.

### *Киевта да татар бар...*

«Донецк—Киев» очкычы көчле буран аркасында Украина башкаласына ике сәгатькә соңарып килеп төште. «Туган тел» Бөтенукраина милли мәдәни үзәге урнашкан Шелковичная урамындагы кечкенә бинада Казан кунагын ахыргача көтәргә булганнар.

— Безнең үзәк 14 оешманы берләштерә, — дип санап китте аның рәисе Кәнәфия Хөснетдинов, вакытның тар икәнен аңлап.

Өстәлдә яткан төсле журналларны, буклетларны, аудиокассета һәм CD дискларны күргәч тә «Туган тел»нең тик ятмавына ышанасың. Җәмгыятьләр каршында үзешчән сәнгать коллективлары, якшәмбе мәктәпләре ачып җибәргәннәр. «Ләйсән» балалар ансамбле Польшадагы конкурсларда катнашып дипломнар алган, «Сөембикә варислары» конкурсы лауреаты да. Киевтагы туташ-ханымнар да, «Шатлык», «Асылъяр» дип аталган ансамбльләрдә җырлап, татар җәмгыятенең данын ил буенча тараталар.

Кәнәфия әфәнде әйтүенчә, кирәк чакта ул Украина хөкүмәте җитәкчеләренең, хәтта президентының кабинетына кереп, милли азчылык вәкилләренең гозерен аларга җиткерә. Фидакарь хезмәте өчен Кәнәфия Хөснетдинов «Украинаның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек булган.

Очрашуда гәҗит битләрендә мактап телгә алырлык милли җанлы ханым-әфәнделәр тагын да бар иде.

Ана Дала күкрәгендә,
Тәңре— Күкнең баласы.
Татарларның йөрәгендә
Хөрриятнең тамгасы.

Бу шигъри юлларның авторы Саба якларыннан Украинага килеп төпләнгән Равил Низамиев — Киевтагы Г.Тукай исемендәге татар җәмгыяте рәисе. Бирелә тупланган милләтпәрвәрләр дә төрле игелекле чаралар уздыралар, башка җәмгыятьләр белән ярыша-ярыша эшлиләр. Әмма Г.Тукай җәмгыятен мин нишләптер «Туган тел» Бөтенукраина милли мәдәни үзәге исемлегендә очратмадым. Анда шулай ук Донецк өлкә татарларының мәдәният үзәге дә күренмәде. Монысы хакында сүз күтәрүче булмады. Әллә Украина татарлары арасында да бердәмлек җитеп бетми микән дигән фикер калды. Монда да татар яшәгән башка җирләрдәге кебек бүлгәләнү, амбиция чалымнары сизелә. «Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?» Бу әйтем безнең татар милли хәрәкәтенең халәтен бик төгәл чагылдыра. Менә шуны чишү формуласын табасы иде. Бәлкем, без дә ул чакта бердәм булыр идек. Атыбыз да тук булыр иде.

Киевтагы татарлар белән очрашканда, Равил әфәнде Низамиев, мәсәлән, бер милләт кысаларында гына ябылып яшәргә ярамый, мәдәният диалоглары булсын, Евразия идеяләре, туранчылык төрки-татарларны берләштерергә тиеш дигәнрәк мәгънәдә чыгыш ясады. Якын арада Равил Низамиев Киевта Евразиячелек хакында фәнни-гамәли конференция оештырырга тели. Бу хакта ул төрле даирәләргә, шул исәптән Бөтендөнья татар конгрессына да чакырулар юллаган.

Киевның гүзәллеген күрергә теләсәң, анда каштаннар чәчәк аткан чорда барырга кирәк, диләр. Хәер, мин Украина башкаласының хәтта яңгырлы март аенда да чиста, уңайлы, матур икәненә игътибар иттем. Алай гына да түгел, Киев төзелә, төзекләндерелә, димәк, ил киләчәккә карый.

Мостафа Җәмилев белән Рәшит Брагин депутат эшләре буенча Транспорт департаментында мәшгуль булган арада, мин мәркәздәге урамнарны йөреп әйләндем. «Хатинька» дигән кафедан милли музыка яңгырап тора иде. Керсәм, ул украиннарның йорты-хатасы рәвешендә эшләнгән гаҗәеп бер туклану урыны икән. Бирелә милли киемле кызлар-егетләр хезмәт күрсәтәләр, кафе-йортның төрле почмакларында халык һөнәрләренең өлгеләрен күз алдында ук ясарга да өйрәтәләр.

Барга килеп бер-ике сүз әйтүемә, зәңгәр күзле украин кызы:

— Сез кайдан? — дип сорады.

— Казаннан, — дигәч, ул шатланып кулларын җәеп җибәрде.

— Ой, безнең директор Роза Александровна да Казаннан!

— Соң, таныштырыгыз алайса!

Барменның йөзенә күләгә төште:

— Ах, әле генә ярты сәгатькә дип шәһәргә чыгып киткән иде...

Ә минем күтәргә вакытым юк иде.
Ул арада депутатлар гозерләрен башкарып урамга чыктылар.
Мостафа әфәнде:
— Закиров, Закиров... Кырымлы булмас. — Һәм, миңа борылып: — Казан татарларыннандыр ул! — диде. (Сүз алар әле генә булып чыккан Департамент башлыгы турында иде.)
— Кая барма — безнекеләр! — дип җөпләп куйды теманы Рәшит.
Инде Казанга кайткач, мин Кәнәфия әфәнде кыстырып җибәргән күчтәнәчләрне — «Дуслык» журналын укып чыктым, Киев «сандугачлары» Әлфия Шевченко, Рәисә Хөснетдинова, «Асылъяр», «Шатлык» төркемнәре яздырган магнитофон тасмаларын тыңладым. Һәм уйлап куйдым. Менә бит ул — безне берләштерә торган нәрсә — татар җыры, һәр татар кешесенең йөрәген ача торган ачкыч — халкыбыз моңы. Шул бер генә нәрсә яшәсә дә, без яшәрбез. Кайда булуыбызга карамастан...

*Казан—Мәскәү—Донецк—Киев—Казан*
*март, 2004*

## СССРга сәяхәт

Поезд Беларусь җиреннән, чакрымнарны саный-саный, Минскига таба җилдертә. Вагон тәрәзәсеннән күренеп киткән күлләр, йортлар, урманнар сугыш фильмнарыннан яшьли хәтергә сеңеп калган манзараларны искә төшерә. Партизаннар, Хатынь, сазлыклар, Беловеж чытырманнары...
Җәй күпләрнең ял чоры булса да, вагоннар тулы түгел. Ресторанда туклanучылар да берән-сәрән генә. Проводнигыбыз, Казаннан Беларуська сабан туена баруыбыз турында ишеткәч, бераз гаҗәпләнеп калды. Янәсе, сез татарлар сабантуй дигәндә... Үзе чын белорус хатыны — тулы гәүдәле, почык борынлы, зәңгәр күзле, итагатьлегә йөзенә чыккан. Аның белән аралашасы гына килеп тора.
— Ничек яшисез анда?
— Шөкер, хезмәт хакыбыз зур түгел, ләкин вакытында түләп баралар, — дип җавап бирә елмаеп вагон башлыгы. — Берәр нәрсә теләмисезме?
Кечкенә купеның бер почмагында тезелеп киткән шоколадлар, «Спрайт»лар, сыралар мине кызыксындырмый.
— Юк, рәхмәт, безнең үзебез белән һәммәсе дә бар...
Кондуктор көрсенеп, тирән сулап куя.
— Шулай шул... Хәзер халык ресторанны үзенең биштәренә төяп йөри... Ә безгә сатарга план бирәләр...
Поезд алга — СССРга таба чаба. Беларусьта Советлар берлеге исән-имин сакланып калган дигән фаразларны еш ишетергә туры килә. Хуш, күрербез, иншалла. Урта һәм олы яшьтәге кешеләр СССРның түләүсез медицинасын, пенсия акчасына Кара диңгезгә йөргән чакларын, ярлыкарсыз-байларсыз, таможнясыз, чикләрсез Калининградтан Владивостокка, Кушкадан Салехардка кадәр сәяхәт иткән чорларны сагыналар, әлбәттә. Вакыт узган саен, талоннар, аракыга чиратлар, чит илләрне телевизор аша гына күргән заманалар онытыла бара...
Менә, ниһаять, Минск. Перронда безне, колачларын җәеп, Татарстанның Беларусьтагы вәкиле, якташыбыз Ирек Гафиятуллин һәм «Чишмә» оешмасының җаваплы сәркәтибе ыспай гәүдәле, чибәр Гөлсинә ханым каршы алалар. Без бер купеда тәүлектән артык бишәү килгәннәр, ниһаять, урамдагы һаваны туялмыйча, күкрәк тутырып сулыйбыз. Рәхәт! Бишәү дигәнем ул: җырчы Равил Харисов, мәдәният хезмәткәре Эльвира Хисамиева, Яр Чаллы педагогия институтында татар теле укытучы Флүрә Галимова, аның ике яшь ярымлык улы Булат һәм мин. Булат бер яктан сәяхәтебезне мәшәкатьләндерсә дә, тыныч һәм күңелле бала булып чыкты. Төннәрен еламады, көндезләрен, безнең алда әнисен оялта-оялта, ярты сәгать саен: «Әни, ими!» — дип даулап барды. Ә мин, үземнең ике баламны һәм оныкларымны искә төшереп, ана кешенең гаиләдәге мәшәкатьле вә алыштыргысыз роле турында уйланып утырдым. Бала үстерү һәм тәрбияләү — энә белән кое казу бит ул. Ә бит мәрхүмә әнием, эти белән сугыштан соң авыл шартларында сигез бала тудырып, тугызны (һәлак булган энекәшнең ятим калган улын) аякка бастырдылар. Сугыш чорында тәртәгә җигелеп йөк сөйрәгән, ачлы-туклы, яланаяк көзге-язгы урманнарда агач кисеп бүрәнә тарттырган меңләгән, йөз меңләгән хатын-кызлар бу дөньядан бер рәхәт күрмичә, хөкүмәттән бер рәхмәт ишетмичә китеп бардылар. Кем башлаган соң ул сугышларны, нәрсә өчен? Җир бүлешә алмый, дөньяны төрле системаларга аерып, миллионнарны маңгайга маңгай бәрелештергән фашистлар, коммунистлар, тагын әллә кемнәр... Рәхәт яшәр өчен туган Ходай бәндәләренең моңа нинди катнашы бар?
Күптән түгел телевидениедән немец концлагерьларында исән калып, сугыштан соң совет төрмәләрендә утырганнар турында тетрәндергеч фильм күрсәттеләр. Контузия алып аңын җуйган хәлдә немецлар кулына төшкән бер совет гаскәрие, елый-елый, бездәге концлагерьлар тегендәгеләргә караганда күпкә катырак режимлы иде, дип сөйләде. Хәрби әсирләрне: «Сез ник үлмәдегез?» — дип, көн дә җәзалый торган булганнар. Ә бит миллионлаган хәрбиләр сугышның беренче айларында ук, совет хөкүмәте җитәкчеләре,

генералларның гаебе аркасында чолганышта калып, немец концлагерьларына эләгәләр. Сугыштан соң Германия хөкүмәте әсирлектә булган совет гражданнары алдында гафу үтенеп, аларга шактый акчалар бирде. Безнең совет лагерьларында интеккән гаепсезләрне 1992 елда гына ярлыкау иттеләр. Нигездә, инде алар үлеп беткәч... Ничек шулай үз халкыңны яратмаска кирәк!

Поездда барганда вакыт күп, тәгәрмәчләр тавышы мине янә уйландыра.

Менә шулхәтле корбаннар биреп, халык көче белән төзелгән ил, система җимерелеп, яңа революцион борылыш-реформалар башланды. 10—15 ел эчендә берәүләр миллионер-миллиардерлар, олигархлар булып, ә миллионнар ач-ялангач калдылар. Ничек монда түләүсез медицина, уку, торак белән тәэмин иткән СССРны сагынмаска?! Бәлкем, бу яктан караганда яңа системага теше-тырнагы белән каршы торган Беларусь президенты Александр Лукашенко (аны халык «батька» дип йөртә) үз халкын дөрес юлдан алып барадыр?..

Минскидагы урамнар, йортлар төзеклеген, шәһәр эчендәге елга-күлләрнең чисталыгын, архитектура төрлелеген, пөхтәлеген күреп, мин сөендем дә... гарьләндем дә. Соңгысы Казаныбызны искә төшерүгә бәйле иде. Тар урамнар, сикәлтәле юллар, әйтерсең лә бомбага тоткан шәһәр кварталлары. Минск, нигездә, сугыштан соң торгызылган шәһәр. Бәлкем, шуңа да совет архитекторлары киләчәккә йөз тотып, кеше мәнфәгатьләрен искә алып эш йөрткәннәрдер. Ник соң безнең Казанда дөнья акчасы сарыф итеп реставрацияләгәннән соң шул ук тар урамнар, уч төбе хәтле мәйданнар торып кала? Тукай мәйданын киңәйтеп, транспорт агымын көйли торган эстакадалар ясар урынына кибетләр, рестораннар төзиләр. Акчасын кая куярга белмәгән пенсия фонды да шул ук мәйданга килеп тыгылган. Без бит башкалабызда бүген тончыгабыз! Ә иртәгә, машиналар саны бермә-бер арткач, нишләрбез?! Нигә соң ул башка илләрдә кешеләргә кагылган мәсьәләләр буенча шәһәр халкы белән даими киңәшеп, референдумнар уздырып торалар, ә бездә моны бары тик тар даирәләрдә генә хәл итәләр? Ә аннары болай да кысан «Детский мир» каршында уен автоматлары барлыкка килә, йә Кремль диварлары астында кемнеңдер кесәсен баетыр өчен сырахана пәйда була. Әгәр дә җәмәгатьчелек белән киңәшеп эшләнгән гамәл булса, халык мондый объектларга каршы акцияләр уздырмас иде. (Шөкер, бу эчпошыргыч биналар, ниһаять, казанлыларның күз алдыннан югалдылар.) Инде аңларга вакыт: безнең шәһәрдәге үзгәрешләр беренче чиратта шәхси мәнфәгатьләрне түгел, ә гади
халык фикерен истә тотып башкарылырга тиеш.

Беларусьның башкаласына безнең шәһәр һәм транспорт министрлыгы түрәләрен алып килеп махсус экскурсияләр оештырырга кирәк. Биредәге киң урамнарда бездәгедәй транспорт мәхшәре күренми. Беренчедән, автобуслар, троллейбуслар даими йөреп тора. Икенчедән, монда акчадан күзләре тонган маршрут таксистлары йөрми. Алар Казанның болай да тар урамнарын бөтенләй басып алдылар. Кагыйдәсез-нисез йөргән таксистлар күпме һәлакәт ясыйлар, бәла китерәләр. Мондый капитализмны илгә кертүеңнән кертмәвең яхшырак түгелме? Монда мин Лукашенко ягында.

Әлбәттә, без Беларуська сәяси вә икътисади мәсьәләләрне өйрәнергә бармадык. Шуңа да бу хакта белгечләр белән аралашмадык. Ләкин 10 меңгә якын милләттәшебез яшәгән төбәктә экономиканы да, милли проблемаларны да, сәясәтне дә яхшы белүчеләрне очратырга туры килде. Беларусьта яшәгән татарларның бер өлешенең ата-бабалары бирегә 600 ел элек Литва кенәзлегенә яугирләр рәвешендә килгәннәр. Алар шушы җирне чит ил басып алучыларыннан саклап яу чапканнар, кайберләре башларын салганнар. Бөек кенәз Витаутас һәм аның варислары татарларга рәхмәт йөзеннән иң яхшы җирләрне, төрле дәрәҗәле исемнәрне биргәннәр. «Зикр аль-китаб» җәмгыяте рәисе Абу Бәкер Шабанович, Беларусь татарлары тарихын өйрәнеп берничә китап язган галим
Ибраһим Конопацкий һәм башка зыялы милләттәшләребез әнә шул затлы нәселләрдән. Алар телләрен югалтсалар да, ислам диненә, борынгы йолаларыбызга тугрылыклы булып калганнар. Яңа эмиграция — бирегә 20—30 ел элек килгән Идел буе, Урал төбәге татарлары. Алар, әлбәттә, туган телебезне яхшы беләләр. Татарстан вәкиллегендә Ватаныбызны сагынган милләттәшләребез атнага бер тапкыр татар кичәләре оештыралар. Алар Бөтендөнья татар конгрессы белән даими элемтәдә торалар, мәдәни яңалыклар хакында хәбәрдарлар. Яңа китаплар, кассеталар, Интернет сагыну хисен, ностальгияне күпмедер йомшарталар, билгеле. Җәйләр җиткәч, туган якларны урап кайтучылар да шактый. Бу ике төркем милләттәшләребез арасында шактый еллар фикер төрлелеге, хәтта бәхәсләр, үпкәләүләр дә яшәп килгән. Ләкин соңгы елларда, әйтергә кирәк, Казан йогынтысы көчәя барган саен, ике як өчен дә уртак тел табу җиңеләйгән. Татар конгрессының этник туризм һәм башка чаралар кысаларында Беларусь татарларын Казанга чакырып тарихи Ватаныбыз белән якыннанрак таныштыру да үз ролен, әлбәттә, башкарган.

Татарча сөйләшмәүче татарлар Идел-Урал төбәгеннән килгәннәрне үз итә башлаганнар. Һәм моның чагылышын биредә узган сабантуйларда күрергә була.

Милли чараларны, бәйрәмнәрне «Чишмә» җәмгыяте рәисе Иран Исхакович Богдановтан башка күз алдына китерүе кыен. Сабантуйларына кешеләрне китерер өчен автобуслар табудан башлап Иран әфәнде колгага менүләрне, көрәшләрне, Русия илчелеге, Президент аппаратыннан вәкилләр чакыруны да үзе оештырган. Әлбәттә, вәкиллек тә, татар җәмгыятьләре дә бу эшләрнең үзәгендә кайнаганнар.

Быелгы сабантуй алдыннан Иран әфәнденең кәефе шәптән түгел иде. Иртәннән һава салкын һәм яңгыр сибәләп торганга, ул: «Кешеләр аз булыр... Кызганыч, бик ныклап әзерләнгән идек», — диде. Шулай да сабантуй узачак атлы спорт базасында автобус динамикларыннан таныш моңнар яңгырап тора, мәйдан тирәсендә әкрен генә зонтиклы кешеләр күренгәли иде. Ә инде рәсми котлаулардан соң Татарстанның халык артисты, һәрнәрсәне үзе энәсеннән җебенә хәтле тикшермичә сәхнәгә чыкмаучы, пөхтә вә ыспай җырчы Равил Харисов дәртле җырларын яңгырата башлагач, яңгыр туктап калгандай булды. Икенче җырчыбыз Эльвира Хисамиева да чибәрлеге, матур тавышы һәм белорус җырларын башкаруы белән тамашачыларның күңелләрен күтәреп, кайберләрен биетә дә башлады. Флүрә дә, бер мәлгә Булатын апасына тапшырып, мәйданга төшеп, татарча матур итеп эстрада җырларын башкарды. Ул арада болытлар таралып, кояш та күренде. Сабантуй мәйданында 200 ләп тамашачы җыелып өлгерде. Әйтергә кирәк, биредә борынгы бәйрәмебезне бөтен атрибутлары белән оештырганнар иде. Ат чабышы, көрәш, капчык белән сугышу, колгага менү һ.б.

Җирле татарлар да, казанлылар белән ярыша-ярыша, милли көйләрне бик оста башкардылар. Гроднодан килгән биюче кызларның чыгышы, мәсәлән, профессиональ артистларныкыннан бер дә ким булмады.

Казаннан еракта узган сабантуйлары төрле җирдә төрлечә оештырыла. Хәзер инде алар Русиянең 50 дән артык төбәгендә, 20 ләп чит илдә даими рәвештә уздырыла башладылар. Иң соңыннан бәйрәмне Федераль сабантуй тәмамлый. Монысы да чагыштырмача яңа күренеш. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы соңгы елларда халкыбызның борынгы бәйрәмен төбәкләрдә йоласына, рәвешенә туры китереп уздыру максатыннан аны оештыручыларны, Казанга чакырып, махсус курсларда укыталар. Русия төбәкләренә Татарстан районнары беркетелеп, анда зур иҗат төркемнәрен, көрәшчеләрне алып бару да соңгы елларда гадәткә кереп киткән күркәм гамәл. Һәм боларын инде Президент аппараты, хөкүмәт даирәләренең ярдәменнән башка оештыруны күзаллавы да мөмкин түгел.

...Менә санаулы көннәр узып та китте. Белоруслар 12 июньдә, шактый зурдан кубып, Россия көнен билгеләп үттеләр. Мәскәү акчаны җәлләп тормаган: Русиянең дистәләгән төбәкләреннән килгән артистлар, иҗат төркемнәре Минск мәйданнарын шаулаттылар. Ләкин Россия—Беларусь арасы визасыз булса да, мөнәсәбәтләр әле көйләнеп бетмәгән кебек. Монысы «батька»ның Русия демократлары уздырган реформаларны өнәп бетермәве белән дә бәйле дип фаразлыйлар сәясәтчеләр.

Халык акчасын урлап, вазифаларын тиешенчә үтәмәгән җитәкчеләрнең Беларусьта язмышы бер генә төрле: төрмә. Инде дистәләгән министрлар һәм башка рангтагы түрәләр зәңгәр күкне тимер рәшәткә аша гына күрергә мәҗбүрләр. Дөрес юлмы бу? Җавабын озак эзләп торырга кирәк түгелдер дип уйлыйм. Биредә колхозлар элеккегечә эшләп килә, дәүләт икътисадны каты контроль астында тота. Болары дөрестерме-юктырмы, төгәл җавап бирүе кыен. Ләкин җирле халык моңа чәпчеми. Киресенчә, күптән түгел узган референдумда алар Александр Лукашенконың сәясәтен дәррәү хуплап чыккан. Гәрчә Европа шурасы, Америка «Беларусьта демократия юк, кеше хокуклары кысыла» дип һәрдаим чаң сугып торсалар да.

...Менә тагын поезд алга чаба. Без СССРның соңгы утравыннан капитализм төзеп маташкан Россиягә таба юл тотабыз. Юл буенча тезелеп киткән дачалар, ике этажлы гади коттеджлар, Беларусьтагы сәясәтнең кай тарафка хәрәкәт иткәнен искә төшергәндәй, артта калалар.

Алда Русия. Һәм безне анда ниләр көткәнен яхшы беләбез. Монысы бәләкәй Булатка гына мәгълүм түгел. Ул, тигез тешләрен күрсәтеп, юлда очраган поездларга, кешеләргә вагон тәрәзәсе аша елмаеп: «Хушыгыз, пока!» — дип, нәни кулларын болгый. Аннары, әнисенә борылып, әкрен генә: «Әни, мәми», — дип пышылдый.

*Казан—Мәскәү—Минск—Казан*
*июнь, 2005*

## Эссе күл хатирәләре

Кыргызстан... Кемнеңдер ул ватаны, кемнеңдер торган җире. Биредә яшәгән татарларның кайберләре бүгеннән үк бу таулы, ташлы, эсселе, сусыз төбәктән ата-бабалары туган якка — Татарстанга, Рәсәйгә кайтып китәрләр иде.

«Эшсезлек биредә...» «Акчаны да бик чамалы гына түлиләр...» «Яхшы эшкә безнекеләрне алмыйлар...»

«Илкәем» дигән татар җәмгыятенең рәисе Равилә Әхмәрованың әнисе Әлмәттә яши, уллары да бәхетләрен Кыргызстаннан читтә тапканнар.

— Туган як тарта, — ди Равилә ханым, сөйләгәндә көчкә күз яшьләрен тыеп, — Ходай кушса, бер кайтырбыз әле әйләнеп...

Ош шәһәренең мәдәният идарәсе рәисе урынбасары булып эшләгән Әхмәрова дүрт көн буена Татарстаннан килгән безнең делегациядән һич кенә дә аерыла алмады.

Хәер, кыргыз далаларын, тауларын, карлы суларын, кунакчыл кешеләрен яратып, биредә төпләнеп калучылар да шактый әле. Рәсми саннарга караганда, Кыргызстанның җиде өлкәсендә 47 мең татар һәм 3 мең башкорт яши. Һәм алар, бер җепкә тагылган дисбе төймәләре сыман, «Туган тел» исемле татар-башкорт мәдәни мәркәзе тирәсендә тупланганнар.

Ошбу җәмгыятьнең президенты Гөлсинә Ульмаскулова — Кыргызстанда яшәгән милләттәшләребезгә генә түгел, андагы хакимияттәгеләргә дә, Татарстан вә Башкортстандагы милли оешмаларга да бик яхшы таныш шәхес, Бишкәктәге Русия илчелеге белән дә килешеп эшли. Биредә татарлар төрле оешмаларга бүленми генә уртак тел табып, матур гына яшәп яталар.

Монысы инде беренче чиратта Гөлсинә ханымның күркәм сыйфатлары, тырышлыгы, үҗәтлеге, таләпчәнлеге аркасында.

— Бездә дә булды ул бүлгәләнергә, тарткалашырга теләүчеләр. Ләкин милләт эше шулхәтле күп — тырышып эшләсәң, һәркемгә дә җитә...

Ерак араны якын итеп Кыргызстанга килүебезнең сәбәбе «Туган тел» оешмасының 15 еллык юбилеенда катнашу булганга, без шимбә көнне Республика драма театрында узачак чараны түземсезлек белән көттек. Җырчыларыбыз Рөстәм Закиров, Алсу Әбелханова, композитор Вәис Бәйрәмов Татар конгрессы байрагы астында төрле төбәкләрдә концертларны байтак куеп йөргән булсалар да, әллә биредәге сый-хөрмәттән үтә канәгать булып, әллә сәхнәгә чыгар алдыннан бераз репетиция ясарга теләп, артистлар өчен бирелгән бүлмәләргә таралыштылар.

Ул арада фуршет оештырылган залга бер-бер артлы дәрәҗәле кунаклар килә торды. Кыргызстанда һәр милләткә хөрмәт белән карау дәүләт җитәкчелегенең үзеннән килә дигән фикер туды.

Дүшәмбегә Гөлсинә ханым «Туган тел»нең юбилее уңаеннан президентның үзенә чакырылган иде. Соңрак Казанга кайткач, мин Кыргызстан халыклары ассамблеясы тарафыннан нәшер ителгән беренче карашка үтә рәсми «Берлектә һәм килешеп» дигән җыентыкны укып чыктым. Ассамблея 31 милли оешманы берләштереп, аларга махсус бина биргән. Кыргызстан хөкүмәте бер яктан милли оешмаларга өлешчә үзенең вәкаләтләрен бирә, ә төрле халыклар җәмгыятьләре этник үсешне, милләтара дуслыкны саклап калуны гарантиялиләр. Әлбәттә, биредә совет мирасы да көчле тәэсирен саклап килә. Урамнарда, кибетләрдә, рәсми оешмаларда урыс теле еш яңгырый. Рубльнең дә абруе җитәрлек. Бишкәктә Славян университеты эшләп килә. Һәм Русия илчелегенең биредәге тормышка йогынтысы ифрат дәрәҗәдә көчле.

Юбилей кичәсенә Кыргызстан халыклары ассамблеясы рәисе, парламент депутаты Исә Токаев беренчеләрдән булып килде. Дәрәҗәле кунаклар арасында Президент аппаратының бүлек мөдире Тынынбек Орманбәков, Республиканың сәүдә министрының урынбасары Болот Җумәбәков, Русия илчелегеннән беренче сәркәтиб, «Туган тел»гә гел ярдәм итеп килгән Надежда Калинина һәм башкалар бар иде.

Чыгышлар бик җылы, бүләкләр затлы булды.

Залга җыелган мең ярым тамашачы чараның рәсми өлешен дә, концертын да дәррәү алкышларга күмде. Рөстәм Закировның халык җырлары, Вәис Бәйрәмовның тальянкадан башлап курай, кубыз белән башкарган көйләре, Алсу Әбелханованың тамашачылар арасына төшеп җырлап-биеп алулары милләттәшләребезнең күңел кылларын тибрәтте. Кайберләренең күзләрендә яшьләр дә күренде. Хәер, җирле татар үзешчәннәре дә бик күркәм, профессиональ дәрәҗәдә чыгышлар ясадылар. Берничә лирик һәм юмористик шигырь укыган мин фәкыйрегезгә дә бер-ике букет һәм кайнар алкышлар насыйп булды. Бер ханым, концерттан соң урамга чыккач, хәтта гади дәфтәргә автографымны куюны зинһарлап сорады. Кесәмдә калган бер кассетамны бүләк иткәч, ул, кош тоткандай хисләнеп: «Менә миңа нәрсә бүләк иттеләр!» — дип, танышлары янына йөгерде.

Дөресен әйтим, мондый җылы очрашулар, ихлас күңелдән аралашулар кыргыз җирендә һәр адымда булды.

Ә инде программабызның иң гүзәл өлеше — кульминациясе — Эссе күлгә (Иссык-куль) ясалган бер көнлек сәяхәт иде. Алатау, Тянь-Шань чылбырлары белән уратып алган бу гаҗәеп җәннәт күлдә хәтта мокыт кешенең күңелендә шигъри юллар туар иде. Безне озатып йөргән, телевидениедә татарча тапшырулар оештыручы Гөлгенә Шонкорова: «Эссе күлдә нинди хисләр туды?» — дип сорагач, мин болай дип җавап бирдем: «Кыргызстанда Эссе күлдән гайре башка бернәрсә булмаса да, ул, һичшиксез, дәүләт булып калыр иде».

Һәм шунысы сөендерә: милләттәшләребезнең кайберләре инде күптән бу оҗмахта урын алганнар. «Туган тел»нең Чулпан-атадагы бүлекчәсен җитәкләгән Арслан Йосыповның кунакчыл йорты, безнең өчен махсус чалынган куй шашлыгы, биредә 24 ел буе «Самал» профилакториясе директоры булып эшләгән Шәүкәт ага Хәйруллин ярдәмендә оештырылган гайре рәсми җыр-бию кичәсе — болар барысы да Кыргызстаннан алып кайткан якты хатирәләр.

Хәер, инде әйткәнебезчә, биредәге тормышның михнәтләре дә җитәрлек. Кыргызстанда хәерчелеккә каршы программалар хакында хәтта рәсми басмаларда да язалар. Халыкның 52 проценты фәкыйрьлектә гомер кичерә. Бигрәк тә олы яшьтәге авыл кешеләре авыр хәлдә. Безгә бик аңлашылып бетмәгән су проблемасы интектерә. Гаиләләрнең 65 проценты һәр кеше башына 5 квадрат метр торак мәйданы белән генә тәэмин ителгән. Җинаятьчелек, наркомания — Кыргызстанда да хакимиятнең башын авырттырган проблемалар.

Гөлсинә ханым Ульмаскулова үзенең төп вазифасын ярдәмгә мохтаҗ татарларга булышуда күрә. Олы яшьтәгеләргә медицина, дарулар белән ярдәм кыла. Эшкуарларга мөрәҗәгать итү, «Туган тел»нең бизнес белән шөгыльләнүче структураларын булдыру нәкъ шул җәһәттән башкарыла да инде. «Татарстан» сәүдә йорты директоры Гөлсинә ханымның уң кулы Равил Бухаров Тянь-Шаньда җыйган үләннәрдән Казандагы «Татхимфармпрепараты» ширкәте белән берлектә шифалы дарулар ясап халыкка арзан бәядән тарату нияте белән янып йөри. Кызганыч, әмма безнең кәсәбәчеләр белән Бишкәктәге милләттәшләребезнең боткасы әлегә пешми. Һаман да шул бюрократик киртәләр комачаулый. Югыйсә мондый хезмәттәшлек базар офыкларын бермә-бер киңәйтер иде. Ульмаскулованың командасында тагын бер гүзәл ханым — «Аникай Эйр» авиакомпаниясе рәисе Әлфия Галиәскәрова да матур хыяллар белән яши. Хәер, Бишкәк — Казан — Бишкәк авиарейсын оештыру хыял гына түгел, чынбарлык инде. Якын арада, Әлфия ханым сүзләренә караганда, бу проект гамәлгә ашачак. Менә шундый тарафдарлары белән тынгысыз Гөлсинә ханым милләттәшләребезнең мәшәкатьле тормышын әзрәк булса да җиңеләйтергә тырыша.

15 ел эчендә милләт өчен башкарылган игелекле гамәлләре белән дә, туплаган бай тәҗрибәсе белән дә «Туган тел» оешмасы һәм аның җитәкчесе Гөлсинә Ульмаскулова, әлбәттә, мактауга лаек. Әмма аның иң кыйммәтлесе — башка татар җәмгыятьләренә өлге булып торуында.

Биредә тарихи Ватанның хәрәкәтчәнлеге турында да әйтеп үтәргә кирәктер. Һәм Бөтендөнья татар конгрессында моны яхшы аңлыйлар. Мондый сәфәрләрдә бөтен эш бәлеш һәм шашлык ашау белән генә чикләнми. Мәсәлән, шул ук Бишкәктә бәйрәмнең икенче көнендә татар кәсәбәчеләренең эшлекле җыены узды. Татарстанның рәсми структуралары да чит илләрдәге милләттәшләребез белән хезмәттәшлеккә игътибарын арттырсын иде. Бигрәк тә милләттәшләребез ике якка да файдалы гамәлләр тәкъдим итеп торганда. Алар бит кул сузып акча сорамыйлар, ә барыбызга да файда китерә торган кәсеп корырга чакыралар. Юкка гына Кыргызстанда чит ил капиталы урнашып, төпләнеп калырга омтылмыйдыр.

Әйе, Кыргызстан — мөстәкыйль дәүләт. Аның бөтен атрибутикасы, чит илләр белән тигез мөнәсәбәтләре бар. Безне бу җөмһүрияткә төрле илләрдән кергән инвестицияләр турында мәгълүмат гаҗәпләндерә. Азия банкы — 422 миллион доллар, Бөтендөнья банкы — 606 миллион, Халыкара валюта фонды — 289 миллион һ.б. саллы финанс оешмалары Кыргызстанга яшел акча яңгыры яудыра.

Урта Азия җөмһүриятләренең киләчәге нинди цивилизацияләргә бәйләнер, нинди юнәлешләр алыр, нинди нәтиҗәләргә китерер? Монысы инде бу илләрнең генә кайгысы түгел.

Манас аэропортында Мәскәү очкычын көтеп торган арада һава аланына берәм-берәм канатларына Америка йолдызлары сугылган күксел төстәге дәү очкычлар төшеп утырдылар. Димәк, дөньяның зур көчләре бирегә вакытлыча гына килмәгәннәр...

*Казан — Бишкәк — Казан*
*июнь, 2004*

# Күркәм шәхесләр,
# изге җаннар...

## Гомер җыры

Гомер уза аккан сулар кебек,
Йөрәкләрдә кала үкенеч.
Әҗәлләрдән дару булмас инде,
Ходай яшәр өчен бирсен көч...

Татар халкының яраткан җырына әверелгән «Гомер уза» көен язган композитор Илгиз Мәҗитов дөнья куйды.

...Илгиз әфәнденең гөрләп торган Татар дәүләт филармониясен баш режиссер буларак җитәкләгән чагы. Кабинеты тулы иҗат кешеләре — җырчылар, шагыйрьләр, музыкантлар. Әледән-әле бүлмәдәге пианино артына утырып, Мәҗитов ниндидер көйләрне, музыкаль фрагментларны уйнап күрсәтә. Тәмәке төпчекләреннән калкулык өелә. Боз сараенда узачак зур концерт программасын әзерләп, иҗат төркеме мәш килә. Миңа, ул чакта яшь юмористка, Илгиз концертны алып баручылар өчен текстлар язарга кушты. Хәзер инде вак-төякләр онытылган. Тик концертның уңышлы килеп чыгуын яхшы хәтерлим.

Шушыннан соң без Илгиз Мәҗитов белән дуслашып киттек. Дистәләгән җырларны бергә иҗат иттек. «Очып кайтам», «Нәүрүз чибәре», «Тагын кайттым» һәм башка популяр җырлар — безнең кайнар бәхәсләрдән соң, хәтта үпкәләшеп-дуслашып беткәннән соң туган әсәрләр.

Илгиз, үзенә ошаган җыр текстын кулга төшерүгә, дәртләнеп, ашыга-ашыга көй язарга керешә иде. Аннары миңа телефоннан:

— Слушай, старик, я на твои слова написал гениальную песню, — дип, музыкасын уйнап күрсәтә иде. (Казанда туып үскәнгә Илгиз татарча яхшы аңласа да, нишләптер күбрәк урысча сөйләшә иде.)

Мин тыңлап торам да:

— Старик, халтуришь, торопишься. Тагын бераз утыр әле... — дип җавап бирәм.

«Гомер уза» җырының да беренче вариантларын тәнкыйтьләргә туры килде. Ләкин, кат-кат эшләгәч, менә дигән җыр килеп чыкты. Шулай да радиога тәкъдим иткәч, сәнгать советында кемнәрдер, көйне тыңлап: «Илгиз үз-үзен кабатлый», — дип, «Гомер уза»ны эфирга тәкъдим итмәгәннәр. Моңа композитор бик гарьләнгән иде. Җырның язмышы ничек булыр иде әле, әгәр дә бер зур концертта ул олы түрәгә ошамаган булса... Тиз арада архивка киткән җырны яздырып эфирга чыгаралар. Зөлфия Шакирова беренче булып аны кассетага яздыра, соңрак Зилә Сөнгатуллина, ә аннан соң беркемгә таныш түгел Бәширә Насыйрова башкара башлый. 2000 елдагы «Татар җыры» конкурсында «Алтын барс» премиясен алган кичәдән соң мин, Илгизнең өенә барып, аңа премияне һәм дипломны тапшырдым. Ул, аяклары каты авыртканга күрә, фатирыннан чыгалмаслык хәлдә калды. Композиторның күзләрендә яшьләр күренде.

— Старик, давай напишем еще одну гениальную песню!..

Мин аның кулларын кыстым. Үзем белән бер драматик эчтәлекле «Соңгы ядкарь» дигән шигырем бар иде. Шуны калдырдым. Белмим, ул аны кабул иткәнме-юкмы. Берничә кат телефоннан сөйләшеп, күрешергә вәгъдә итеп тә мин Илгиз янына барып чыга алмадым. Исән чакта дөнья куабыз. Ул, шылтыраткан саен, «все нормально!» дип җавап бирә, язмышка чәпчеми иде. Гомумән, ихтыяр көче зур иде аның.

Филармония залында матәм чыгышында Илгизнең эшләгән эшләре, мактаулы исемнәре, Хезмәт ордены белән бүләкләнүен искә алдылар. Хәтта аның язган җырларын атап үтүчеләр дә булды. Тик менә «Гомер уза» җырын матәм текстларын язучылар да, нотык тотучылар да нигәдер искә алмадылар.

Шәһәр мохитендә үсеп тәрбияләнсә дә, татар телен камил белмәсә дә, Илгиз милли җанлы иде, халкыбызның аһәңен, моңын тоеп яшәде. Моны аның чын халык моңы белән сугарылган дистәләгән әсәрләре дәлилләп тора. «Гомер уза» да нәкъ шулар арасында.

## Җитмеш яшьлек егет

Берничә ел элек миңа Самара якларында булырга туры килде. Андагы очрашулар, кичәләр, гаҗәеп гүзәл кешеләр турында аерым утырып, мең дә бер кич буе сөйләргә мөмкин булыр иде. Ләкин иң истә калганы Самараның «Татар ашлары» ресторанында узган кичә иде. Казаннан килгән ике мөхтәрәм иҗат «генералы» белән миңа да шул мәҗлестә утырырга насыйп булды.

Татар мохите белән бераз таныш кеше беләдер инде, Самара өлкәсендә 100 меңнән артык кан кардәшләребез яши. Анда, күп төбәкләрдән аермалы буларак, бердәнбер булса да татар мәктәбе эшләп килә. Бер дистә елга якын татар радиосы сөйли, һәм биш ел «Бердәмлек» дигән газета нәшер ителә.

Соңгы кичәдә бокаллар әзрәк, ә акыллы, җор, үлчәп әйтелгән сүзләр күбрәк яңгырады. Истә калганы һәм кулыма каләм алырга этәргәне Равил ага Яһүдиннең мәгънәле нотыгы булды.

Җитмешнең өстенә баскан, озын гәүдәле, чал чәчле, һәрвакыт сүзен үлчәп, кистереп әйтә белүче, башына, әйтерсең лә җисеменә туры китереп тегелгән чигүле кара түбәтәй кигән кешене күрсәгез, ул Равил ага Яһүдин булыр. Хәер, сез аны Самарада гына түгел, Казанда да күргәнегез бардыр, чөнки ул Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты әгъзасы һәм кәсәбәче буларак та безнең якларга еш килгәләп йөрде.

Моннан берничә ел элек Самара дәүләт университетының милли факультетына утызлап татар егете һәм кызы укырга керергә гариза бирә. Ләкин керү имтиханнарында аларның барысы да, икеле алып, исемлектән төшеп калалар. Гәрчә араларында тирән белемле, урта мәктәпне медаль белән тәмамлаганнары булса да.

Моның хикмәте бик тиз ачыла. Шул факультетта эшләгән бер татар хатыны Әбдәсә ханым, Равил агага килеп, елый-елый менә нәрсәләр сөйләп бирә. Факультет деканы татарларны күралмый торган карагруһчы икән. Менә шул адәм укытучыларны алдан кисәтеп куйган: факультетка бер генә татар баласын да алмаска! Шуңа күрә татар яшьләренә катлаулы сораулар, өстәмә таләпләр куеп, имтиханнарда «батырганнар». Кем әйтмешли, бәйләнергә теләсәң, баганага да бәйләнеп, йомыркадан да җөй табып була бит ул!

Бу хәбәрне ишеткәч, Равил ага тиз генә матур түбәтәе белән киңәшләшеп ала да, бер төркем журналистлар ияртеп, әлеге факультет башлыгына килә. «Ни өчен сез татар балаларына каршы күрсәтмә бирдегез? Мин иртәгә үк Татар конгрессына барам һәм бу хәлне бөтен дөньяга таратам», —ди ул. Журналистлар алдында үз гаебен тану эштән колак кагу белән бер икәнен аңлаган декан: «Монда бернинди дә сәяси, милли проблема юк, бу нибары очраклы хәл генә!» — дип акланырга тырыша. Ләкин Равил ага мәсьәләне бик җитди куя. Имтихан тоталмаган яшьләрне, аларның ата-аналарын шаһит итеп чакырта. Эшнең зурга

китүен чамалап, декан кулларын күтәрә. Бу юлы татар абитуриентлары, имтихан да биреп тормыйча, сөйләшү, тест юлы белән университетка кабул ителәләр.

Шуннан соң алты елга якын вакыт узып китә. Равил ага тырышлыгы белән университетка кергән 33 студент, чыгарылыш имтиханнарын яхшы билгеләргә тапшырып, диплом алып, өлкәнең төрле мәктәпләренә, оешмаларына таралышалар.

Мәҗлестә утырган профессор Шамил Мәхмүдов бу хакта болай диде:

— Мин хәзер нәкъ шул факультетта эшлим. Декан кайчагында сезне искә төшерә дә: «Татар мафиясе» башлыгына миннән сәлам әйтегез!» — дип әйтеп куя. Хөрмәтле Равил абый, шул сәламне сезгә җиткерергә рөхсәт итегез!..

Мәҗлестәгеләр елмаешып дәррәү кул чаптылар. Ә мин менә нәрсә турында уйландым. Безнең халык еш кына мескенләнергә ярата. Нәчәлствоны күреп, бөтенләй коелып төшүчеләр дә байтак. Үзебезнең хокукларыбызны аяк терәп дауларга кирәклеген онытабыз, куркабыз йә теләмибез. Бигрәк тә сүз милләт мәнфәгатьләре турында барганда. Әгәр дә шушы утыз өч студентның хокукларын Равил ага кебек чая кеше якламаса, бүген аларның язмышы бөтенләй башкача булыр иде. Милләтебезгә менә нинди көрәшчеләр кирәк!

Соңрак Равил ага, безнең бәләкәй делегациябезгә хөрмәт күрсәтеп, үзенең Самарадан 45 чакрымда урнашкан Кызыл Яр бистәсендәге оҗмах почмагына чакырды. Киң елга буенда утырган зур йортның гүзәллеге тышында түгел, эчендә иде. Равил әфәнде, үтә кунакчыл хәләл җефете Рауза ханым Казан кунакларын шулхәтле эчкерсез кабул иттеләр ки, саубуллашканда безнең, күпне күргән ир-егетләрнең дә күзләренә яшьләр килде.

Сауна яратучы иҗат «генераллары», Равил аганың эссе мунчасына кереп, «эх-ух» килә-килә берничә себерке туздырган арада, мин хуҗаны сораштырып-тыңлап утырдым.

Көрәшергә, бирешмәскә, җиңәргә! Бу кайсыдыр романнан хәтергә сеңеп калган гыйбарә нәкъ Равил Яһүдингә карата әйтелгән кебек.

14 яшеннән күн фабрикасына килеп, соңрак 27 ел аның директоры булып эшләве дә, архивында саклангаан илнең билгеле шәхесләре белән бергә төшкән фотографияләре дә, кайчандыр Германиядә фашист әсирлегендә бил бөккән Рәгыйбә апага халыкара оешмалар аша әллә ничә мең алман маркасын тәшкил иткән пенсияне алып бирүе дә — аерым әсәр өчен маҗаралы бер сюжет ул. Ә репрессия елларында әҗәл тегермәненә эләгеп һәлак булган әтисенә бәйле вакыйгалар аеруча тетрәндерә.

1970 елларда фидакарь хезмәте өчен хөкүмәтнең дәрәҗәле ордены белән бүләкләнгәч, Равил ага, Сталин төрмәләрендә хатсыз-хәбәрсез югалган әтисе Хәйруллланы эзләп, Пенза якларына барып чыга. Сораштыра-сораштыра, кайсына бүләк биреп, кайсын кунак итеп, ул шул елларда төрмә башлыгы булып эшләгән кешене эзләп таба. Ни гаҗәп, Хәйрулла һәм аның белән бергә атылган авылдашларының ачы язмышы турында төрмәче белә икән. Аларның иң коточкыч «гаебе» Рамазан аенда бергәләшеп тәкбир әйтеп намазга барулары була! Бу гөнаһсыз гамәл, НКВД тарафыннан, милли дини банда оештырып, урам буйлап влачка каршы демонстрация оештыру дип бәяләнә.

Влач дошманнарын төрмәдә үк аталар һәм алар утырган камераны кирпеч-бетон белән ябып күмеп тә куялар. Берничә сәгатьтән соң атылганнарны ярлыкау турында югарыдан фәрман килеп төшә...

Соңрак төрмәче ярдәме белән Равил ага элеккеге НКВД башлыгын да эзләп таба һәм төрле юллар белән әтисенең, аның авылдашларының җинаять эшен вакытлыча кулына төшерә. Ә бит ул ябык эш була. Бер атна эчендә Равил абый әтисе һәм аның белән гаепсез һәлак булганнарның эшеннән бөтен мәгълүматны сыгып ала. Кайбер фоторәсемнәрне дә үзендә калдыра. Шулай итеп, күп еллар үткәч, репрессия корбаннарының балалары, якыннары үзләренең әтиләренең язмышы хакында мәгълүмат алалар. Нәкъ бер атнадан соң Равил ага җинаять эшләрен яңадан КГБга кайтара.

Төрмә башлыгы һәм НКВД җитәкчесе кебек каты бәгырьле кешеләрнең дә күңеленә сукмак таба алган Равил ага коточкыч чорның тагын бер җинаятенә тап була.

«Беркөнне зиндан башлыгы, әллә минем алда үзен бурычлы сизгәнгә, әллә эчендә җыелган шакшылыктан арынырга теләп, без барган машинаны кинәт урман кырыенда туктатырга кушты.

— Син, энем, бар, урманга кер, ике йөз метр узгач күрерсең, — ди бу».

Равил ага, нарат урманына кереп бераз баргач, комлы җирдә сибелгән бихисап кеше сөякләренә юлыга.

Шулай итеп, төрмә башлыгы аерылышыр алдыннан Самара егетенә НКВДның тагын бер вәхшилеген ачып бирә.

Бу эш болай була. 800 ләп «халык дошманын» этап белән бер урыннан икенче урынга алып китәләр. Ач-ялангач, богауланган кешеләр юлда бик әкрен кыймылдыйлар. Көн кичкә авыша. Конвойны озатып баручыларның түземлеге калмый. Җитмәсә, өлкә үзәгендә ул кичне беренче тапкыр бозда балет күрсәтәселәр икән. Анда ашыгасы бар. Сәнгатькә мәхәббәт көчлерәк булган, күрәсең. 800 кешене шул нарат урманында «качарга ниятләгән өчен» дип кырып салалар.

Равил ага белән тормыш, заманалар турында озак сөйләштек. Бу кешедән гаҗәеп бер көч, рухи нык-лык, оптимизм бәреп тора. Әйтерсең лә минем каршымда җитмеш яшьлек пенсионер түгел, типсә тимер өзәрлек егет утыра иде.

*Эпилог урынына.* Равил абый белән күрешмәгәнгә биш-алты ел узгандыр. Ул арада Самарадагы таны-шым да, мин дә шактый гына хасталарга дучар булып, кем әйтмешли, яраларны ямап-ябыштырып йөргән-без икән. Эшкә чыккач та, мин Кызыл Ярга шылтыраттым. Равил ага әйтерсең лә фәкать Казаннан теле-фон шылтыравын көтеп утырган. Хәл-әхвәлләрне сорашкач, җитди генә әйтеп куймасынмы:

— Беләсеңме, Дамир энем, бездә бит татар авылларында милли мәктәпләрне ябу башланды...

Дөресен әйткәндә, мин бу хакта хәбәрдар идем. Чөнки андый галәмәт Самара өлкәсендә генә түгел, бө-тен Рәсәй буенча бара. Ләкин моңа ничек каршы торырга? Равил ага үзенә бер хас әрсезлек белән минем борчулы күңелемә шифа салды: «Ә без яптырмыйбыз!» — диде ул, бер дә икеләнмичә. Һәм татар авылла-рында ата-аналарны аякка бастырып, җыеннар уздырып, мәктәпләрне яптырмау турында карарлар кабул иттереп йөрүе хакында тәфсилләп сөйләде. Ягъни демократия игълан иткән Русиядә милләтләрнең язмы-шын конституцион хокукларны кулланып хәл итәргә кирәк. Шигем калмады: минем белән телефоннан көр тавышлы, егәрлеге ташып торган җитмеш биш яшьлек егет сөйләшә иде...

## Холык

Берзаман «Татарстан яшьләре»ндә Альберт абый Яхин турында Туфан Миңнуллин, минемчә, гадел вә эчкерсез мәкалә бастырган иде. Бу арада 70 яшен тутырган Альберт абый минем язмышымда кайчандыр зур роль уйнаган кеше. Ошбу язмам шуның дәлиле булып тора.

Без әле университетны тәмамламаган идек. 4 нче курстан соң мин практиканы «Чаян» журналында узарга булдым. Чөнки ул торгынлык елларында влачка мәдхия җырлаучы гәҗит-журналлардан усал тән-кыйть сүзе белән аерылып тора иде. Һәм дә минем анда кечкенә мәкаләләрем дә басылып килә иде. Ул чакта ук «Чаян»да, башка редакцияләрдән аермалы буларак, чын демократия хөкем сөрә иде. Журналның ярты миллионнан артык тиражы, халык арасында зур абруе булса да, редакциягә партия казнасыннан акча бик аз тамган, күрәсең. Шуңа да хезмәт хаклары түбән, редакция бүлмәләрендә иске мебель, ә баш редак-торның күпне күргән бер иске «Жигули»е бар иде. Дөресрәге, машинада ешрак редакция хезмәткәрләре үзләре йөриләр иде. Соңрак аңладым: биредәге демократия баш редактор Альберт абый Яхинның үзенә бәйле икән. Аның кабул итү бүлмәсе, секретаре юк иде, теләсә кем теләсә кайчан шеф белән аралаша ала иде. Ул гына да түгел, нәшриятның ашханәсендә ике зал бар иде. Баш редакторлар өчен аерым бүлмә, ә га-ди халык зур залда тамак ялгый иде. Альберт абый, мөмкинлеге булса да, безнең белән бергә ашый иде. Әлбәттә, баш редакторлар моны өнәп бетермиләр һәм Яхинга кырын караштыргалыйлар иде, янәсе, кыла-на. Ләкин Яхин демократия уйнамый иде. Бу аның холкы, принцибы. Журнал битләрендә бер төрле — бю-рократларны, масаючыларны һ.б. шундый ямьсез адәмнәрне тәнкыйтьләп-чыбыркылап тор да, ә тормыш-та үзең икенче төрле, ягъни шул тискәре геройларча яшә. Гадел, принципиаль, чиста, тугры булу «чаян-»чыларның язылмаган девизы иде. Һәм моны беренче чиратта Альберт абый безгә үзенең холкы белән ях-шы сеңдерде, матур үрнәк булып торды.

Җәен практиканы уңышлы гына тәмамлап, бишенче курста укый башладым. Ләкин, күп тә үтмәде, беркөнне мине ул чактагы деканыбыз Диләрә апа Тумашева бүлмәсенә чакырттылар. Керсәм: анда Аль-берт Яхин утыра иде. Күрештек.

Альберт абый сүзне, гадәттәгечә, кыска тотты:

— Әйдә, Дамир, җыен, киттек эшкә. Аста машина көтә...

Мин аптыраудан авызымны ачып калдым. Күрәсең, бу мәсьәлә декан бүлмәсендә хәл ителгән иде ин-де.

Шул көннән мин «Чаян»да әдәби хезмәткәр (литсотрудник) булып эшли дә башладым һәм берьюлы университетны да тәмамладым.

Кызганыч, озак та үтмәде, Альберт абый «Чаян»нан башка эшкә китте. Мин моның сәбәпләрен төгәл генә әйталмыйм. Ләкин үземчә болай дип фикер йөртәм. «Чаян» журналының баш редакторы ул чорларда-гы тәртип буенча обком номенклатурасына керә, ягъни аны бюро раслый иде. Баш редакторны эштән алу, башка эшкә күчерү обком карарыннан вә рөхсәтеннән башка бул-магандыр. Ә Альберт абый Яхин кайбер баш редакторлар кебек обкомга йөрергә яратмый иде. Әлеге дә баягы холкы аркасында. Чөнки еш кына «Чаян»га килгән хатлардагы фактлар рай-ком бюрократларына бәйле булалар иде. Ә обком исә үз кадрларына җил-яңгыр тидерми, аларны һәрдаим яклап бара иде. Партократларны сүгү ул әле үзгәртеп кору елларында гына килеп чыккан нәрсә, ә торгын-лык чорында андый гамәл җилгә каршы кычкыру белән бер иде.

Шуңа күрә бил бөгәргә яратмаган, туры бәрә торган баш редакторның урыныннан китүе обком өчен зур югалту булмагандыр. Альберт абыйның яңа эше дә, ягъни университетка мөгаллим булып китүе бу мәсьәләне номенклатурадан башка хәл итүенә ишарәли.

Инде килеп, Альберт абыйның үзенчәлекле холкы турында тагын бер вакыйганы искә төшереп үтим. Ул хәл мин «Чаян»га килгәнче булган. Һәм аны миңа шул вакыйганы үз башыннан кичергән сатирик Борис Бронштейн сөйләде.

«Чаян»да отставкадагы бер полковник турында фельетон бастыралар. Ул әфәнде, төрле мәкерле юллар белән Казан тирәсендә яшәүчеләргә җир мәйданчыклары сатып, акча эшләп йөргән. Кыскасы, фельетон пәйда булгач, әлеге аферист «Чаян»ны мәхкәмәгә биргән. Әйтергә кирәк, Брежнев заманында гәҗит-журналны судка бирү бик сирәк очрый торган хәл иде. Гадәттә, «кем хаклы», «кем юк» дигән карарны әлеге дә баягы обком-райком кабул итә иде. Ул хәзер генә төчкергән саен журналистларны мәхкәмәгә йөгертеп интектерәләр...

Суд буласы көнне Яхин иртән үк Бронштейнга машина бирә һәм җир сатып алучылардан гариза яздырып кайтырга куша. Яхин мәхкәмәгә үзе генә китә. «Фельетон авторы кайтуга суд залына килсен», — дип әйтеп калдыра.

Журналны җавапка тартучы дәгъвачы судта Яхинны «пешерә», тәнкыйтьли, фельетонның нинди документларга нигезләнүен күрсәтүне таләп итә.

Нәкъ шул чакта залга Бронштейн килеп керә. Ул баш редактор янына утыра һәм аның колагына:

— Мин шаһитларны табалмадым, — дип пышылдый.

Яхин югалып калмый.

— Миңа хәзер монда соңгы сүзне бирәләр. Теләсә нинди кәгазь тап та миңа тоттыр! — дип пышылдый ул фельетончыга.

Бронштейн портфеленнән буш кәгазьләр чыгарып Яхинга тоттыра.

Шуннан соң Альберт абый кәгазьләрне чатнаттырып «укый» башлый.

— Дәлилләр дисезме? Менә сезгә дәлилләр! Әле генә безнең журналист сез җир участоклары саткан кешеләрдән язма аңлатмалар алып кайтты. Менә беренчесе гражданка Белованыкы, икенчесе гражданин Вахитовныкы... Дәвам итимме?..

Моны һич кенә дә көтмәгән аферист «лып» итеп урынына утыра. Суд аның дәгъвасын кире кага. Судья Яхиннан документларны, дәлил буларак теркәр өчен, аңар тапшыруын үтенә. Альберт абый чиста кәгазь битләрен судьяга тапшыра. Тегесе бер кәгазьләргә, бер баш редакторга карап өнсез кала. Ләкин эш үткән була.

Иртән редакциягә Татарстанның Югары мәхкәмәсе рәисе шылтырата.

— Карале, Яхин, син кичә мәхкәмәдә ниндидер гениальный трюк күрсәткән икән. Миңа кереп, шул хакта бераз тәфсилләбрәк сөйлә әле. Университетта укытам бит. Студентларга психология сабагын биргәндә гыйбрәт өчен шәп мисал булыр иде...

Менә шундый холык кешедә. Озаккадыр ул...

## Энекәш

Бәла килдеме — капкаңны ач, диләр. Әнинең кабере өстендә беренче чәчәкләр шытып чыгарга өлгермәде, энекәш дөнья куйды. Аны авылга алып кайтып күмдек. Ул көнне урамнар Казаннан кайткан машиналар белән шыгрым тулы иде. Иллегә дә җитмәгән энекәшем Әнвәрнең шулхәтле дуслары-танышлары булуына барысы да шаккатты.

Минем бишмәтне киеп 70 нче елларда Казанга килгән Әнвәр, урта мәктәпне тәмамлаганчы ук, спорт буенча авылдагы, райондагы булган медальләрне, кубокларны яулап өлгергән иде.

Шуңа да, Казанга килгәч, озак баш ватмадым:

— Синең юлың зур спортка, — дип, чаңгычылар клубына алып бардым.

— Ярый, абый, тора-бара укырга да керермен әле, — дип, Әнвәр баштанаяк спорт эшләренә кереп китте.

Үҗәт, максатчан, эшне ярты юлда калдырырга яратмый торган егет иде энекәш. Заманалар җиңел түгел, җитмәсә, гаиләле студент булганга, мин аңа матди яктан әллә ни булыша алмадым. Кайчак ашар-ашамас йөрсә дә, Әнвәр күнегүләрен ташламады. Һәм бер ел да үтмәде, ул беренче разряд алды, шәһәр ярышларында ота башлады. Ә тагын күпмедер вакыт узгач, спорт мастеры булды, Татарстан чемпионатында, Идел буе халыклары спартакиадасында җиңеп чыкты.

Мин энекәш белән горурлана идем. Бер ярышын да калдырмадым. Аның белән урманнарда, бата-чума, чаңгы ярышларында йөри идем. 50 шәр чакрымлык дистанция узарлык егәре, сәламәтлеге булуына соклана идем. Озакламый ул университетка укырга керде, өйләнеп җибәрде, ләкин спортны ташламады.

Тик дөнья — куласа: бер әйләнә, бер баса дигәндәй, шундый җайлы гына тернәкләнеп килгәндә, энекәшне кинәт «ашыгыч ярдәм» белән алып киттеләр. Катлаулы булмаса да операция ясадылар. Спорт күнегүләрен туктатырга туры килде...

Тагын утырып уйлаштык. Спортчылар яшьлеген, гайрәтен, сәламәтлеген сарыф итә-итә кубоклар, медальләр, грамоталар яулыйлар, гәҗит-журнал битләрендә, телевидение экраннарында еш күренәләр, дан казаналар. Ләкин спорттан китүгә, барысы да онытыла. Ә яшәргә кирәк. Ул хәзер генә спортта акча хакимлек итә, ә торгынлык елларында район, республика, ил өчен чыгыш ясау спортчы өчен дан-дәрәҗә иде, шул «кәнфиткә» спортчыларны йөгертепме-йөгертәләр иде.

Ул чактагы минем бер дустым — адаш (хәзер инде мәрхүм) — Әнвәрнең язмышын хәл итте.

— Менә сиңа, энекәш, ике эш: берсе — гади экспедитор, икенчесе — директор урынбасары. Кайсын тарта аласың, шунда барасың, — диде ул Әнвәргә.

Мин үземнең холкым белән беренче мәлгә гадирәк эштән башлар идем дә, тик энекәш, ике уйлап тормый, җитдирәк урынны сайлады...

Аннан соң күп еллар узды. Әнвәр, спорттагы кебек, хезмәтендә дә баскычтан югарыга күтәрелә барды. Көне-төне эштә иде. Зур бер ширкәт оештырып, аның генераль директоры булды, берничә тапкыр депутат итеп сайланды. Гаиләсе түгәрәк: янында терәк булырлык хатыны, мәктәпкә йөри башлаган кызы һәм улы бар иде...

Ләкин матур көннәр, бәхетле еллар озакка бармады. Кинәт, аяз көнне яшен суккандай, җан әрнеткеч хәбәр килде. Кавказда ял иткәндә шифаханәдә Әнвәрнең ашказанында яман шеш таптылар. Гаиләбезнең күге караңгыланып китте. Дөньяның яме югалды. Бәлкем, шушы авыр хәбәр әнинең гомерен кыскарткандыр да инде...

Табибларның фаразлавы коточкыч иде: иң күбе — ярты ел гомер. Операция ясарга мөмкин, ләкин файдасыз. Моны бездәге гадәт буенча Әнвәрнең үзенә әйтмәдек. Бәлкем, ул сизенгәндер дә. Әмма без дә, табиб та ахыргача хакыйкатьне ачыктан-ачык әйталмадык.

Нәкъ шул шыксыз көннәрдә Финляндиядән бер танышым килеп төште. Күрештек. Сүз әлеге темага кереп китте. Аның да туганы шундый ук хәлдә икән. Тик анда бу мәсьәләдә ябыклык юк. Табиблар хастага бөтенесен турыдан-туры әйтеп бирәләр. Алданып-йолданып яшәүнең мәгънәсен күрмиләр. Киресенчә, реаль вазгыятьне белгән авыру белән бергә дәвалау тактикасын сайлыйлар. Чит илдәге дустым: «Әнвәрнең үзенә әйтегез!» — дип киңәш бирсә дә, без җөрьәт италмадык. Үкенергәме моңа, юкмы, хәзер дә төгәл әйталмыйм.

Танылган хирург-онколог Рәфкать Таҗиев Әнвәргә операция ясагач та безгә әйтте:

— Егетләр, шанслар бик аз... Сез безгә бик соң килгәнсез...

Ләкин, ни гаҗәп, тәҗрибәле атаклы табиб та ялгышты. Ашказанын кисеп алгач та, Әнвәр ниндидер аңлашылмаган көчләр ярдәме белән бик тиз аякка басты. Ярты ел да узып китте, бер ел да... Ул яшәде, эшен дәвам итте, депутат вазифаларын да башкарды. Таныш-белешләр гаҗәпләнә иделәр, ә без аның һәр яшәгән көненә үзе белән бергә ифрат сөенә идек. Гаилә бәйрәмнәрендә энекәш, моңлы тавышы белән «Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?» җырын башкарып, барыбызны да елата иде. Безнең белән дуслашып киткән, һәрвакыт аралашып торган Рәфкать әфәнде дә гаҗәпләнүен яшермәде. «Егетләр, мин үзем дә аңламыйм... Мондый авырулар, гадәттә, иң күбе ярты ел яшиләр», — дия иде ул, безнең сорауларыбызга җавап биреп.

Әлбәттә, Әнвәр бу хәлләрдән соң бераз үзгәрде. Кыяфәте белән генә түгел, холкы белән дә. Ешрак хисләргә бирелә, фәлсәфи темаларга сөйләшә башлады. Мал җыю, алдашу кебек тормышыбызда киң таралган нәрсәләрне аңламый да, кабул да итми иде. Илдә чәчәк аткан ришвәтчелек, җинаятьчелек, гади кешеләрнең начар яшәве аны тирән борчыды. Әнвәрне яшәткән көч, әлбәттә, ихтыяр көче булды. Ул беркайчан да төшенкелеккә, паникага бирелмәде. Без моңсуланган чакта да күңелебезне күтәрергә тырыша иде.

Ләкин яман чир астыртын гына аны кимерүен дәвам иткән икән. Ике ел ярым узгач, энекәш тагын сырхауханәгә керде. Бу юлы аның хәле күзгә күренеп начарайды. Бер тапкыр янына баргач, мин аның янәшәсендә утыручы каратутлы ханымга тап булдым.

— Бу хатын — экстрасенс, — дип таныштырды ул мине аның белән. — Тиз арада ярдәм итәргә вәгъдә бирә...

Бата торган кеше саламга да ябыша, диләр. Мин баштарак күрәзәчегә игътибар да итмәдем. Ләкин икенче килүемдә ул аның янында күренмәде. Әнвәрнең кәефе төшенке иде.

— Куып җибәрдем мин аны, абый...

Сәбәбен әйткәч, егылып китә яздым. Ошбу христиан динендәге күрәзәче аңа әйткән икән: «Син безнең дингә күчсәң, исемеңне алыштырсаң, ярты елда савыгырсың, югыйсә үләрсең». Коточкыч бит бу! Үлем түшәгендә яткан, болай да нишләргә белмәгән хәсрәтле кешеләрне мәкерле тырнакларына эләктерергә йөрүче козгыннар янәшәбездә икән бит!

— Юк! — дигән энекәш. — Мин татар, мөселман булып тудым һәм шулай үләчәкмен дә!

Сүз уңаеннан гына әйтим: динне, милләтне алыштыру йә башкача язылу очраклары турында хәзер еш ишетеп торабыз. Әгәр бу афәткә үлемгә дучар булган хасталар бирешми икән, таза-сау кешеләргә динне, милләтне сату килешә торган эшме?!

Әнвәрнең соңгы көннәре турында язарга бик авыр. Сүнә барса да, шылтыраткан саен ул: «Абый, минем хәлләр нормально... Әле бирешергә исәп юк!» — дип, мине тынычландыра иде.

Җәйнең матур бер көнендә (җомга иде) ул күзләрен мәңгегә йомды. Кайгы-хәсрәтебез иксез-чиксез булды. Мәет янында нишләргә белми торганда, кинәт ишектә кыңгырау чылтырады. Мин барып ачтым. Анда бер яшь ханым басып тора иде.

— Сез кем? — дип сорадым мин.

— Мин чәч алучы. Әнвәр абый мине бүген иртән чакырткан иде...

Соңрак белдем: шул ук көнне ул эштә зур киңәшмә уздырырга да ниятләнгән булган икән.

Эх, энекәш, һич кенә үләм дип уйламагансың икән! Соңгы минутыңа кадәр. Шул сине яшәткәндер дә инде...

## Шәүкәт абый

Узган гасырның 70 нче еллар башы иде. Армиягә китәр алдыннан мин якын дустым Наил белән Мәскәүдән аның туган авылы — Кама Тамагы районындагы Кыртапага кайттым. 100—120 йортлык тау астында урнашкан бу авылның чишмәләре Гомәр ага Бәширов язганча «көмеш сулы», сулары искиткеч тәмле иде. Әллә безнең якларда андый таулар-чишмәләр булмаганга (юкса Чувашстанның Батыр районына Кыртападан бер-ике сәгатьлек юл гына), миңа бу авыл бик ошады. Бигрәк тә мәрхәмәтле, кунакчыл, ихлас күңелле кешеләре белән.

Авылдан чыккан булсак та, башкаладан, ягъни Мәскәүдән икәнебезне сиздерергә теләптер инде, без ялда да тик ятмадык. Наилнең әнисе Бану апага, абыйсы Рашатка булышып кына калмадык — буш вакытларыбызда малайшакларны җыештырып футбол уйната идек, ә кичләрен клубка бара идек. Андагы культура-агарту эше безгә, Мәскәүдән кайткан кайнар йөрәкле комсомолецларга, сүлпән бара кебек тоелды. Шуңа да, җырлый-бии торган кызларны-егетләрне үзебез табып, җыйнап, репетицияләр уздырып, Кыртапада гөрләтеп зур концерт оештырдык. Шуннан соң безнең исем авыл кешеләренең теленнән төшмәде.

Озак та үтмәде, Кама Тамагы район газетасында ут уйната торган булдыклы Мәскәү егетләре турында зур гына мәкалә бастырып чыгардылар. Аның авторы Кыртапада яшәүче укытучы Шәүкәт абый Шәрәпов иде. Мин, журналистика, язу эшләренә яшьли күңелем тартканга, Шәүкәт абый белән якыннанрак танышып, аралаша башладым. Кыртападан киткәч тә элемтәләрне өзмәскә килештек. Язмыш шулай килеп чыкты ки, мин Кыртапада ял иткән көннәрдә Казаннан күз явын алырлык бер чибәр кыз ялга кайтып төште. Аның әти-әниләре шушы авылдан икән, ул да чираттагы ялын уздырырга бирегә кайткан. Аның белән бәйле мәхәббәт тарихын тәфсилләп язып тормыйм, кыскасы, соңрак, армиядән кайткач, мин, ул чибәркәйгә өйләнеп, Кыртапа авылы кияве булып киттем.

Беренче мәлгә Шәүкәт абый Шәрәпов белән араларыбызны хатлар бәйләп торды. Ара-тирә ул Казанга да килеп чыга иде. Әйтергә кирәк, ул елларда авыллар арасында хәзерге кебек асфальт юллар юк иде — Кыртапага да, Барышка да Теньки аша, куркыныч Варварин чокырларын кичәкичә, атларда, тракторларда кайталар иде. Шуңа да авыл кешеләренә юл газабы — гүр газабы икәнлеген күп татырга туры килде.

Мин инде, Казан университетын тәмамлап, «Чаян» журналында эшли идем. Әз-мәз хикәяләр, шигырьләр язгалаганга, Шәүкәт абый, бу мәсьәләдә миннән күпкә остарак булса да, өстән аска карамыйча, кыска-кыска шигырьләрен миңа алып килеп күрсәтә, киңәшләшә иде. Кайберләрен, сайлап алып, «Чаян»га бирә идек. Шәүкәт Шәрәпов кайбер хәзерге әрсез шагыйрьләр кебек беркайчан да сан һәм күләм күбрәк булсын дип йөрмәде. Сирәк яза иде, әмма язганы мәгънәле, кызык иде. Шәүкәт абый безнең татар авылларында сирәк булса да әле очрый торган тыныч холыклы, сүзен үлчәп, ләкин җиренә җиткереп әйтә торган мөхтәрәм зыялы кешеләрнең берсе иде.

Менә алдымда аның якташлары ярдәме белән дөнья күргән «Кинаяле җавап» дигән соңгы китабы ята. Бәләкәй басмада мыек астыннан елмаю тартып чыгарырга сәләтле кыска шигырьләр белән тулы бер дөнья. Шәүкәт абыйның ахмаклыктан, ялагайлыктан, наданлыктан, тәкәбберлектән көлүе дә оста итеп «чыбыркы шартлату» белән тәмамлана. Бу сатирик шигырьнең иң четерекле һәм мөһим сыйфаты. Аны кайберәүләр «курокка басу» дип тә атыйлар. Һәм күпләр бу әмәлне гомер буе язып та үзләштерә алмыйлар.

Агач көрәк печән өя,
Тимер сәнәк кар көри;
Лом-башлык, эш бармый, дип,
Аларны сүгеп йөри.

Менә мондый кыска гына юмористик, сатирик шигырьләр аша Шәүкәт абый Шәрәпов дөньяга карашын чагылдыра, үзенең тормышны җентекләп күзәтүен, аның төрле якларын яхшы белүен исбатлый.

Шәүкәт абыйның якташы Туфан Миңнуллин китапның кереш сүзендә аны тау итәге белән чагыштыра. Мин аның белән килешеп, бер генә җөмлә өстәп куяр идем. Шәүкәт ага Шәрәпов ул — тау итәгеннән, Җир-анабыз куеныннан челтерәп агып чыккан күпсанлы чишмәләрнең берсе. Татар әдәбиятының киң елгасы әнә шундый чишмәләр агып торганда гына саекмас.

Исән булса, Шәүкәт абый быел 80 яшен тутырыр иде. Күптән түгел аның кызы Резида (журналист икән) мине «Гомер уза» дигән җырның авторы буларак эзләп тапты. Ул аңа бик ошый, әтисе үлгәч еш тыңлый икән. «Ничек туды соң мондый әсәр? Бик сагышлы... Сез дә кайгылар кичердегезме әллә?» Резида сеңелкәш андый әсәрне кайгыларны үз башыңнан кичергәч кенә язып буладыр дип уйлаган. Әйе, гадәттә бу шулай. Ләкин минем очракта алай булмады. Мин ул шигырьне язганда, зур югалтуларым-кайгыларым алда булган икән. Шуларны сизенеп язганмындыр, бәлкем... Резида, күз яшьләрен сөртә-сөртә, яраткан әтисенең соңгы көннәре турында сөйләде. Үзем дә, киң күңелле Шәүкәт абыйны, бәгырьләремне телеп киткән якыннарымны искә алып, күз яшьләремне көчкә тыеп утырдым. Нишләп тә булмый — язмыш. Һәм инде җырымда әйтелгәнчә:

Әҗәлләрдән дәва булмас инде,
Ходай яшәр өчен бирсен көч...

Һәм һәрберебезгә, һәм һәр көн...

## Йөрәкләрдә кала үкенеч...

Һич көтмәгәндә, уйламаганда, сөекле әниебез дөнья куйды.

Ул кичне сыерыбыз бозаулаган икән. Әни, күрше Мәрьям апа белән шул җан иясен дөньяга тизрәк тудырырга тырышканда, үзен кинәт начар хис итә башлаган. Өйгә алып кергәч, биш минуттан соң, ул бер генә сүз дә әйтмичә, мәңгегә күзләрен йомган.

Бер ай элек кенә юбилейлар уздырып мәш килеп йөргән көннәрдә әни белән әти Казанда иделәр. Шул кичәләрдә катнашып, сөенешеп, рәхмәтләр әйтеп авылга кайтып киттеләр. Җитмешнең өстендә булса да, әни үзенең тапкырлыгы, матурлыгы, сафлыгы белән күпләрне шаккатырган иде. Күрәсең, шуңа безнең уяулыгыбыз да йокымсырап калгандыр. Сеңлесе Гөлсинә апага Казаннан кайткач әйткән әйтүен: «Бу араларда нишләптер хәлем китә... Тик балаларга белгертмәдем... Югыйсә Казанда калдырырлар иде...»

Әни беркайчан да зарлана белмәде. Һәрнәрсәгә шөкрана кылып яшәде, язмышына сыкранмады. Ә бит сүгәрлек иде ул ләгънәт язмышны!

Фәкыйрь, ишле гаиләдә олы кыз булып туганга, аңа лаеш шулпасын бик күп татырга туры килгән.

Утызынчы еллар... Көчләп колхозга кертү. Бабайның бердәнбер сыерын тартып алалар, соңгы әчмуха онын себереп дәүләткә илтәләр.

Минем үпкәм әнә шул чорга һәм берсеннән-берсе бәләкәй сабыйларны ач калдыручы, гади халыкны эт типкесендә яшәргә мәҗбүр иткән залим җитәкчеләргә. Шул дөньяның астын өскә әйләндергән залимнәрне каберләреннән торгызып, мин аларны әнием исеменнән хөкем итәр идем!

Без бит бу дөньяга социализм төзергә дә, мәгънәсез сугыш авырлыкларын күрергә дә тумыйбыз. Безгә гомерне Аллаһы Тәгалә бирә һәм ул гына аны ала. Нигә без шул бердәнбер гомерне үзебезчә түгел, кемнәрнеңдер кушуынча яшәргә тиеш?!

Мин алардан сорар идем: нигә сез, сугыш башлап, кадерле әниемне ач-ялангач килеш урман кистердегез, бүрәнә күтәрттегез, окоп казыттыгыз?!

Ул чорда күргән чиксез михнәтләр дә әнинең йөрәгенә тирән яралар салган бит...

Егерменче гасырның икенче яртысында үз халкын якты киләчәк белән алдап ач калдырган пеләш башлы экспериментаторга мин әйтер идем: нигә безнең матур болыннарны, тирән күлләрне харап иттең, нигә, янә сыерларны колхозга алып, безнең сигез балалы гаиләбезне ач калдырдың? Язын ипи сорап тилмерткән балаларына карап әнинең йөрәге ничек кенә телгәләнгәндер әле?!

Безнең аналарны вакытсыз картайткан сәбәпләр бүген дә җитәрлек. Авылның сикәлтәле юллары, буш кибетләре... Ул гынамыни? Вакытында хезмәт хакын, пенсияләрне түләми интектергән хакимияттән сорыйсым килә: тагын күпме гади халыкның түземлеген сынарга була?! Инде болай да, шартлар булмаганга, авыл сазлыгында нинди бөек галимнәр, җырчылар, композиторлар, шагыйрьләр, талантлар батып-чумып кала!..

Зираттан кайткач, озак кына әнә шулар турында уйланып, гарьләнеп елап утырдым. Радиодан Югославия сугышы турында Мәскәүнең позициясен, шовинистик белдерүләрен тәкрарлап, янә халыкның миен бутый башладылар. Инде соңгы айда гына да Русиянең хәерче бюджетының чиреге хәрбиләргә бирелгән икән. Димәк, тагын бил каешын кысарга туры килә. Кыскасы, гади кешене санга сукмау, аңа төкереп карау сәясәте дәвам итә...

Әнине авыл ярата, хөрмәт итә иде. Соңгы юлга озатканда да, өчесен, җидесен уздырганда да, авылдашларыбыз йортыбызга килеп кайгыбызны уртаклаштылар, безне юатырга тырыштылар.

Гаиләбезнең иң матур гөле шиңгән, өебездә нур югалган авыр көннәрдә мин безнең кебек кадерле әниләрен югалткан кешеләр турында да уйландым. Әйе, мондый аерылышу котылгысыз. Тик һәркемнең йөрәгендә үкенеч каладыр. Кемдер әнисен күрергә авылга сирәк кайткандыр, кайсыдыр авыр сүз әйтеп гафу

үтенмәгәндер, ә кайберәүләр, тапкан малын юкка-барга тотып, әнисенә тиешле ярдәм күрсәтмәгәндер. Ни кызганыч!..

Мәктәптән башлап балигъ булганчы һәркайсыбызга, «исән чакта әниләрне кадерләгез» дип әйтеп киләләр. Ләкин кеше шулай яратылган ки, ул үз башына төшмичә андый үгет-нәсихәтләрне аңламый. Шулай да, туганнар, кайгы килгәнне көтеп тормагыз. Аналарны исән чакта саклагыз, картайтмагыз, кадерләгез. Соңыннан бик үкенерсез. Һәм ул үкенеч гүргә кергәнче сезнең йөрәгегезне телгәләр.

Инде Казанга китәр алдыннан мин тагын бер кат ихатаны әйләнеп чыктым. Язгы кояш карларны эреткәнгә, төрле яктан бәләкәй гөрләвекләр ага, ишегалдында тавыклар кыткылдап йөри, бакчада сыерчыклар сайрый. Кайсыдыр ишектән башына шәл ураган әни килеп чыгар да, безгә хәерле юл теләп, догалар укыр кебек...

## Текә ярда эткәй кала...

Бу язма, инде күптән дөнья күреп, эткәйне сөендергән булыр иде. Тик гомер мәшәкатьләре белән үз көенә ага торды, нишләптер иң якын кешеләремнең берсе турында, утырып, төпле нәрсә язып булмады. Югыйсә этием Минсәгыйрь Гыйсметдиновның тормыш юлы хакында кимендә тулы бер роман иҗат итеп булыр иде. Безнең якларда «тирән елга агар тавышсыз, сай елга агар шаулап» дигән гыйбарә яшәп килә. Әти турында шулай дип әйтергә ярый кебек. Ул үз-үзенә ябылып яшәмәсә дә, данлыклы, гыйбрәтле вә катлаулы, озын гомер юлы узуы хакында шапырынып, мактанып йөрүчеләрдән түгел. Ә сиксән бишен тутырган кешенең сөйләрлек нәрсәләре аз булмагандыр.

...Гыйсметдин бабайның ишле гаиләсендә Минсәгыйрь, өченче бала булып, Идел буе төбәкләрендә ачлык котырган чорда дөньяга килә. Ач-ялангач баланы рәхимсез язмыш бик тиз балигъ итә. Үз куллары белән кызыл балчыктан ясалган сыбызгыларны чуваш авылларына алып барып сатып, бәләкәй Минсәгыйрь дә гаиләне яшәтеп калуга үз өлешен кертә.

Гыйлемгә омтылу, этинең иң көчле канатлары булып, аны гомер буе алга, биеклеккә һәм яктылыкка күтәреп килгән. Сориле авылындагы җидееллык мәктәпкә, көзен-кышын михнәтләр күреп, чабатадан 4—5 чакрым йөрергә ансат булмаган, әлбәттә. Авылдашларының шул авыр чорда күбесе, «укып кем баеган» - дип, сабакларын ташлап, эш камытына җигелгәннәр. Әти исә укуын Батыр педагогия училищесында дәвам иткән һәм 1939 елда аны тәмамлаган...

Армиядә хезмәт итү, сугыш еллары аның гомеренең аерым бер дәһшәтле сәхифәседер. Исемдә, безнең ишле гаиләдә этинең фронтта күргәннәрен, кичләрен җыелышып, һәрберебез «Мең дә бер кичә»не тыңлаган кебек йотлыгып тыңлый идек. Һәр елны 9 майда, майор мундирын киеп, орден-медальләрен тагып, эти, исән калган ветераннар белән бергә Җиңү бәйрәменә багышланган чараларда ялкынлы чыгышлар ясап, күрше чувашларны шаккатыра, безләрне дә сөендерә.

Бөек Ватан сугышында ул санитар машинада яралыларны алгы сызыктан алып, тылга төрле госпитальләргә ташыган. Фашист гаскәриләре, халыкара кануннарны санга сукмыйча, кызыл хачлы машиналарга да һөҗүм иткәннәр. Шуңа да эткәй еш кына үлем белән янәшә йөргән. Хәер, сугыштан исән-имин кайтканнарның һәркайсының дистәләгән, йөзләгән тапкыр теге дөньяга китү, яралану куркынычы булгандыр. Ләкин аларны, безнең бәхеткә, фәрештәләр саклап калганнар. Әти сөйләгәннәрдән бер вакыйганы гына искә алып китәсе килә.

Мәгълүм ки, сугышта солдатны Газраил һәр почмакта көтеп тора.

Матур бер җәйге көндә алман очкычлары кинәт безнең гаскәрләр өстенә бомба яудыра башлыйлар, пулеметлардан ут ачалар. Бу хәлне көтмәгән гаскәриләр, кем кая кача ала, шунда йөгерәләр. Күбесе нигәдер куак-агач арасында урнашкан бер йортка таба юнәләләр. Әти исә, машинасын сүндереп, кырда ялгыз торган бер «ЗИС» астына кереп ята. Бомбага тоту озак бармаса да, очкычлар солдатлар күпләп җыелган бакчалы йортны җир белән тигезлиләр. Анда яраланган, һәлак булганнарның саны бихисап була. Әтигә килгәндә, ул, үзен саклап калган «ЗИС» астыннан чыгып, машинаның әрҗәсенә күз ташлый. Йа Хода, анда дистәләгән ящик снаряд төялгән булган икән! Бомбаның бер генә кыйпылчыгы эләксә дә, «ЗИС» эти белән бергә шундук җәһәннәмгә очкан булыр иде...

Гыйсметдиновлар гаиләсе сугышка ике лачын кебек улларын җибәргән. Берсе — минем этием — аннан исән-сау әйләнеп кайтса, икенчесе — Миңлебарый абый — фронтта хәбәрсез югалган. Әбиебез Сәрвәрҗиһан аны соңгы көненә хәтле көтте. Ләкин...

...Тәрәзәдә шәүлә... Көтә ана
Яу кырыннан улы кайтканын.
Аналарны, картаймасын өчен,
Сугышлардан сакла, Ходаем.

Бу инде күптән гүр иясе булган әбиемә багышланган «Буш тәрәзә» дигән шигырем һич искермәс кебек тоела. Әфган, Чечня... Көткән аналар, кайгы-хәсрәт кичереп, вакытсыз картаялар һәм бу фани дөньядан китеп баралар. Кызганыч, Рәсәйне Ходай әлегә сугышлардан сакламый...

Җиде ел гомер узгач, хәрби офицер, ниһаять, 1946 елда туган авылы Татар Тимәшенә кайта. Сагындырган, бик сагындырган туган як! Дары, кан исеннән гарык булган Минсәгыйрь, сандугачлар сайравын ишетеп шау чәчәкле болыннарны урап чыккач, үз-үзенә катгый карар бирә — бу гүзәллектән һич кенә дә аерылмаска! Җитмәсә, ул сугыш юлларын таптаган чорда Тимәштә менә дигән сылу кызлар буйга җиткәннәр. Касыйм кызы чибәр Минзифаны күргәч, туган якта төпләнү нияте чынбарлыкка әверелә. Тиздән Минсәгыйрь өйләнеп җибәрә һәм башлангыч мәктәптә укыта да башлый.

Әтинең соңрак Казанда читтән торып югары белем алуын, мәктәп директоры булып ярты гасырдан артык хезмәт итүен, кыскасы, мөхтәрәм мөгаллим булып китүен әниебезнең тырышлыгыннан башка күз алдына да китерергә мөмкин түгел. Бу юлы әткәй турында сүз барса да, газиз әнием хакында (ул 1999 елның мартында вафат булды) аерым әйтми булмый.

Ирне ир иткән дә хатын, җир иткән дә хатын, диләр халыкта. Дөрестер бу. Әти укыту, белем бирү, җәмәгать эшләре белән мәшгуль булган дәвердә әни, бер дә чәпчемичә, авыр вә мәшәкатьле хуҗалык хезмәтен үз җилкәсендә алып барды. Ул гына да түгел, кечкенә балаларын да карарга, каенанасына да ярарга, колхоз эшләрен дә җиренә җиткереп башкарырга вакыт, көч-куәт вә теләк таба алды. Әниебезнең искиткеч тәрбияле, зирәк, нечкә күңелле, күркәм холыклы, игелекле, тырыш, изге кеше булганын без аны югалткач кына аңладык.

Язмышның ачысын-төчесен әниебез дә балачактан ук татыган. Ишле гаиләдә үсүе дә, коллективизация галәмәтләреннән күргән нужалар да, якыннарын югалтулар да әнинең йөрәгендә тирән яралар калдыргандыр. Сугыш еллары, ачлык, ялангачлык, урман кисүләр, окоп казулар... Безнең кешене санга сукмый торган влач хәтта күп балалы аналарга да тиешле акчасын түләмәде. Без аякка баскач, әти-әниебезгә кулдан килгәнне эшләргә һәм аларның тормышын җиңеләйтергә тырыштык. Ләкин әни алдында мин шәхсән бүген дә үземне бурычлы итеп тоям. Терсәк якын, әмма... Бу дөньядан ашыгыбрак китте шул әнкәй. Гел әйтеп килде: «Әнвәр улымның әҗәлен күрмәсәм иде, Ходаем!» Теләге кабул булды мәрхүмәнең. Чөнки 1978 елда 28 яшьлек энекәшебез Шамирның һәлак булуы барыбызны да бик тетрәндергән иде. Тагын бер мондый югалту хәсрәтен күрергә теләмәгәндер әни. Әни юк инде... Хәзер аңа багышланган шигыремне укып кына юанырга калды. Әле ярый үзе исән вакытта, бу юлларны язып, аңа карата җылы хисләремне белдереп калганмын:

...Искә төшер узган яшьлегеңне,
Оныт, әнкәй, оныт картлыкны.
Син бу җирдә хәсрәтне күп күрдең,
Татып калчы бераз шатлыкны...

Шулай итеп, тигез генә барган дөньяның бер чите кителеп китте. Гомер көзендә әтигә безнең белән бергә зур югалтулар кичерергә туры килде. Ул беренче мәлгә канаты сынган кош кебек ябыгып, моңаеп калды. «Шәмдәлемдә соңгы шәмем сүнде...» Ул бу сүзләрне җыр белән түгел, елау аша җиткерә иде. Ялгызлыктан әрнүләре, исән чакта «әниегезгә җитәрлек игътибар күрсәталмадым» дип үкенүләре әтине бүген дә тирән сагышка төшерә. Шулай килеп чыкты ки, сигез бала үстереп, әти бүген авылда япа-ялгыз калды. Һәм, гаҗәп, ул сынмады! Алай гына да түгел, миңа да кинәт авыру бәргән чорда ничек тә булса рухымны төшермәскә, бернәрсәгә карамыйча яшәү өчен көрәшергә кирәк дигән өмет чаткысын ирештереп килде.

Язасы сүзләр байтак. Әти һәрдаим безгә әйтә иде: «Иң мөһиме, кеше булыгыз һәм белем алырга тырышыгыз. Һөнәрле үлмәс...» Әтинең сүзләрен тотучылар бер без генә түгел, ә 60 елга якын дәвердә якты мәгариф учагына әверелгән, авыл мәктәбен тәмамлап кеше булган меңләгән шәкертләре дә. Шунысы кызык: чал чәчле абыйлар да аңа исеме белән түгел, хөрмәт итеп «абый» дип дәшәләр. Соңгы вакытта, лаеклы ялга киткәч тә, әти мәктәп проблемалары белән кызыксынып тора. Һәм борчыла. Елдан-ел балалар саны кими, шул сәбәпле татар мәктәбенең киләчәге юк дип, безнең укучылар дүртенче класстан соң чуваш авылына укырга йөрергә мәҗбүр. Кайчандыр ике катлы агач мәктәп төзеткән әти Горбачев чорында үз тырышлыгы һәм үҗәтлеге белән таштан яңа мәктәп һәм балалар бакчасы бинасын салдыра башлаган иде. Акча табылмау сәбәпле, бу төзелеп бетмәгән бина, Рәсәйнең милли сәясәткә булган мөнәсәбәтен тасвирлап, авыл уртасында моңаеп утыра.

Әти бәләкәй татар авылының киләчәге өчен борчыла. Илдә барган сәяси, әхлакый тотрыксызлык, иртәгәсе көнгә ышаныч булмау, яшьләрнең, сукбай балаларның язмышы аны хафага сала. Ә бит үзенең ашарына-эчәренә бар, кием-салымы җитәрлек, атна саен диярлек уллары, кызлары, киленнәре, онык һәм оныкчыклары кайтып торалар. Өендә телефоны, газы бар...

Ләкин гражданлык хисе ташып торган оптимист әти беркайчан да ил, милләт язмышына битараф булмады. Гомер юлы кояш баешына таба барса да, ул бүген дә хәрәкәттә. Ә хәрәкәттә, инде үзегез беләсез,

бәрәкәт. Иманым камил, туган йортта эткәй яшәгәндә, сукмакларны үлән басмас.

Озаграк яшәсәң иде, эткәй!..

...Бола суы нишләп шулай моңсу ага,
Дулкыннары гүя яраларга кага...
Кеше китә — тик исеме генә кала...
Исәннәрне сәфәр көтә, дәшә кала.
Хуш, авылым! Текә ярда эткәй кала,
Бөтен сагыш әйтерсең лә аңа кала...

# Уйланулар

## Текәләр һәм гадиләр

Мәгълүм ки, кешелек дөньясы җәяүлеләрдән һәм тәгәрмәчлеләрдән тора. Соңгыларын янә икегә бүлеп булыр иде — түрәләргә һәм гадиләргә. Беренчеләре юлда интекми-нитми ансат кына хәрәкәт иткәнгә, тәгәрмәчле гадиләр язмышына тәфсилләбрәк тукталасы килә.

...Яңгырлы кич. Эңгер-меңгер... Театральная урамын узып, Горький паркы ягына борылуым булды, ДАИ инспекторы аклы-каралы таягын болгады.

— Сез тоташ сызыкны кисеп борылдыгыз! — дип, лейтенант мине мигалкалы машинасына чакырды һәм протокол тутыра башлады.

Шул чагында бер затлы джип, нәкъ минем эзләргә бастырып, безнең якка борылды. Ягъни, минем кебек үк, юл кагыйдәсен бозды...

— Алайса, аны да туктатыгыз! — дип, мин джипка күрсәттем.

Әллә тәҗрибәсе җитәрлек түгел иде, әллә минем алда принципиаль икәнен исбатларга тырышып, лейтенант, машинасыннан атылып чыгып, тылсымлы таягын селтәп, джипны туктатты. Аның тәрәзәсеннән ниндидер таныклык пәйда булуга, милиционер, фуражкасына кулын куеп, юл кагыйдәсен тупас бозган джипны елмаеп озатып калды.

— Ул хөкүмәт машинасы, — дигәч тә, мин:

— Канун барысына да бер түгелмени? — дип сорап куйдым.

Күрәсең, лейтенантка бу сорау урынсыз тоелды, ул җавап бирмәде. Мин яңгырлы кичтә, эңгер-меңгердә тоташ сызыкның күренмәвен искәртеп, теге джип белән булган хәлне дә протоколга теркәтеп куйдым.

Кыскасы, юл кагыйдәләрен күзәтүчеләр төрле-төрле мандатларга хөрмәт белән карыйлар. Ара-тирә ДАИ җитәкчеләре эфирга чыгып шундый «текә» документларны күпләп конфискацияләүләре хакында сөйлиләр сөйләвен. Мин моңа ышанам. Ләкин әрсезлек, җир астыннан аккан су кебек, теләсә кайдан бәреп чыга. Ниндидер юллар табыла. Кайберәүләр өч бертөрле саннан торган йә «күзгеле» номерларны кулга төшерәләр, кемнәрдер милиция түрәләре имзалаган визиткалар белән аклана. Димәк, милиция бер кулы белән ялган документларны тартып ала, икенче кулы белән юл кагыйдәләрен бозып җәзасыз калырга мөмкинлек бирә торган номерлар, документлар өләшә. Иманым камил, ДАИ җитәкчеләре аклы-каралы таяк һәм сыбызгы ияләрен үз вазифаларын намуслы үтәргә, принципиаль булырга өн-диләрдер. Ришвәт алучы хезмәткәрләрен фаш итеп, алар белән араны бик тиз өзәләр бит. Ләкин юлдагы тормыш еш кына язылмаган кагыйдәләр нигезендә тәгәри.

Әле менә юл хәрәкәтендә тагын бер эксперимент башлап җибәргәннәр. Казанның болай да тар, сикәлтәле урамнарында ДАИ шәһәрнең меңьеллыгы алдыннан күнегүләр уздыра икән. Сирена яңгыратып, утларын яктыртып (янәсе, кортеж килә) ДАИ машиналары үзәк урамнар буйлап узганда, автойөртүчеләр уңга борылып шып туктарга тиеш. Мондый «STOP»ны безнең ике яктан да машина белән тулган урамнарда фәкать Джеймс Бондның махсус автомобильләрендә генә башкарып булыр иде. Тәгәрмәчлеләрнең гадиләре өчен атна-ун көн элек ДАИ хезмәткәрләре Чехов базары янында мәкерле капкын куйдылар. Ершов урамын ябу сәбәпле, бу микрорайонда болай да мәхшәр иде. Ә инде төнлә базар каршына «кирпеч» куеп, иртән тәгәрмәчлеләргә җәза бирү мыскыл итүгә охшап тора түгелме?!. Ә нигә «Марсель» кибете янында бу хакта игълан элеп куймаска? Әйтерсең лә кызыл кенәгәсе булмаган меңләгән автомобильчеләрнең интегүе кемдәдер зур канәгатьләнү хисе тудыра.

Шулай да юлдагы бөтен уңайсызлыклар, башбаштаклык өчен ДАИ оешмаларын, хезмәткәрләрен генә гаепләү һич тә дөрес булмас иде. Эшләмәгән светофорлар, чокырлы, караңгы урамнар, тиешле урыннарында үз вакытында куелмаган игъланнар. Болары өчен беренче чиратта җирле хакимият җавап бирергә тиеш бит.

Ошбу җәһәттән Биектау районы Бөреле борылышында тимер юл кичүен ремонтлау бер эчпошыргыч хәлгә әверелде. Шул сәбәптән бер айдан артык меңләгән машина тимер юлны кичү өчен тузан туздырып,

бензин ягып, 3—4 чакрым артык юл урап хәрәкәт итәргә мәҗбүр булды. Ремонт ясаучылар тимер юлның аръягында да тормыш барын оныттылар бугай. Ә бит шул якта, Казансу буенда, дистәләгән авыллар, йөзләгән бакчалар урнашкан. Гади кешеләр турында кайгырткан хакимиятләр теләсә нинди, шул исәптән вакытлы урау юлларын да тиешле тәртиптә тотарлар иде. Бу цивилизацияле илләрдә нәкъ шулай эшләнә дә.

Соңгы елларда тормыш күзгә күренеп үзгәрә, бөтен яктан капитализм чалымнары күзәтелә. Ләкин бер нәрсә — гади кеше турында кайгырту мәсьәләсе — һаман совет чорындагыча кала бирә.

Гаҗәп бит, хакимият халыкны, хокукый дәүләт төзик дип, кануннарны хөрмәт итәргә, үтәргә өнди, ә үзе күрәләтә аларны бозып килә. Шулай булгач, гади кешеләрдә законга, хакимияткә нинди хөрмәт-ышаныч булсын? Бүген кайбер җитәкчеләрдә гади кешеләрнең гозеренә колак салмау гадәткә әйләнеп бара. Халык — үзенең мәшәкатьле көенә, ә влач үзенчә параллель дөньяда яши. Күрәсең, атаклы инглиз драматургы Бернард Шоу сүзләре бик хаклы: «Хакимият мәгънәсезләрне үзгәртә алмый, ә мәгънәсезләр властьны боза ала».

...Паспорт юнәтер өчен ЖКУдан бер белешмә алырга кирәк булды. Элек ул безнең йортта гына иде. Төрле сәер реформалар аркасында аны үзгәртеп, берләштереп бөтенләй башка урамга күчергәннәр. Күрәсең, документ дәгъвалаучылардан ерактарак булырга теләптер инде. Паспортистка ялда иде. Ләкин ялда булмаса да, эшем уңмас иде. Чөнки... аның бүлмәсенең тимер ишеген инде бер атна ача алмыйлар икән. «Икенче атнада килерсез», — диделәр.

Мондый конторадан ничек чыгып китүем турында язып торасы килми. Шунысын гына әйтим: ЖКУдан чыккан һәр адәмнең авызыннан ләгънәт сүзләре ишетелә. Ирексездән уйлап куясың: әллә бездә гади халыкка начар булган саен, влачтагыларга рәхәтрәк микән?

## Җилемчеләр

Көлке көнендә без өч иптәш Бауман урамына бардык. Салкын иде. Шуңа да «җылыткыч» сата торган кафелар, кибетләр гөжләп торды. Шуннан гайре кызыкны табалмагач, кул селтәп, кайту юлына чыктык.

«Чәй» кибете янында безне кинәт 12—13 яшьлек «шалканнар» чорнап алды.

— Дяденьки, дайте на хлеб! — дип, болар безгә чытырдап ябыштылар.

Ярый әле Рәис дустыбыз югалып калмады. Милиционерларга хас тавыш белән:

— Ну что, нюхачи, нанюхались?! Сейчас всех заберем в милицию! — дигәч кенә, яшь сукбайлар, сүгенә-сүгенә, төрле якка сибелделәр.

Замана билгесе — затлы кибетләр, кафе-рестораннар тирәсендә борын аслары кибеп җитмәгәннәр хәер сорана. Аннары шул акчага «Момент» дигән келәй сатып алалар да, башларына полиэтилен пакет киеп, әнә шул сасы нәрсәне иснәп кәефләнәләр. Авыздагы сигарет, сүгенү — бу адәм актыкларының иң гаепсез шөгыле.

Вакыт-вакыт милиция автобусына төяп тә киткәлиләр икән үзләрен. Ләкин өч сәгатьтән соң, әти-әниләре килеп алмаса, кире чыгарып җибәрәләр. Бу урам малайлары арасында ата-аналылары да байтак икән. Ләкин җилемчеләр өйдә утыруны, мәктәптә укуны һич кенә дә кабул итмиләр. Болар хәер җыйган почмакларда үзләрен ирекле, теләсә нәрсә кыланырга-кылырга хаклы анархистлар кебек тоталар.

Урам көчекләре сыман көннән-көн үрчи барган сукбайлыкның тамырлары, әлбәттә, беренче чиратта гаиләдә. Ә соңгы елларда гаиләләр таркала, ата-ана көндәлек проблемаларын җәһәтрәк шешә ярдәмендә хәл итә. Исереккә дөнья тубыктан, дилбегәсе ычкынган бала-чага шундук контрольдән чыга. Андыйларга урам үзе наркотик, көчле әфьюн. Ул аларны бер эләктердеме — бетте. Моның икенче бер сәбәбе — элеккеге тәрбияви даирәләрнең әлеге мәсьәләдән читләшүе, яңаларының йә булмавы, йә заманча эшли алмавында. Сәбәпләр ачык: нишләп соң чаралар күрелми? Бүген Русиядә сукбай балалар, беспризорниклар тарихта моңарчы булмаган саннарны тәшкил итә! Нужа куа-куа, өлкәннәр балаларны бөтенләй оныттылар, күрәсең.

Моны яздым да сискәнеп куйдым: әлеге туннельдә шулай дөм караңгы микән? Мәктәпләр бар, хәмергә чуммаган әтиләр-әниләрне беләм. Ара-тирә тәүфыйклы балалар да очрый бит...

Өч-дүрт ай элек бер күңелле мәҗлестә булырга туры килде. Бик матур һәм милли рухта узды ул. Җырчылар да, биючеләр дә, музыкантлар да байтак иде. Тик шаккатырганы әлеге мәҗлесне алып баручы бер милли җанлы абзыйның балалары булды. 10—12 яшьлек ике малай гаҗәп матур чыгыш ясадылар: берсе дөнья халыклары биюләрен оста итеп башкарды, икенчесе, көлдерә-көлдерә, яттан татарча шигырьләр сөйләде. Алар белән горурланып утырган әти-әнисе чын-чынлап бәхетле мизгелләр кичерделәр. Хәер, кунакларның да гаҗәпләнүләре чиктән ашкан иде. Әлеге ике баланы кайчан да булса келәй иснәүче яшьтәшләре арасында очратуны күз алдына китереп тә булмый.

Әлбәттә, үсмер чакта балаларга һәрьяктан зур игътибар күрсәтелергә тиеш. Алар файдалы һәм кызыклы шөгыль белән мәшгуль булсалар, бу иң өметле юлларның берсе.

Чит илләрдә моны, мәсәлән, болайрак хәл итәләр. Хоккей, бассейн, чаңгы шуу, компьютер һ.б. Аңлашыла ки, болар өчен шартлар тудырырга, акча тотарга кирәк. 500 мең кеше яши торган Хельсинкида, ми-

сал өчен, 29 боз сарае бар! Анда яше-карты өчәр смена физкультура һәм спорт белән шөгыльләнә. Уйлап карагыз: өчәр смена, ә урын барыбер җитми!

Димәк, балаларга вакытны, көчне генә түгел, капиталны да җәлләргә ярамый. Акыллы илләрдә алга карап яшәүчеләр моны яхшы аңлыйлар һәм нәкъ шулай эшлиләр дә. Киләчәк буын өчен акча салу — иң үтемле, иң отышлы гамәлләрнең берсе, үз-үзен тулаем аклый торган инвестиция.

Ә инде яшь сукбайларның, җилем иснәүчеләрнең күбәюенә илтифат итмичә күрмәмешкә салышып торсак, берничә елдан алар безнең чабуга гына түгел, изүгә ябышачаклар. Һәм, аңлыйсыздыр, җәмәгать, монысы безгә бик кыйммәткә төшәчәк...

## Көз һәм без

Менә табигатьтә тагын алтын көз хакимлек итә. Әле күптән түгел генә гөрләп чәчәк аткан бакчалар саргаеп коелып төштеләр. Аяк астында, ыңгырашкан сыман, сары яфраклар кыштырдый... Әлеге манзара кеше язмышларын хәтерләтә. Заманында бу хакта мондыйрак юллар да язып куйганмын:

Өй каршында... ялгыз каен тора,
Бер яфрагы калган үзенең.
Җилләр исә, яңгыр-карлар ява,
Ләкин төшми яфрак өзелеп.

Минем көзге бакчага чыгуым быел тикмәгә генә булмады. Җәйнең кыл уртасында көтмәгәндә мәкерле хаста аяктан бәреп екты. Шактый михнәтләрдән, борчулы көннәрдән соң аякка басып, шөкер, тәпиләрлек хәлгә килдем.

Чехов базары каршында игелекле куллар белән торгызылган кечкенә генә бакча бар. Ул көне буе гөжләп тора: монда таякка таянган бабайларны да, коляска тарткан әниләрне дә, студентларны да, эт җитәкләп йөргән ханым-туташларны да очратасың. Шәһәр аристократлары үзәге булгангамы, биредә ара-тирә чын зыялыларга, әйтерсең лә иске дәреслекләрдән таныш галим-голәмаларга тап буласың. Андый кешеләрнең итагатьлеге йөзләренә чыккан һәм алар нәниләр белән бергә, һичшиксез, әлеге матур гармонияле бакчаның аерылмас өлеше. Ләкин соңгы вакытта (күрәсең, укулар башланганга) бу бакчада хәзер чын «хуҗалар» — 15—16 яшьлек егетләр һәм кызлар. Аларның күзләренә көзге гүзәллек тә, сәламәтлек сукмакларына баскан бабайлар да, әле генә тәпили башлаган нәниләр дә, табигатьнең соңгы матурлыгын үзенә сеңдергән янар чәчәкләр дә күренми. Аларны кызыксындырган нәрсәләр — базар тирәсендәге тәүлек буена сатыла торган сыра һәм аракы. Әкрен генә, үз көенә барган бакча тормышы яшьләрнең «тырышлыгы» белән парә-парә килде. Эскәмияләр караңгырак почмакларга күчте, аяк астында тәмәке төпчекләре, бушаган шешәләр ауный, тәртипсез сүзләр агышын хәтта трамвайлар тавышы да баса алмый.

Әле монысы бер хәл, бакчада көч туплаган яшьләрнең куллары кычыта, каннары кыза, нәтиҗәдә бераз соңарып шул парк аша өйләренә кайтырга җөрьәт иткән кешеләрнең хәле бер дә көнләшерлек түгел. Җитмәсә, милиция хезмәткәрләре дә әлеге бакчаларны, бәласеннән башаяк дигәндәй, читләтеп узалар. Хәтта Казанның меңьеллыгы бәйрәм ителгән көннәрдә дә бу паркта аларны күрү бәхете насыйп булмады.

Меңьеллык дигәннән, шәһәребездә байтак игелекле эшләр башкарылды. Ял итү урыннары төзекләндерелде, яңа юллар салынды. Бик кызганыч, ләкин вак-төякләренә, гадәттәгечә, кул җитмәде.

Менә шул ук яңартылган Вишневский урамын аркылы чыгарга тырышып карагыз. Парктан алып «Болгар» кунакханәсенә кадәр бертуктаусыз меңләгән автомобильләр хәрәкәт итә. Төзүчеләр «вак кына» мәсьәләне, ягъни җәяүлеләрне онытканнар. «Болгар» кунакханәсе каршында җир астыннан чыгу юлын казыганнар казуын, ләкин, кем әйтмешли, башлаганнар да ташлаганнар. Бөтен туннельгә бер челчел уты кебек лампа яна. Кешеләр, бигрәк тә олы яшьтәгеләр һәм хатынкызлар, ул караңгы базга төшәргә җөрьәт итмиләр. Кыскасы, шул бер вак-төяк аркасында галәмәт киң урамны кичү бүген сират күперләрен узуга тиң.

Көзләр тиздән кышка керер, юллар боз белән капланыр. Малай-шалай моңа, билгеле, бик тә шатланыр. Ләкин халык арасында минем кебек мыжгаклар да дачурта бит, җәмәгать!

## Кара йөзләр

Аларның артымнан килүен аркам белән сиземләдем. Мин яшәгән йортка — илле, ә диагностик үзәккә нибары егерме метр ара калган иде. Анда төне буе ут яна, димәк, сакчылар нәүбәттә утыра. Шунда йөгердем. Ишекләрен шакыдым, хәтта кычкырдым — ачмадылар. Инде нишләргә дип борылырга өлгермәдем, артымнан килгән явызларның беренчесе күз төбемә зур һәм каты йодрыгы белән китереп тә сукты. Күздән утлар чәчелде, чайкалып киттем, ләкин, ихтыярымны җыеп, кулымдагы ашамлыклар тулы пакет белән яшь «шалканның» муен төбенә берне тондырдым. Егыла башлавын күреп, мин шундук баскычтан аның

өстенә сикереп, җиргә бәреп ектым. Күрәм, калганнары мине янәшәдә, йортым каршында көтеп торалар. Тагын 19—20 яшьлек типсә тимер өзәрлек өч егеткә каршы тора алмавымны чамалап, мин, аларга якынаеп, аңлашырга теләдем:

— Егетләр, сез нигә миңа һөҗүм итә...

Җавап урынына төрле яктан башыма, битемә, эчемә тимердәй йодрыклар белән бәрә башладылар. Мин үзебезнең йорт ишегалдына ыргылдым. Ләкин көчләр тигез түгел иде. Җиргә егылганымны, тибеп-тибеп кыйнаганнарын, ахыр чиктә кесәләрдән акча янчыгын, документларны, машина ачкычларын алганнарын хәтерлим.

Шунда берсе әйтте:

— Кажется, он готов... Пошли!

Алар китте, ә мин шунда ятып калдым. Баш әйләнә, күзләр күрми. Күпме вакыт үткәндер, хәтерләмим, тик соңгы көчләремне җыеп, мин, шуыша-сөйрәлә, фатир ишеге төбенә җитә алдым. Хатыным белән кызым мине шуннан алып кергәннәр...

Операция өстәлендә аңга килдем.

Җәрәхәтләрне ямаучы хирург миндәйләрне күп күргән кеше булса да, түзалмады:

— Звери!.. За что же они Вас так?!

Ул сорау әле бүген дә, ерткычларча кыйналудан соң шактый вакыт узгач та, җавапсыз кала. Әлеге вәхшилекне милиция хезмәткәрләре дә аңлап җиталмыйлар. Талау максатыннан башкарылган җинаятьме бу, әллә журналистка һөҗүм итүме? Чөнки соңгы елларда ошбу һөнәр ияләрен кыйнау модага кереп бара.

15 нче сырхауханәдә озак ятмасам да, андагы конвейер аша узган үзем кебек бичараларны күреп, бер нәрсәгә инандым: без криминал илдә яшибез. Башыңа төшмәсә, ул тәмугларны кичмәсәң, җинаять һәм җинаятьчеләр турында «Эфир» телеканалыннан гына җылы квартирада карап утырганда моны ничектер абстракт рәвештә кабул итәсең.

Ә инде «ашыгыч ярдәм» машинасында бертуктаусыз китереп торган кыйналган, мәсхәрәләнгән дистәләгән, йөзләгән кешеләрне үз күзең белән күрү — бөтенләй башка нәрсә.

Күрше палатада биш кеше — урамда кыйналган. Безнең бүлмәдә яткан егет һәм аның яшьтәше студент Рәис (исемен үзгәртеп язам) 8 кешелек төркем тарафыннан өйләре янында кыйналганнар. Бейсбол таягы белән тишелгән башка инде икенче операция ясарга тиешләр. Рәиснең сүзләренә караганда, бу кыйнауны ДАИ хезмәткәрләре карап торганнар, ләкин яшьләрнең үзара разборкасы дип тыгылмаганнар, кан коешны туктатмаганнар.

Чирмешәннән, кырык эшен кырык якка ташлап, Рәисне карарга килгән әнисе бу хәсрәт йортында бер айга якын торса да, хәзерге вазгыятьне, яшьләрнең урамнарда котырган этләр кебек бер-берсен ерткычларча кыйнап, талап йөрүләрен аңлый алмый. Хәер, ул гына да түгел, Казан феноменын галимнәр дә, күпме өйрәнеп, аңлый алмадылар бугай. Югыйсә аңа каршы күптән тиешле чаралар күрерләр иде. Бәлкем, шуңа да башкалабыздагы урам сугышлары бераз тынып кына тора, ә бөтенләйгә беркайчан да тукталмый. Бу меңьеллык шәһәребезнең тутыкмас бер «символы», «визит карточкасына» әверелгән яманаты. Шул урам сугышчыларыннан соңрак «текәләр» үсеп чыга, оешкан җинаятьчел төркемнәр барлыкка килә.

Әйтергә кирәк, урам сырхауханәгә клиентларны шулхәтле күп һәм даими биреп тора ки, биредә палаталар гына түгел, коридорлар да имгәтелгәннәр белән шыплап тулган. Кайберләре монда айлар буе яталар, кайсылары исемсез солдатлар кебек билгесез булганга, алар янына шәфкать туташларыннан, санитаркалардан гайре якын килүче дә юк. 15 нче больницаның биналарын, бүлмәләрен төзекләндерүгә акчасы юклыгы әллә кайдан күренеп тора. Ничәмә лифтның фәкать берсе генә эшләве дә әнә шуңа бәйле булса кирәк. Имгәнгән авыруларны рентгенга, операция, җәрәхәтләрне бәйләү бүлмәләренә ташу гаять катлаулы эшкә әверелә. Аңлашыла ки, биредә төп клиентура аксөякләр түгел, гади халык. Күрәсең, шуңа да сырхауханә проблемалары, сәламәтлек саклау даирәләрендә ул хәтле зур дип исәпләнмичә, елдан-ел чишелми килә. Биредә бәләкәй хезмәт хакына фидакарьләрчә эшләп йөргән табиблар, кече медперсонал һәрбер хаста кешегә кулларыннан килгәнчә булышалар, сыкранулар, җәрәхәтләрне, күз яшьләрен күп күрсәләр дә, аларның бәгырьләре катмаган, тән ярасы алганнарның һәркайсына җан азыгы — җылы сүзне әйтергә онытмыйлар.

Сырхауханәдән өйгә кайткач та, 3 яшьлек оныгым, мине танымыйча, куркып елап җибәрде һәм икенче бүлмәгә кереп посты. Җимерек авыз белән җүнләп ашап булмый, түшәктә фәкать бер рәвештә — түшәмгә генә карап ятасың. Сынган кабыргалар, сызлаган яралар, яртылаш кына күрә торган кан баскан күзләр, җан әрнүләре...

Җитмәсә, тикшеренүчеләр, укол кадарга шәфкать туташлары килә. Паспорт, страховка полисы, машина документларын яңадан ясату да дөнья кадәр мәшәкать икән. Ичмасам, урланган нәрсәләрне почта әрҗәсенә дә китереп салмыйлар, зобанилар! Акчаларны чистарткач, документларны нигә кире кайтармаска? Бу беркатлы кешеләрнең фикере генә икән. Чынбарлыкта исә аферистлар базарында паспортның үз бәһасе бар — ул кара мал белән шөгыльләнүчеләрне кызыксындыра. Безнең хикмәтле адәмнәр кеше бәласеннән дә табыш эзли. Югалган документларны тапкан кеше сиңа сатулашырга килә йә телефоннан шылтыратып акча сорый...

Төркиядән, Прагадан, Мәскәүдән, Чувашстаннан (кай арада ишеткәннәр диген) һәм, әлбәттә, Казаннан, борчылып, туганнар, дуслар шылтырата. Монысы рухи көч бирә. Тик адәм рәтле сөйләшеп кенә булмый. Якыннар өчен гаиләдә әйтерсең лә гадәттән тыш хәл кертелгән. Алар, нәрсә кирәк, ничек ярдәм итик, дип атлыгып торалар. Берничә көннән соң оның та яныма килә башлады. Аның: «Дәти, сиңа больномы?» — дип соравы иң көчле психотропный даруларның берсе иде.

Ни өчен бу кара йөзләр миңа ташландылар? Очраклымы бу, юкмы? Акчаларны, документларны, машина ачкычларын алып китү беренче карашка талау фактын раслап торса да, икеләнүләр бар. Вәхшиләр яшьләре, айнык булулары, яхшы киенүләре, дәшми генә кыйнаулары белән дә күңелгә шик салып качтылар. Кемнеңдер заказы буенча усал телле журналистка карата башкарылган кара гамәл түгелме бу?! Бәлкем, сайлаулар алдыннан мине сырхаухана түшәгенә яткыру кемгәдер бик кирәк булгандыр. «Татарстан яшьләре»ндә Ригага ясаган сәяхәт турындагы язмам нәкъ мин кыйналган көнне дөнья күргән иде түгелме? Анда Латвиядә барган катлаулы милли сәясәт турында язылган өлештә латышларны яклап чыккан идем... «Азатлык» радиосы аша Чечнядагы сугышны тәнкыйтьләүләр дә байтак булды... Әллә болары авырткан башның нигезсез фантазияләре генәме? Акча, бизнес эшләреннән дә ерак торам. Кыскасы, гөманнар күп, ләкин исбатлар өчен теге каһәр сукканнарны тотарга кирәк.

Мин аякка басып килгәндә, Мәскәү телевидениеесе сюжет күрсәтте: танылган журналист Отто Лацис та минем кебек бәлагә юлыккан икән. Телеэкраннарда журналист үзе пәйда булды һәм кыйналуы, талануы хакында тәфсилләп сөйләп бирде. Моның эзләрен Лацисның йөзендә күрмәгәч, мин Мәскәү бандитларының кыйнау культурасы югарырак ахрысы, дигән фикергә килдем. Казаннныкылар бу мәсьәләдә, әдәп саклап тормыйча, измәңне измичә туктамыйлар. Хәер, эш анда гына да түгел. Мәскәү журналистлары мондый фактларны шундук күтәреп алып киң җәмәгатьчелеккә җиткезәләр. Кирәкме бу, юкмы — белмим. Һәрхәлдә, миңа да бу хакта тәкъдимнәр булды. Ләкин моннан баш тарттым. «Менә мине нишләттеләр», — дип җәлләтүне дә, бу факт тирәсендә резонанс, ыгы-зыгы куптаруны да әле төзәлмәгән яраларга тоз салу кебегрәк кабул иттем.

Әле хәзер дә, милиция башлыкларыннан теге кара йөзләрнең эзенә төшәбез дигәнрәк вәгъдәләр килеп торган дәвердә дә, мин әллә ни дулкынланмыйм. Чөнки ышанам: бер гаепсез кешене кыйнап ташлаган һәм аны талаган явызлар үз җәзаларын һичшиксез алачаклар. Хокук саклау оешмаларыннан булмаса, Ходай Тәгаләдән.

Бүген булмаса, иртәгә!

## Үз илендә солтан булмагач...

Соңгы арада чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең адрес-телефоннарын сорап килүчеләр күбәйде. Күрәсең, үз илеңдә тормыш авырайган саен, бәхетне читтән эзләү теләге көчәя бара.

Менә Фәрит (исеме үзгәртелеп бирелә) — типсә тимер өзәрлек 33 яшьлек ир-егет. Армия сафларында 15 еллап хезмәт итеп гарык булгач, Казанга кайткан. Хәрбилеккә күңеле бөтенләй ятмый, башка һөнәре дә юк, ары барган, бире сугылган да — Татар конгрессына килгән. Исәбе — чит илгә китү.

— Нинди телләр беләсең соң? — дип сорыйм Фәрит әфәндедән. Чөнки Мәскәү очкычыннан чит җиргә барып төшкәч тә, бөек Толстой, Пушкин телендә үзеңә бер чынаяк чәй дә сорап алалмыйсың.

— Телләрне өйрәнергә була анысы...

Димәк, үзе дә аңлый армия капитаны. Тик өйрәнеп була белән белү арасында зур аерма ятканын шәйләп бетерми.

— Ярый, ипилек-чәйлек өйрәндегез ди, ә һөнәрегез...

— Мин любой эшне майтарам! — дип, хәрбиләрчә өздереп җавап бирә офицер.

Фәрит өчен теләсә нинди ил, теләсә нинди эш ярый. Иң мөһиме, Рәсәйдән генә чыгып таярга булсын...

— Ә-әнә татарлар яши бит. Финляндиядә дә, Австралиядә дә, Кытайда да. Шуларның адресларын бирегез!

Әйе, татарлар яши торган илләр байтак. Ләкин Фәриткә дә, башка шундый гозер белән килүчеләргә дә чынбарлыкны аңлатырга туры килә: милләттәшләребезнең рөхсәтеннән башка без аларның адресларын, телефоннарын биралмыйбыз. Хәер, бездә дә бит татар булганы өчен генә бер дә белмәгән кешегә кемнеңдер адресын чыгарып тоттырмыйлар.

Ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең оешып (община рәвешендә) яшәүчеләре бармак белән генә санарлык. Һәм алар да Рәсәйдән килгәннәрне эшкә урнаштыру, фатир табу белән шөгыльләнергә атлыгып тормыйлар.

Заманында укытучы булып эшләгән Рәмзия ханым менә икенче ел рәттән ничек тә булса Канадага китәргә хыялланып йөри. Бу идея белән ул күптән «авырый». Кат-кат мөрәҗәгать иткәч, мин аның үтенечен Канадада яшәүче бер ханымга юлладым. *«Зинһар өчен, мондый хатларны кабат миңа җибәрә күрмәгез!* — дип җавап язды океан артыннан милләттәшебез. — *Бездә хәзер канунсыз эмиграциягә әз генә ярдәм итсәң, кысылсаң, мәсәлән, консультация генә бирсәң дә, бик зур штрафларга һәм башка төрле административ җәзаларга дучар буласың...»*

Безнекеләр һич кенә дә аңламыйлар: чит илләрдә Рәсәйдән килгән йортсыз-җирсез татарны сагынып көтеп утыручы юк. Үз акчаңа кунакка бару, милләттәшеңә сәлам биреп, күрешеп, аралашып кайту — бер нәрсә, ә анда бөтенләйгә калу — икенче...

Ниндидер катлаулы юллар белән Нидерландка барып, анда ике ел кара эштә бил бөгеп кайткан Казанда яшәүче Гөлсинә ханым болай ди: «Әгәр миңа монда 500 доллар түләсәләр, мин беркая да китмәс идем».

Нидерландта Гөлсинә ханым бер бай төрекнең өйләрен җыештырган, кафеда бармен булып эшләгән, тагын кайдадыр идән, кер юган...

— Соң, ул хәтле эш башкарсаң, монда да 500 долларны эшләп булыр иде!

— Юк! — дип кырт кисә Гөлсинә ханым. — Мин монда андый кара эшләрне башкара алмыйм. Монда оят...

Чит җирләрдә олтан булу битне кызартмый, ә туган илдә һәркемнең солтан буласы килә. Ләкин солтанлыкка ирешү, җәмәгать, ансат нәрсә түгел, җитмәсә, андый урыннар санаулы.

«Туган җирне ярату», «патриотизм» кебек төшенчәләр модадан чыккан чорда үз Ватаныңны ташлап, чит мәмләкәтләргә китү һәм анда бәхет табу матур хыялга охшап тора. Ә бит Рәсәйдән киткән яшь кызларның маҗаралары вә фаҗигале язмышлары гына да күп нәрсә турында сөйли түгелме?!

Шулай килеп чыкты ки, миңа үз гомеремдә төрле илләрдә байтак йөрергә туры килде. Күп кенә милләттәшләребез белән танышып, инде ничәмә ел очрашып, хатлар алышып торам. Бу җәһәттән соңгы елларда электрон почта гаҗәп мөмкинлекләр тудырды. Инде чит җирләрдә туып үскән яңа буын ата-бабаларын шунда ахирәткә озатса да, юк-юк та татар җирен сагынып монда кайтып китә. Чөнки нәсел агачының кәүсәсе анда, ә тамырлары монда. Ә ул тарта. Чикләр ачыла башлагач та, мөһаҗир балалары ата-бабалары туган җиргә зиярәт кылып, иң кадерле бүләк итеп бер уч туфрак алып китәләр.

...1991 ел. Төркиядә ике гасыр элек таулы-ташлы җирләргә килеп урнашкан милләттәшләребезнең варислары белән очраштык. Коры Көек дип аталган бу авыл кешеләре шактый төрекләшкән булса да, халкыбызның җырларын яхшы хәтерлиләр иде. Төне буе гармун «чалдык», иртән елаша-елаша аерылыштык. Шул мизгелдә авыл картларының күзләрендә күргән тирән сагышны ничек тә тасвирлап бирә алмыйм. Ностальгия — дәвалап булмый торган хаста. Мөһаҗирлекнең әчесен-төчесен үз җилкәсендә татыган буыннар инде бу фани дөньядан китеп тә беткәннәрдер. Ә күпмесе аларның эзсез-хәбәрсез югалган. Буын җепләре өзелгән.

Әлбәттә, бүген заманасы башка, тизлекләр үзгә, элемтәдә торуы да ансат.

Хәзерге яшьләр күрәләтә лаеш шулпасын эчәргә теләмәс. Ләкин шулай да, чәчләренә чал керә башлагач, туган якны сагыну чире аларда да үз-үзен нык сиздерәчәк. Менә моны берьяклы сәяхәт кылырга ниятләүче яшьләребез онытмасыннар иде.

Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, демократия чорында читкә китүчеләр күбәйде. Төрле илләрдә яңа эмиграция оешып килә. Еш кына элеккеге СССРдан күчеп килгән безнекеләр иске эмиграция белән аралашмыйлар. Дога кыла белмәгән, кулына Коръән алмаган, татарча сөйләшмәгән милләттәшләребезне иске эмиграция (нигездә инсафлы-иманлы кардәшләребез) үз итеп бетерми. Чемодан тутыра башлаганчы, менә бу нюансны дә искә алырга кирәк.

Еш кына татар теле укытучылары, музыкантлар, кайбер җырчылар: «Менә Финляндиягә барып татарча укытыр идем, уйнар идем, җырлар идем!» — дип хыялланып йөриләр. Мыекларына чорнап куйсыннар иде: анда яшәүче 800 гә якын милләттәшебез Казан, Татарстанның танылган шәхесләре белән күптән даими элемтәдә торалар. Шуңа күрә үзләренә кирәкле белгечләрне турыдан-туры чакырта алалар.

Ә инде үз-үзен хөрмәт иткән кеше беркайчан да ашка төшкән таракан сыман чакырылмаган кунак булып йөрмәскә тиеш.

## Күл буена килсәң иде

Әллә нинди балыкчы булмасам да, узган җәй мин бакчамнан биш километр ераклыктагы бер күлгә (адресын әйтмим, йә дәррәү килерсез!) кәрәкә тотарга йөрдем. Безнең төбәктәге күлләрдә андый балык байтак. Ләкин аны кармакка эләктерү ансат эш түгел, чөнки һәр күлнең үзенең нечкәлекләре бар. Берсендә, мәсәлән, суалчанга яхшы чиртә, икенчесендә арпа ярмасына эләгә, кайсысындадыр геркулеска менә моондыйларны чыгаралар...

Бер-ике баруда без бер дустым белән нәрсәгә каптырырга кирәклеген ачыкладык. Ләкин вак-төяктән гайре бернәрсә дә алып кайталмадык. Шунда без бу четерекле эштә разведка мәгълүматлары тупларга кирәклеген аңладык.

Күрәбез, бездән ерак түгел бер күзлекле абзый балык чүпләп утыра. Шуңа якынайдык. Исәнләштек, хәл-әхвәлен сораштык. Бу теләр-теләмәс кенә сөйләшә, «әйе», «юк», «белмим»нән артыгын ычкындырмый. Шулай да кармакның тирәнлеген, сеңернең калынлыгын күреп калдык. Исеме Әхтәм икән, пенсионер, күп еллар төзелештә эшләгән. Үзебезнең милләт кешеләре икәнен белгәч, абзый бераз йомшарды, хәтта тактик серне — арпа ярмасына тотуын да әйтте. Хәер, бездә дә шундый ук җим бар иде барын. Шуны кармакка утыртып, тиз генә суга ташладык. Көтәбез, ник бер чиртсен, ә абзый бер-бер артлы зур-зур

кәрәкәләрне чыгарып кына тора. Бу баруыбыз да заяга китте. Шулай да Әхтәм абзыйның кайда утырганын истә калдырып киттек. Янәсе, иртүк килеп аның урынына кармак салабыз.

Иртәгесен без сәгать биштә кабалана-кабалана, күл буена килсәк — тот капчыгыңны — профессионал инде үз эшенә керешкән иде. Тагын нәтиҗәсез кайтып китмәс өчен мин Әхтәм абзыйдан төпченеп карадым. Ни өчен безгә балык эләкми? Югыйсә шул ук ярма, әле безнең кармак саплары пластик — аныкы кебек изолента белән чорналган кәкре таяклар түгел инде.

— Соң, нәрсәсе бар инде аның? Кичтән җим ясыйсың да монда килгәч сибәсең, — дип көлемсерәде ул, минем төпченүләремә бер җөмлә белән җавап биреп.

Гаҗәп, без күлгә машина белән йөрибез, ә Әхтәм абзый «унберенче трамвайда» килә. Ә үзенең дачасы әллә кайда — Арча белән Бөреле арасында икән. Әле, җитмәсә, станциядән күлгә биш километр юл үтәсе. Кай арада килеп җитә диген?!

Берничә көн аралашкач, Әхтәм абзый бераз йомшара төште. Ә инде чираттагы уңышлы тотымнан соң һәм без бераз «шайтан суы» да салып биргәч, бөтенләй ачылып китте.

— Мин монда, агайне, өченче ел йөрим, — диде ул, әллә үкенеп, әллә шатланып. — Аяклар никудышный. Ярты километр атлыйм да утырып торам. Ике операция кичердем. Кан начар йөри...

Шулчак мин аның резина итек кигән аякларына күз төшердем.

— Мондый итекләрдә, җитмәсә, көне буе су эчендә басып торасыз, бетәсез бит!

Әхтәм абзый «Прима» көйрәтеп җибәрде.

— Хатын да шулай ди. Һаман сүгә. Аякларның сызлавына чыдар хәл юк. Тик һәр көнне диярлек шушында сөйрәлеп киләм...

Беренче мәлгә без уйлаган идек: махир балыкчы шушы тирәдә генә тора, шуңа да күлгә иртәнге кояш белән килә. Дустым хәтта: «Абзыйның биредә берәр кәнтәе бардыр, шунда кереп кенә йоклыйдыр ул», — дип тә фаразлаган иде.

Ялгыштык. Безнең фаразларыбызны ишеткәч, Әхтәм абзыйның йөзенә үзенә генә хас елмаю чыкты.

— Балык тоту — бер эш, гыйшык-мыйшык — бөтенләй башка, — диде ул, җитди тонга күчеп.

Чыннан да, шактый мокыт булганбыз икән без. Бер-ике ай эчендә Әхтәм абзый күп нәрсәгә өйрәтте. Дуслашып киттек. Бу эштә мөһим нәрсәләр байтак икән. Җилнең юнәлеше, атмосфера басымы, сеңернең калынлыгы, кармакның зурлыгы, җимне ясау һ.б. Хәтта балыкны чистарту һәм пешерү үзе бер мавыктыргыч технология икән.

Беренче карашка балык тоту гади бер шөгыль булып күренсә дә, чынбарлыкта ул ифрат четерекле нәрсә. Монда түземлелек тә, реакция дә, булдыклылык та бик кирәк. Гадәттә, көннәр буе җүнләп ашамаска да туры килә. Ләкин балык тоту чиреннән арынып булмый. Бу гомерлек дәваланмый торган чир дә, газап та, ләззәт тә. Еш кына балыкчыларның хатыннары, бигрәк тә яшьрәкләре, ирләрен аңламыйлар. Шуның аркасында гаиләдә ыгы-зыгы, талаш чыга. Кайберләре җайлашалар. Ә өченчеләре кул селтиләр. Йөрсен шунда, юк-юк та балык белән кайта бит...

Шулай итеп җәйләр узып китте. Дачалар ябыла башлады. Ә күңел һаман күлгә тарта.

Күптән түгел узып барышлый шунда төштем. Әхтәм абзый белән балык тоткан камышлыкта берәү дә юк иде. Ничектер моңсу булып китте. Әйтерсең лә күлнең дулкыннары, камышлар белән пышылдашып, Әхтәм абзый кебек оста балыкчыны юксына...

## Хәлләр әйбәт, уртача алганда

Марк Твен әйтмешли, алдауның өч төре бар: алдау, рәхимсез алдау һәм статистика.

Атна-ун көн саен бер мөхтәрәм гәҗит Идел буе төбәкләрендәге азык-төлек бәяләрен игълан итеп тора. Шуны укыган саен, хатын белән ике арада баштарак мини-низаг куба иде.

— Акча бетте дәмени? — дип гаҗәпләнәм мин, хәләлемә шакмаклы күзләр белән карап.

— Бетте шул... Азык-төлеккә тоттым. Алар бит бик бәя хәзер... Ашаган белми, тураган белә...

Мин әлеге саллы гәҗитне алам. Бәхәс статистика ярдәмендә дәвам итә. Беренче карашка минем фикерләр саллы һәм оттырышсыз.

— Менә бит иң арзан колбаса бездә, — дим мин, гәҗиткә төртеп, — сыер маеның да иң очсызы Ульяннан кала Казанда...

Хатын статистикага безелдәгән черкине сыпыргандай кул гына селки:

— Ышан син аларга... Беләсе иде, кайсы түшәмнән алып сырлыйлар икән мондый бәяләрне?!

Берничә тапкыр хәләл җефет мине базарга алып барып, кибетләргә алып кереп, махсус экскурсия ясады. Чыннан да, бәяләр гәҗиттәге кебек үк сөйкемле күренмәделәр. Гаҗәп, билгеле.

Ниһаять, абруйлы гәҗиткә дә барып ирешкән, ахрысы, гади кешеләрнең гаҗәпләнүе. Күптән түгел редакция статистика идарәсенең аңлатмасын бәян итте. Ул абайламыйча аякка баскан филнең гафу үтенүен хәтерләтте. Бәяләрне Казанның төрле районнарыннан иң арзанын һәм иң кыйммәтлесен алалар да икән, бергә кушалар һәм, шуны бүлеп, уртачасын чыгаралар. Әнә шул сөйкемле сан статистика мәгълүматы рәвешендә гәҗиттә урын ала. Һәм без Идел буе шәһәрләре арасында ашамлыклар буенча иң арзаннар рәтенә керәбез. Мактанырлык бит!

Кайчак күрше Чувашиядән туган-тумачалар килеп тә кәефне төшерә. Сездә фәлән нәрсә кыйбатрак, бездә ул шалкан бәясе... Баштарак гәҗиттәге статистиканы күрсәтеп борыннарына чиртергә тырышып караган идем дә, соңрак авызым ябылды. Аларда да күренгәли икән ул матур бәяләр диаграммасы. Күрәсең, һәр төбәк үзенчә чыгара ул уртача саннарны. Әле тагын уртача хезмәт хакы, уртача эшсезләр саны, уртача яшәүчеләр һәм үлүчеләр, бер кешегә туры килгән уртача квадрат метрлар бар... Болары да влачның халык турында кайгыртуын дәлилләп торган хикмәтле саннарга охшап тора.

Кыскасы, уртача алганда, әйбәт яшибез. Ә менә һәркайсыбызның, аерым алганда күпчелекнең, көн күрүе шәптән түгел.

Монда көзге искә төшә. Гадәттә, аңа үпкәлиләр. Авызлары кыек булганнар. Ә статистика көзгеләре хәтта андыйларны да матурайтып күрсәтә.

## Әйтмә син авыр сүз!

Көйдергән дә тел, сөйдергән дә тел. Күптән күрешмәгән бер танышымны тыңлап утырам һәм әнә шул хакта уйланам.

Заманында күрше авылга кияүгә чыккан ул. Бердәнбер кызлары туган. Укучылар өчен аның исеме Миләүшә булсын. Бу бала мәктәпне тәмамларга өлгерми, этисе авырып дөнья куя. Әнисе Миңлегөл тырышып-тырышып Миләүшәне буйга җиткерә. Ана белән кыз җырдагыдай бербөтен булып яшиләр. Озакламый Миләүшә Казанга укырга китә. Ләкин аралары өзелми. Алар сагынышып, хатлар язышып, җай чыкканда күрешеп торалар.

Берничә елдан Миләүшә, үзенә яр табып, кияүгә чыга. Ә Миңлегөл, авылда яшәүнең мәгънәсен югалтып, йортын сата һәм, мең төрле бюрократик михнәтләрне җиңеп, Казанга күчеп килә. Янәсе, тиздән онык туа, кызыма якынрак булыйм, ярдәм итим. Ә инде кирәк чакта Миләүшә дә, кияве Газиз дә язмыш кочагына ташламаслар.

Онык туа. Миңлегөл, тулай торактагы бүлмәсен бикләп, кызына килә. Ләкин ана кешегә өч бүлмәле зур фатирда почмак табылмый. Моның сәбәбе дә җепсез энә кебек бик гади булып чыга. Кияү дигән кеше тещаны: «Телең озын, алдыңнан артың яхшы!» — дип, бусагадан борып чыгара.

— Ничек шулай булды соң? Бәлкем, бер авыр сүз әйткәнсеңдер киявеңә? — дип төпченәм мин Миңлегөлдән, яшьләрнең шәфкатьсезлеген шомартырга тырышып.

— Кызымны яклап әйткәләгәнмендер инде. Кем әйтми соң?!

Танышымның күзләре яшь белән тула. Оныкны күрәсе, иркәлисе килә. Качып-посып, кияү эштә чакта гына кызы һәм оныгы янына барып кайта. Ә аннары тәпи йөри башлаган Таһирны елатып, тулай торагына ашыга.

— Ник соң өчәү утырып сөйләшмисез, аңлашмыйсыз? Бәлкем, уртак тел табар идегез...

Юк, бергә җыелып, тыныч кына аңлашу бу адәмнәргә бирелмәгән. Кияү теләми, кыз курка, каенана түбәнсенеп авыз ачасы килми.

Икенче тапкыр мин Миңлегөлне кызы һәм оныгы белән урамда очраттым.

Гаҗәп нәрсә — өчесе дә заманча матур, чиста-пөхтә киенгәннәр, тамаклары тук. Карап торырга бәхетле кешеләр. Ләкин күзләрендә шатлык, йөзләрендә нур юк.

— Соң, син бит ирең белән утырып сөйләшә аласың. Ул яшь кеше, нигә андый каты бәгырьле булырга? — дип сорыйм Миләүшәдән. Күз яшьләре янәшәдәге фонтан сыман.

— Әй абый җаным, мин гел ике ут арасында инде, — дип үкси ул. — Ирем әнине якын китерми, аны яклап сүз әйтсәм, «Бар, аның белән тор!» дип кычкыра. Белмим нишләргә?! Яратам бит мин аны. Икенче балага уздым. Әни дә жәл...

Өч яшьлек оныкның дөньясы түгәрәк, ул шаркылдап көлә-көлә фонтан кырыеннан күгәрченнәрне куып йөри. Тик бер нәрсәне генә аңламый сабый — аерылышуны.

— Дәү әни, син ник безнең белән балмыйсың?

Авыр манзара бу. Хәтта чит кешегә дә. Беренче мәлдә мин Газизгә шылтыратырга да җыенган идем. Ниятем бу капма-каршы лагерьны өстәл артына утырту иде. Татар теле «юк!», «кирәкми!» дигән катгый сүзләрдән генә тормый бит. Анда җайлы сүзләр дә байтак. Аңлашырлар иде.

Әмма Миңлегөл минем бу ниятемне тамырдан кисте:

— Зинһар өчен! Мин аның белән күрешергә дә, сөйләшергә дә теләмим. Файдасыз эш! Үзе башлап гафу үтенсен!

Миләүшә кинәт, усал гына:

— Әй әни! — дип пышылдады.

Әлеге хәлне язуым тикмәгә түгел, җәмәгать. Аңлаша алмаучылар күбәя бара. Якын кешеләр, бертуганнар айлар, еллар буе аралашмый, үпкәләшеп, култык астында таш йөртәләр. Иң мөһиме, кем хаклы да кем гаепле икәнен аңлап та булмый. Чөнки андый кешеләр арасында еш кына упкын барлыкка килә.

Күптән түгел бер мәҗлестә булырга туры килде. Читтәрәк яшь кенә егет дәшми-нитми, уртак сүзгә катнашмый утыра.

Соңрак өстәл артыннан күтәрелгәч, хуҗа кеше теге дәшмәс егеткә:

— Харис, син минем кунакны өенә хәтле озатып куй, яме, — диде.

Киттек без Харис белән. Ул хуҗа абзыйны йөртүче шофер икән. Юл буе бер сүз дәшмәде. Тегеләй дә, болай да әйтеп карыйм — җавап «әйе», «юк». Рәхмәт әйтеп төшеп калдым. Әйтерсең лә мәет ташучы катафалкада утырып кайттым.

Икенче тапкыр дус кешене очратып, әлеге дәшмәс Харис турында сораштым:

— Әтисе белән нык сүзгә килгәннәр алар, — дип аңлатты танышым. — Бер пүчтәк өчен. Гаҗәп кешеләр.

Бу егет күптән түгел өйләнгән икән. Әтисе яшьләргә фатир сатып алган. Соңрак Харис яшь хатыны белән сүзгә килгән.

Әтисе, бу хәлне ишетеп, авылга кайткан улына каты итеп болай дигән:

— Алай була икән, син фатирдан чыгып китәсең!

Улы моңа бик каты үпкәләгән. Әтисе белән сөйләшми башлаган.

Мәгълүм ки, гаиләдә барысын да тигезләп торучы йомшак бәгырьле әниләр бар. Дәшмәс Харисның әнисе дә әлеге хәлдә улы белән ире арасында арадашчы булыр иде. Тик ул үзе дә берничә ай инде ире белән аралашмый икән. Әллә көнләшкәннәр, әллә әрләшкәннәр. Харисның Казанда яшәүче апасы да, энесенең ультиматумын үтә кискен дип, мөнәсәбәтләрне көйләргә тырышып караган. Ләкин аңламаганнар. Очкыннан ут кабына, диләр. Килен белән каената — бер лагерь, улы, әнисе, кызы, икенче лагерьга оешып, инде берничә ай дәшмәү заговорында яшиләр. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, аралар катлаулана бара, барысы да эчтән янып, ут йотып йөриләр, ә берәүнең дә чигенәсе килми.

Бер караганда, бу проблема — әлеге кешеләрнең үз эше, шәхси мәсьәләсе. Ләкин сезгә усал караган сатучы, тиктомалдан нахак сүз әйткән автобус йөртүче, телефоннан кирәк булганда шефы белән тоташтырмаучы дорфа секретарь кыз — болар барысы да әнә шундый проблемалы гаиләләрдән, һәм алар безнең тормышыбызны бер дә бизәмиләр, бер дә җиңеләйтмиләр.

## Ике «изм» арасында

Бездә әлегә капитализмны социализмча төзиләр. Мәркәзебез Казанда, төгәлрәге, Шмидт урамында, тугыз катлы матур йорт салып куйдылар. Фатирыбызның тәрәзәсе шул якка караганга, әлеге төзелешнең башлануы, барышы күз алдыбызда булды. Әйтергә кирәк, төзүчеләр капиталистларча эшләделәр: пөхтә, заманча һәм тиз. Узган көзне элитный йортны салып та куйдылар. Ләкин анда бүген дә беркем яшәми.

Чөнки яңа татарлар вә урыслар әлеге йорттагы фатирларны үзләре теләгәнчә үзгәртеп коралар, төзекләндерәләр. Нәтиҗәдә йортыбыз каршында чын социализм башланды. Тиз арада төзелеш чүп-чарларыннан Эльбруслар, Памирлар һәм башка исемсез биек таулар үсеп чыкты.

Шушы манзараны күреп, әзрәк фикерләү сәләте булган һәр адәм, төзүче булмаса да, уйланырга кирешә. Әгәр дә кешенең зәвыгын канәгатьләндерерлек ясый алмыйсың икән, нигә бу эшкә алынырга? Нигә төзелеш материалларын әрәм-шәрәм итәргә? Аларны куеп-алып, ватып-җимереп, анда-монда ташып йөрергә? Дүрт диварны сал да сат! Калганын һәркем үзенчә маташтырсын. Совет кешесе элек-электән полуфабрикат фатирлар алып яшәгәнгә, ул аларны һәрвакыт үзенә ничек кирәк, шулай ясый иде. Ә монда тышкы диварларны капитализмдагыча матур салдылар, ә эчтә аннан-моннан, социализмдагыча эш майтарганнар.

Шәһәрдә заманча супермаркетлар, яңа базар комплекслары төзелә. Шуларга керәсең дә, муллыкны, чисталыкны күреп, тәмле исләрне иснәп, тауар алмасаң да, сөенеп чыгасың. Монысы — капитализм. Ләкин социализм да әллә кая китмәде: ул фасад ягыннан куылса да, ишегалдына кереп урын алды. Чүп-чары, сасысы, шунда казынган этләре, сукбайлары белән яши бирә үлемсез социализм.

Капитализм яшәгән Бауман урамыннан элеккеге Киров урамына таба йөз метр китсәң, социализмга яңадан кайтасың. Чокыр-чакырлы юллар, бер Аллага мәгълүм кагыйдәләр буенча хәрәкәт иткән йөзләгән автобуслар, машиналар, троллейбуслар, кешеләр. Яңа тәртипне биредә көне-төне сакта торган милиция хезмәткәрләре дә урнаштыра алмый.

Әзрәк фикерләү сәләте булган һәркем әлеге мәркәзне үзгәртеп кору турында уйланадыр. Шәһәрдә көннән-көн автомобильләр саны арта, ә без атлар чорында бабайлар салып калдырган урамнарны яңабаштан корырга кирәк икәнен әллә онытабыз, әллә теләмибез. Ә бит бу эш үзәктән башланырга тиеш. Чөнки Казан ул бер Бауман урамы гына түгел!

Ә үзәк бүген тончыга. Төзелеп яткан метро да транспорт проблемасын чишә алмас кебек.

Чөнки автомобильләр саны тизрәк арта. Димәк, шәһәрдәге транспорт хәрәкәте принципиаль чишелеш табарга тиеш. Әлегә хәтле үзәккә чыккан урамнарда яңа йортларны искеләр урынына салу гадәте яшәп ки-

лә. Безнең архитекторлар урамнарны киңәйтүдән шайтан догадан курыккан кебек өркиләр. Нәтиҗәдә Идел буендагы шәһәрләрдән тик безнең Казанда гына транспортның бөтен төре берьюлы бер үк урамнардан йөри. Берсе туктап калса, баш бетте — паралич!

Бәлкем, шәһәр күләмендә бу проблемалар турында борчылалар һәм уйланалардыр. Ләкин монысы безгә мәгълүм түгел. Гәрчә казанлылар арасында чын архитекторлар да, белгечләр дә, акыл ияләре дә җитәрлек. Нигә мәркәзне үзгәртеп кору, шәһәрнең башка проблемаларын чишү кебек җитди мәсьәләләрне алар белән дә киңәшмәскә, конкурслар уздырмаска? Әнә бит Швейцариядә кайчак берәр агачны күчереп утыртыр алдыннан да референдум уздыралар.

Кыскасы, ачыклык җитми. Әйе, рекламалар һәр тыкрыкта күзгә бәреп, кычкырып торалар — монысы капитализм, ә чын хәбәрдарлык, халык белән киңәшүдә элеккегечә — социализм.

Менә шулай ике «изм» арасында адашып, аптырап, аңгыраешып йөрибез, җәмәгать!

## Йөрәк җылысы

Әгәр дә авыру кеше яшәргә тели икән, табиб бу очракта көчсез.

*Фаина Раневская*

Сагындырып килде быел бураннар. Әйтерсең лә соңга калганга ашыккандай кар өермәләре бөтерелеп-бөтерелеп йөрделәр дә тиз арада хастаханә бакчасының җирәнсу аллеяларына калын ястык булып яттылар. Тәрәзәләрдә, су торбаларында җил төрле октаваларда бертуктаусыз кышкы романс уйнап торды. Ниһаять, дөнья, кешеләрне сөендереп, ак биләүгә төренде. Салкыннары да озак көттермәде.

— Һәр фасылның үз бизәге шул...

Мин Нәҗия белән килешәм. Ул хастаханәдә дә күңел төшенкелегенә бирелми. Ә бит чамасыз озакка сузылган шыксыз көздә үк сәламәтлекләре һава торышына бәйлелектән хастаханәгә кереп яткан авыруларның кайсының башы авырта, кайсы йөрәген тотып йөри, бер ишеләре карап торырга исән-имин, ә кан басымын үлчәп карасалар, табибларның күзләре дүрт була. Мин дә шулар рәтенә керәм. Рәхмәт Нәҗиягә. Күрше палатада көннәр буе баш күтәрми яткан кешене, әллә кызганып, әллә бераз хәлен җиңеләйтергә теләп, елмаеп килеп керә дә: «Дамир абый, берәр нәрсә кирәк түгелме?» — дип сорый. Шул сөале генә дә авырткан йөрәккә май булып ята, сәбәпсез уйнап торган кан басымы хакында бер мәлгә онытып торасың. Хастаханә бүлмәләре яктырып киткәндәй була. Куе коңгырт чәчләре, тигез көрәнсу кашлары, сөйкемле йөзе, халат астыннан сизелеп торган матур буй-сыны бу яшь кенә хатын-кызны кешеләргә ягымлы, игътибарлы булуы өчен мин бүгеннән безнең неврология бүлегенең башлыгы итеп куяр идем. Ләкин Нәҗия авыл мәктәбендә укытучы һәм мондый күркәм сыйфатлары аркасында аңа хезмәттәшләре, мәктәп җитәкчелеге ике кул белән ябышып тора. Яхшы кеше кайда да кирәк шул.

Беркүпме вакыт узып, аякка баскач, мин ашханәгә үзем тәпили башладым. Нәҗия белән бер өстәл артына туры килдек. Биредә дә авыл укытучысы миңа илтифатын киметмәде. Йә чәй ясап китерә, йә савыт-сабаларны илтешеп куя. Ә кичке аштан соң озын, бормалы коридорлардан берәр сәгать җәяү йөрү безнең гайре рәсми шөгылебезгә әйләнеп китте.

Хастаханәдә вакыт ташбака кебек йөри. Ә төрле темаларга гәпләшеп хәрәкәт иткәндә, үзеңне ниндидер кирәкле эш башкарган кебек хис итәсең. Иң мөһиме, сәгать уклары да тизрәк әйләнә кебек.

Нәҗия күбрәк тыңларга яратса да, ара-тирә үзенең гаиләсе, туганнары хакында бер-ике кыска җөмлә кыстырып куя. Туган ягы Магнитогорск, әби-бабалары ачлык елларында, татар җирен ташлап, шунда юл тотканнар. Яшьлек чоры имансызлык, ассимиляция заманына туры килсә дә, Нәҗия, аның ике сеңлесе татар тәрбиясендә үскәннәр. Утызның өстендә генә булуына карамастан, ул ике зур югалту да кичергән. Сеңлесе фаҗигале рәвештә юл һәлакәтендә дөнья куя. Тагын бер якын туганы да гаиләсе белән шундый ук фаҗигагә дучар була. Нәҗиянең кайгыларын мин бик яхшы аңлыйм. Ике энекәшемне югалту, әни белән әбине җир куенына иңдерү минем чәчләремә дә чал кертеп, йөрәккә тирән вә төзәлмәслек җәрәхәт салды. Бәлкем, шул кайгы-хәсрәтләрдән соң сикерә башлагандыр да ул тиктормас кан басымы!..

Магнитогорскида үткән елларны Нәҗия бөтенләй искә төшермәде. «Анда кайткан саен бер-ике атна ятактан торалмыйм. Башым авырта. Андагы экология — ужас!» Ә бит балачак, үсмер чор, яшьлек еллары гадәттә кеше хәтеренә матур бизәкләре, мизгелләре белән уелып кала. Күрәсең, Нәҗиянең Урал якларында үткән гомере андыйлардан булмаган. Кем белә, бәлкем, Урал чибәренең гайрәте чигүгә экология генә сәбәп түгелдер...

Соңрак татарлар, кыр казлары сыман, туган төбәкләренә кайта башлаган чорда, Нәҗиянең барлык якыннары Татарстанга юл тоталар. Әлбәттә, бу бик мәшәкатьле күченү, яңа урында оя корып җибәрү бөтен гаиләдән зур көч, матди чыгымнар, сәламәтлек таләп иткәндер. Нәкъ шул дәвердә Нәҗиянең беренче баш авыртулары үзен сиздерә башлаган да инде...

Хастаханә тормышын каләм ияләре ничектер читләтеп узалар, һәм бу аңлашыла да. Сүз бит сабан туе, тамаша-кәнсирт, колхоз яисә завод, замана геройлары хакында түгел. Ләкин үзәк өзгеч драмалар, иң әче күз яшьләренә нәкъ шушы ак диварлар шаһит булалар да инде. Юкка гына Габдулла Тукай хастаханәне

үлемгә барганда «соңгы станца» дип атамаган. Тик күпме генә сәяхәт итсәң дә, юллар шунда илтә һәм күпләрнең шунда тәмамлана да.

Бередә язылган кагыйдәләргә караганда язылмаганнары күбрәк. Әйтик, җаваплы табибка хаста кеше һинд кешесе изге сыерга табынган сыман табына. Аның киңәшләрен хасталар һичшиксез үтәргә тырыша. Шулаен шулай да, тик авырулар белән уртак тел табу, мөшкел хәлгә төшкән кешенең күңел халәтен аңлап, аны дәвалау юлларын дөрес билгеләү бик сирәк талантларга гына бирелә.

Бер ел элек хастаханәдә ятканда минем кинәттән кан басымы күтәрелеп чак кына инсульт булмады. Шәфкать туташлары, йөгерә-йөгерә, дежур табибны эзли башладылар. Тегесе юк та юк. Ул шимбә көнне бөтен зур хастаханәгә берүзе генә икән. Ярый әле, кем әйтмешли, кичә генә өйләнмәгән, таблеткалар янымда, кайсысын эчәргә икәнен дә михнәтле тормыш инде өйрәткән иде. Ярты сәгатьтән соң, ниһаять, яшь кенә чибәр туташ янымда пәйда булды. «Бу инсульт һөҗүме... Була торган хәл... Даруларыгызны эчегез дә ятыгыз...» Шаккатырсың, сәхнәләрдә йөрерлек буйсыны вә кыяфәте булган чибәркәй кай арада кеше организмының бөтен нечкәлекләрен өйрәнә алган диген?!

Наҗия, бернәрсәгә дә чәпчемичә, анализларын биреп, даруларын эчеп, безнең белән бергә ике атналап хастаханәдә ятты. Аның монда булуы минем өчен караңгы бүлмәдәге якты нур, ә елмаюын күрү иң шифалы даруларның берсе иде. Шуңа да мин эчемнән генә Наҗия белән аерылу минутларын мөмкин кадәр кичектерүне тели идем...

Ә без, ир-егетләр исә, табибларның обходыннан соң үзебезнең консилиумнарыбызны уздырабыз. 47 яшьлек шофер Зөфәр инде 5 ел элек инвалидлык алган (йөрәк клапаннарын алыштырган) һәм менә инде ике атна табибтан «Ник мин болай йөткерәм?» дигән сорауга җавап көтә. Шундый ук җайсыз бер сорау аягы кинәттән аксый башлаган банкир Җәүдәтне дә борчый. Ә Чечня сугышыннан кайткан 25 яшьлек Радмир, саташып, йокы аралаш палата буенча арлы-бирле йөри, башкаларны шик-шөбһәгә сала. Чөнки аларның төн йоклыйсы бар. Алла сакласын, Радмирның күзенә төнлә дошман булып күренсәң... Башыңа күсәк алырга да озак түгел. Ярый әле бу хәлләрне аңлап, табиблар психикасы имгәтелгән авыруны тиз арада тиешле адреска озаттылар. Кыскасы, бередә һәрбер сырхау ак халатлылардан зарыгып ярдәм һәм җавап көтә. Безнең алдагы язмыш нинди булыр? Тик төгәл диагнозны белүче дә, әйтүче дә юк. Ял итегез, имеш. Кая ашыгырга?

Мәгълүм ки, соңгы елларда безнең хастаханәләр дә динозаврлар чорыннан чыгып, техник яктан шактый гына җиһазландырыла башладылар. Ләкин табиблар аларда эшләргә өйрәнсәләр дә, дәвалау эшен кискен камилләштерә алмадылар. Техника белән аларның берсе эшләсә, диагнозны икенчесе куя. Ә бит табиб ялгышы миначы ялгышына тиң. Аермасы шунда: миначы хатасы өчен үз гомере белән түли, ә табиб — кешенеке белән.

Наҗия мондый «бәхәс-консилиумнарда» ак халатлылар ягында. Имеш, нинди җаваплы хезмәт — ә күпме генә түлиләр. Шуңа күрә авырулар мондый игелекле хезмәт ияләренә бүләкләрен, акчаларын кызганмасыннар иде... Наҗия ике якны да бәхетле итү ягында. Хәер, табибларны «майлау» темасы хасталар арасында әледән-әле күтәрелә. Шоколад, кәнфит бирүләр хәзер врачларны мыскыл итүгә тиңләшә икән. Затлырак бүләкләр, бигрәк тә ак халатның кесәсенә сиздерми генә саллы акча салу ташбака кебек әкрен теләсә кемне дә скипидар сөрткәндәй йөгертә башлый. Баксаң, без инде бүген түләүле медицина чорына икенче аягыбыз белән дә кереп барабыз икән.

Буранлы көннәрне кояшлы һава алыштырды. Мондый халәттә гаҗәеп оптимизм калкып чыга, яшиселәр килә. Авыруларның аклы-сарылы кыяфәтләрендә күптән югалган башка төсләр пәйда була башлый. Мин дә Наҗиянең битләрендә ниндидер серле елмаю, ә күзләрендә «Дамир абый, көннәр язга таба алыша, ә сез, каләм иясе, нигәдер бер җылы сүз тапмыйсыз?!» дигән сорауны укыйм. Укуын укыйм да, сүзләрем дә бар, ләкин кыюлыгым җитми.

Ниһаять, коридорның яктыртылмаган бер почмагында мин, Наҗиянең кулын тотып:

— Синең кебек кеше... ул... фәрештә... Сине яратмый мөмкин түгел! — дип пышылдадым.

Наҗия кулын тартып алмады. Коңгырт күзләренең озын керфекләре күбәләк канатлары сыман тиз-тиз бер-берсенә тигәләп алдылар:

— Дамир абый, бу бит хастаханә... Нинди ярату, нинди фәрештә?!

— Күркәм сүзләр хастаханәдә күпкә кадерлерәк ул, Наҗия!..

Ул минутларда йөрәк дөп-дөп тибә, кан басымы да табибларны шаккатыргыч дәрәҗәгә сикергәндер. Тик мин ниндидер ләззәти дөньяда гизгәнгә андый вак-төякләргә илтифат итеп тормадым. Бу минутларда мин үземне ниндидер сәхнәдә — сөюдән шашкан әллә Хәлил, әллә Таһир ролендә хис иттем. Тагын да каударланып, Наҗиянең өстенә бер олау комплиментлар, искә төшкән шигъри юлларны аудардым. Ул ышаныргамы-юкмы дигәндәй сүзсез калды. Көткәндер ул андый хикмәтле вә назлы җөмләләрне! Чөнки өйләнеп, балалар үсеп җитлеккән чорда без, ирләр, хатыннарыбызга иң күркәм комплимент «Ашың тәмле булган!» дигәннән артыграгын ычкындырмыйбыз. Өйгә кайткач, телләр көрмәкләнә, кая ул мәхәббәт турында искә алу!

Шул көннән безнең коридорда йөрүләр ниндидер бер эчке мәгънәгә ия була башлады. Мин хыялый бер дөньяга килеп эләккәндәй булдым, ә иң мөһиме, авыруымны да онытып, фәкать Нәҗия турында уйладым.

...Ул көнне кояш каядыр болытлар артына югалып, тагын көчле җил купты, кар ишә башлады. Күңел нәрсәдер сизенгәндәй булды. Соңгы көннәрдә мине бер урынлы палатага күчергәннәр иде. Кинәт ишекне кемдер шакыды.

— Керегез!

Бусагада Нәҗия күренде. Ул үзенә килешеп торган матур күлмәктән иде.

— Нәрсә, Нәҗия, сине чыгаралар мәллә?

Нәҗия, урындыкның бер читенә утырып:

— Әйе, Дамир абый, бер сәгатьтән мине алырга ирем килеп җитә. Мин хушлашырга кердем. Зинһар, башка авырмагыз... Мин Ходайдан сорармын...

— Тукта әле, Нәҗия, ә синең соң диагнозың?..

— Ә минеке, Дамир абый... — Ул бер мизгелгә тәрәзәгә борылды. — Ә минеке, сез әйткәнчә, чыдасаң, түзәрлек... — Нәҗия, тиз генә урыныннан кузгалып, минем кулымны кысты һәм битемә кайнар иреннәрен тидерде: — Хушыгыз! Бу язуымны мин киткәч укырсыз!..

Ул китте. Мин икегә бөкләнгән дәфтәр битен нигәдер бер куркыну белән ачтым.

*«Дамир абый! Мине диагноз белән шатландырмадылар. Киресенчә. Нишлисең, язмышым шулайдыр. Тик сез бирешмәгез! Мин сезне яраттым».*

Йөрәктә әйтерсең лә нидер өзелеп китте. Тәрәзәгә бәреп яуган җепшек кар, эреп, пыяла буйлап күз яшьләре сыман бертоташ ага иде...

## Эчтәлек

### Сукыр тавык

*(Юмористик хикәяләр)*


Ботак ........................................
Көнләшү ........................................
Суга сикермәгез!.. ........................................
Разборка ........................................
«Террорчылар» ........................................
Сукыр тавык ........................................
Влач бар ул! ........................................
Интервью ........................................
Ярый әле... ........................................
Язып кара! ........................................
Май кап! ........................................
Кабак ........................................
Дурдом ........................................
Букет ........................................


### Исем китә бирәүгә

*(Шаян шигырьләр)*


Уртача ........................................
Исем китә бирәүгә ........................................
Ни җитмәгән? ........................................
Демократия ........................................
Әби-бабай тәрбиясе ........................................
Җыя халык долларны ........................................
Сагыну ........................................
Үпкәләмә Ходайга ........................................
Ришвәткә мәдхия ........................................
Иске сандык ........................................
Гали, Вәли һәм бәяләр... ........................................
Ярты ........................................
Атта да, тәртәдә дә... ........................................
Бикле урман ........................................
Яңа ел попсасы ........................................
Иҗат газабы ........................................
Яшен ........................................


### Гомер уза

*(Җырлар, шигырьләр)*

Кызлар көлә... ..........................................................................................
Китәр идем дә бит... ..................................................................................
Киленнәр......................................................................................................
Сөю хакына...................................................................................................
Үкенү............................................................................................................
Яңа бистә......................................................................................................
Бер җырлыйсы килә ....................................................................................
Ничек түзим икән?! ....................................................................................
Сөю хатлары ................................................................................................
Ә мин калам Казанда... ..............................................................................
Мәхәббәт юк диеп уйлама ..........................................................................
Сөюебез әле алдадыр ..................................................................................
Кайсыгызның күңеле нечкәргән?.. ............................................................
Күңелең сынмасын........................................................................................
Гомер уза.......................................................................................................
Урман чәчәкләре .........................................................................................
Идел ярларында без икәү... ........................................................................
Оныта адәм баласы .....................................................................................
Диңгез ..........................................................................................................
Тагын кайттым ............................................................................................
Чабата...........................................................................................................
Дәфтәр..........................................................................................................
Соңгы яфрак ................................................................................................
Күл................................................................................................................
Багышлау ....................................................................................................
Юл чатында... ..............................................................................................
Кеше китә... .................................................................................................
Ялгыз әткәй..................................................................................................
Әгәр мине шулай яратсаң... ........................................................................

## Юлъязмалар

Татар — Африкада да татар .....................................................................
Бардым, җаныем, Донбасска… ..................................................................
СССРга сәяхәт ..............................................................................................
Эссе күл хатирәләре ......................................................................................

## Күркәм шәхесләр, изге җаннар...

Гомер җыры ..................................................................................................
Җитмеш яшьлек егет.....................................................................................
Холык ............................................................................................................
Энекәш ..........................................................................................................
Шәүкәт абый.................................................................................................
Йөрәкләрдә кала үкенеч................................................................................
Текә ярда әткәй кала... .................................................................................

## Уйланулар

Текәләр һәм гадиләр ...................................................................................
Җилемчеләр ..................................................................................................
Көз һәм без....................................................................................................
Кара йөзләр...................................................................................................
Үз илендә солтан булмагач... ......................................................................
Күл буена килсәң иде...................................................................................
Хәлләр әйбәт, уртача алганда.......................................................................
Әйтмә син авыр сүз! ....................................................................................
Ике «изм» арасында ......................................................................................
Йөрәк җылысы..............................................................................................

Литературно-художественное издание

***Гисметдин*** *Дамир*

***(Гисметдинов*** *Дамир Минсагирович)*

**Дело и в коне, и в оглоблях...**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Гыйсметдин** Дамир*

*(**Гыйсметдинов** Дамир Минсәгыйрович)*

**Атта да, тәртәдә дә...**

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы *Л.П.Петрова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә
салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.04.2007. Форматы 70□100 1/32. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 8,45. Шартлы буяу-оттиск 8,78. Нәшер-хисап табагы 7,90.
Тиражы 1000 д. Заказ С-466.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.